Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

1

гыйнвар 2021

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Коточкыч ачлык
28 бит

Белмим, үзең сизәсеңме...
87 бит

Һади Такташ улы Рафаил белән

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

1 (325)
гыйнвар 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

28

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Ләйлә Лерон
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Гомәр Бәширов

ТАРИХИ МИРАС

4 «Күңелебезнең үз иленә чыктык!» *М.Фәйзи*
10 Кыпчаклар
12 Җөри хан турында риваять. *Р.Галләм*
14 Шәмсуар йолдызлыгы. *Ф.Бәйрәмова*
21 Секира. *Л.Нәгыймов*
22 Казаннан читтә татар китабын бастырган матбагалар. *Р.Мәрданов, И.Һадиев*
28 Коточкыч ачлык. *Р.Шәрәфиева һәм Л.Гобәйдуллин*
32 Мәхмүд Мәрҗанинең кабер ташы. *А.Гайнетдинов*

ТАТАР ГАМЕ

34 Уразмәтнең фаиз углы. *М.Әмирханов*
42 Җәүһәр иясе Җәүһәриягә. *Ә.Зарипов*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ДИНИ МИРАС

48 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
54 Мәңгелеккә юнәлеш. *И.Таһиров*
60 Ислам хакында хакыйкать. *А.Али*
62 Әтием Азиз Али турында. *Җ.Али*
64 Азиз Али шигырьләре
66 Нарыш аксакалы. *С.Сәлимшина-Шаһимәрданова*
72 2021 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

ӘДӘБИ МИРАС

74 Суомида татарлыкны дәвам иттерүче. *Х.Миңнегулов*
80 Такташ һәм Сирин. *Ә.Шәрипов*
84 Фәтхи Бурнаш һәм шәһри Казан. *Н.Каштан*
87 Белмим, үзең сизәсеңме...
88 «Ялкын»лы ялкынлы еллар хатирәсе.

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

90 Илдар Юзеев вафаты (1933-2004). *Л.Лерон*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

94 Гомәр Бәшировның фотомирасы. *З.Бәширов*
97 «Казан мәгарәсе»ндә очрашу. *Ф.Закиров*
102 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
104 Истә, һаман да истә!

ФИКЕР ДӘРЬЯСЫ

106 Яһүдләрчә. *Р.Садриев*

СӘНГАТИ МИРАС

110 Татар җырчылары. З.Гыйльметдинова
112 «Туган тел» җыры

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Гыйнвар*

Заказ №А-3514. Тираж – 2810 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 26.12.2020. Чыгу көне: 30.12.2020.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: һади Такташ улы Рафаил белән. 1928 ел. Фото Лена Гайнанова архивыннан алынды.

Телсез халык үзе дә була алмый,
халыксыз тел дә юк.

Гомәр Бәширов

Гомәр Бәширов хатыны Кәримә белән. ***Зөфәр Бәширов фотосы***

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Гомәр Бәширов

(7.01.1901-7.05.1999)



* * *

Язучы һәрвакыт, бөтен гомере буена ни дә булса язып тора. Ул язмыйча яши алмый. Иҗат эше аның рухи ихтыяҗына әйләнә.

* * *

Халык иҗаты ул – халыкның байлыгы. Ул халык белән бергә яши.

* * *

Әдәби телнең сүз составын баетырга ярдәм итүче төп чыганакларның иң бае, – билгеле, халыкның җанлы сөйләшү теле, төрле шивәләр.

* * *

Бик билгеле нәрсә бит: сүз, нәкъ үз урынына туры килгәндә генә, бөтен нурлары белән балкый, бары тик үз оясында гына музыка булып яңгырый. Әгәр аны, тегеннән-моннан гына эләктереп алып, чит-ят ояга ябып куялар икән, ул, шыксыз үрдәк баласы шикелле, зар елый.

* * *

Хәзерге тормышны тасвир итәме язучы яки борынгы заман турында язамы, аның күңел түрендә һәрвакыт, якты йолдыз булып, халык идеалы балкып торырга тиеш.

* * *

Халыкның иң зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, – һичшиксез, аның теле. Халык үзенең телен, оста бакчачы кебек, яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар куырудан саклап, мең еллар буена үстереп килгән, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә китергән.

* * *

Җиде санында иң әүвәл халыкның табигать серләрен күрә белүе чагыла: камка өстендә җиде нокта, кешенең һәм күпчелек тереклек ияләренең башында җиде тишек, кояш спектрында җиде төс һ.б. ■

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

«Күңелебезнең үз иленә чыктык!»*

Мирхәйдәр Фәйзи

Кабан күле

Казан – Шода

1923, апрель-июнь.

Пароход кузгалды. Яулыклар болгый-болгый аерылдык. Ямьле Ак Идел өстендә күңелле пароход белән алга киттек. Нинди рәхәт, нинди зур бәхет, нинди күңелле! Онытылып бетә язган бәхет алдыма килеп басып, ямьләр белән чолганып, иксез-чиксез бәхетле булдым. Бәхетле булмаска ни – күңелле бит пароходта бару. Күңелле, рәхәт бит ташып җәелгән киң җылгада – җитмәсә тагы, күңелләр тулып, Ак Иделдә аккош кебек пароход күкрәгендә тирбәлү.

1923 ел, май

1есендә ямьле Ак Идел буйларында күренеп калган татар авылларына тирән бер тойгы, зур бер мәхәббәт белән карап узам. Һәркайсында торасым, урамыннан узасым, кешеләрен күрәсем, чын ямь белән бизәләсем килә. Күзләрем кәгъбәсен күреп, күңелем дуслары белән гаибанә серләшеп, телләрем күңел сизенүләрен җырлар аша ирештереп, бәхетле булып барам.

Мин китәм сездән каһәрләр яудырып!
И шәһәрнең мәңге мәгърур коллары!
Саф күңелдән гөлләремне тамдырып,
Мин барам сезгә, авыл юксыллары!..

* Көндәлекләрдән кыскартып бирелә. – ***Ред.***

Бирски каласына туктап уздык. Ак Идел гаҗәп рәвештә бормаланып ага. Тагы шунысы бер кызык: сөйләшкән татарлардан һәммәсе диярлек мине белә, ягъни «Галиябану»ны белә, бик тиз танышабыз, танышу бер дә кыен түгел.

2сендә. Кайсы җирләрдә Идел диңгез кебек җәелеп, очы күренми ята. Бик күңелле. Пароход та шәп кенә йөзә. Авыллар кала, ямьле җир үтелә. Көн һәйбәт. Тирә яхшы ук яшәреп килә. Агачларда сандугачлар сайрап, күңелне җилкендерәләр. Бөтен тирәмдә ямь, күкрәгем дә авыртмый. Сапсаумын.

Пристаньда бер татар хатыны белән озак мөсахәбә ясадым. Бу типичный татар хатыны миндә никадәр тәэсир ясаса, мин дә аңа шулай ук тәэсир иткәнмен. Пароходтагы берничә кешегә мине мактап өлгергән. «Шулкадәр җагымлы булыр икән лә бәндәсе», – дип әйтә, ди. Пароход кузгалганда, әллә ничә рәт исәнләшеп озатып калды. Чүт яулык кына селкешмәдек. Кояш баеп барганда пароход өстеннән Пьяный Бор күренеше күңелемә бәйрәмнәр бирде.

Кич ялгыз гына палубада җырлап барганда, яныма бер егет килеп: «Утырабызмы?» – диде. «Утырыйк», – дидем. Утырды, таныштык. Татарстан 6 нчы коммунист яшьләр өлкә съездына Минзәлә кантоныннан делегат булып барган, Актаныш авылы комсомолының секретаре Мөбарәк Арсланов дигән егет икән. Бу миңа кадерле бер танышу булды. Рәхәтләнеп сөйләштем. Моның белән инде бөтенесен сөйләшеп була. Бу тирә комсомоллары хакында мәгълүматлар бирде. Үзе ямьле, дәртле, көчле егет икән! Төннең байтак өлешен күңелле сөхбәт белән үткәрдек.

3сендә. Без хәзер Татарстанда. Кичә Татарстан җиренә керү белән Мамадыш егете белән икәүләп күңелебезнең үз иленә чыктык дип куанышып алдык без.

Чистай пристанендә әтинең Ватанына чыгып аяк бастым. Әти-әниләрне уйладым. Пристаньдагы бер кешедән туганнарны сораштырып карадым. Вак салучы бер татар малае белән сөхбәт иттем.

Волгага чыктык. Су тагы да киңәйде. Гаҗәп инде. Уфадан чыкканнан бирле Ак Идел, Кама, Волга суларында йөзеп, Вятка суын күреп, дүрт зур җылганы таваф итү насыйп булды.

Пароходта намазын калдырмый барган бер суфи мөселман бар иде. Бу татарга күңелем бер дә якынлык сизмәде. Үз кешем итеп карый алмадым. Сөйләшмәдем.

Богородскийда бер пароход белән бәрелешә яздык, курыктык.

Кич пароход палубасында Мөбарәк Арсланов белән бик озак сөйләшеп бардык. Пароходлар үтә, әллә нинди утлар җылкылдый, күңелле! Бу комсомолец миндә тулы гына тәэсир калдырды. Яраттым яшь эшчене, көчен хезмәткә багышлаган яшь игенчене.

4есендә иртә сәгать 5тә Казан күренде. Бүген бит Гает көне. 3 мөселман (берсе камчылы ишан баласы) гает укыды.

Әйе, Казанга җиттек. Уфадан мең чакрымлык юлны дүрт төн кунып килеп җиттек. Пароход Бишбалтага туктады. Җиңел ямщиклар юк, әллә ничә кеше кушылып, ломовой яллап, дыңгырдап киттек. Мин «Болгар»га төштем. Номер бик матур түгел. Рәткә салынып бетмәгән әле.

Татарлар ду килеп бәйрәм итә. Көн буе номер тәрәзәсендә бәйрәмчеләрне тамаша итеп утырдым. Бер картина бик кызык тоелды: ирләр һәммәсе диярлек каракүл бүректән, кыз-хатын калфактан, шәлдән. Башка киемнәре һәммәсе Европача. Эсседә

каракүл тиресе каплап йөрү бик җиңел түгелдер, әлбәттә. Ләкин Татарстан булу җәһәтеннән караганда, үз кием-нәрендә күренү ямьсез тоелмый.

5есендә. Бик уңайсыз чакка туры килдем. Дүрт көн бәйрәм итәләр икән. Бәйрәмне өйдә генә үткәрергә карар бирдем. Шулай да Зур Проломныйга барып әйләндем. Кабан күле янында байтак ирмәкләндем. Их, күңелле Кабан өсте! Көймәдә йөрүчеләр белән тулган. Татар егетләре, гармун белән әйттереп йөреп, җанымны рәхәтләндерделәр. Казанга килүем белән, җан азыгым белән каршыландым. Казан, күңелем газиз байлары белән куандырып, өметләр бирде. Берәр нәрсәгә кызыккан малай төсле, гармунлы көймәләрнең артыннан ияреп йөрдем.

Кич Дәүләт татар театрына бардым. Тинчуринның «Сакла, шартламасын!» дигән комедиясе куелды. Театр Уфаныкының яртысына да җитмәсә дә, уютный гына, матур гына икән. 20 сумга билет алып кердем. Габдессәлам Хаҗиев та килгән, бергә йөргәләдек. Сәхнәдә Әпсәләмовны гына танып утырдым. Шәп уйнадылар. Ну Әпсәләмов чукындырып чыгарды соң! Кыланмыйча, табигый чыгарган көлкеләре белән шартлата язды! Тагы Болгарская, Колмәмәт, Терегулов, Мәҗидов, Әхмәрова дигән артистлар уйнадылар. Әпсәләмовны пәрдә саен алкышладылар.

7сендә бәйрәм иткән булып тәмле мәмиләр, пирожныйлар, кәнфитләр алып кайттым. Кичкә таба байтак гомеремне Кабан күле буенда үткәрдем. Татар малайлары гармун, скрипкалар белән чукындырып уйнап йөриләр ки, әлдә яхшы, Казанга килгәнмен. Ярый әле мөхәррир булганмын, ярый әле Казанга йомышым төште. Югыйсә татарның йөрәге булган Казан иленә килеп, күңелебезнең үз Кабаны булган ямьле су өстендәге бу бәхетле күренешләрдән мәхрүм булыр идем. Мин инде Казанда җыларга теләмим. Матур да ул, зур да ул, ямьле дә ул, ямьсез яклары белән куркытмый да ул. Миңа алар белән йөрү эләкми әле. Әмма су читеннән торып, су өстеннән тирбәнеп килгән гармун тавышын тыңлау анда йөрүгә караганда да ямьлерәк. Ахырзаман җитә, диләр, йөреп калырга кирәк.

17сендә дүрт-биш көн томау белән номерда авырып яту аркасында, көнлек хәлләремне рәтләп яза алмый калдым. Шушы 10 көн эчендә иске танышлардан Гобәйдулла Буби, Якуб Хәлили, Хәбибрахман Зәбири, Әпсәләмов, Сәмигулла Салихов, Зөһрә Салихова, Гайшә абыстай Хөсәенова, Гаяз Максудов, Зәки Вәлиевләр белән күрештем. Яңалардан: Ш.Рәмзи, Әхмәт Гомәров (Главлит башлыгы), Балтанов (Наркомпрос комиссарының замы), Г.Кәрәм, Мөхәммәт Кулиев, Мохтаров (Татпечать түрәсе), Һашим Салихов, Шәфика Салихова, Закир Сәйфи, Габдерахман Дәүләтшин, Хәлил Бакиев, Ибраһим Максудов, Колмәмәт (артист), Гали Ходаяров, Насих Мохтаров, Ибраһим Кулиев, Әсма Хәлили, Кәрим Тинчурин, Заһидә Тинчурина, Галимҗан Ибраһимов, Хәсән Мостафин, Һади Такташев (шагыйрь), Толымбайский, Гали Галиев, Суфия Таһирова, Фатих Сәйфи-Казанлылар белән таныштым. Күңелем каршында мәхәббәте булган обкомол егете Газиз Мөлековны танышмый гына күрдем.

Тинчурин Кәримләрдә әллә ничә рәт булдым, чәй эчтем. Заһидә ханым да, Тинчурин үзе дә бик ямьле әсәр калдыралар. Тинчурин бик сөйкемле кыланды. Зур ярдәмнәр, уңайлыклар күрсәтте. Тиз генә пьесаларымны укып чыгып, рецензияләр язды, Наркомпросларга, Акадцентрларга бергә барып, йомышымны тизләтеп йөрде. Үзе



Болакның тулып аккан мәле. 1926 ел. ***А.Бренинг фотосы.***

дә кызыклы, зәвыклы кеше икән ки, тиз үзләшеп алдым, яратып аерылдым.

Татпечатьтә Ходаяров, Кулиев, Зәбири, Мохтаровлар белән күрештем. Ибраһим Кулиевка «Галиябану»ның ярты битен төшереп калдыруына ачуланып барган идем, тиз гафу әйтте. Бик ачык, простой кеше икән. Бер сүздән китапларымны бастырырга сүз бирде. Һәм мине тизрәк җибәрергә дә әмәл табып, хәзер 1 миллиард сум бирде дә, «Фәрештә», «Авыл бәйрәме»ләремне нәшер итәргә алдылар. Табагына 1 миллиардтан 7 миллиардка килештек. Акчасын бер айдан алырга булгач, арттырып бирергә дә булдылар. Шулай итеп мәсьәләне бик җиңел бетерделәр. Татарстан Башкортстан түгел икән шул!

Казанда бер частный ширкәт – «Корылтай» бар икән. Башында торган Насих Мохтаров белән барып күрештем. Ул да бер пьесамны алып бастырмакчы булган иде, хәзерге пьесам җитми калды. Нашир артты.

Галимҗан Ибраһимовка барып, хуш кабул ителдем. Бик ачык каршылады. Олуг мөхәррир янында озак сөйләшеп утырып чыктым. «Галиябану» хакында да, каләмем хакында да матур сүзләр ишетеп сөендерде. «Авыл тормышын нечкә аңлап, аны садә, җиңел, матур итеп күрсәтә алуда син ялгызсың. Бу тормышны тасвир киләчәктә дә синең монополияңдә калыр», – диде. Киңәшләр бирде. Сөендерде, яшәтте, үстерде. Күңелемнең хөрмәтлесе булган зат тагы да күңелемне җәлеп итеп калды. Гади генә, дусларча гына карап, иркәләп кенә сөйләшеп, чын бер олуг кеше икәнен күрсәтә белде. Аннан алган ямьле тәэсир белән күңелем, хатирәм тулды. Галимҗан Ибраһимов янында яшь шагыйрь һәм мөхәррирләрдән Һади Такташев, Толымбайский, Гали Галиевләр белән таныштым.

Главлитта яшь кенә, нәни генә бер Кулиев (Мөхәммәт бугай) белән таныштырганнар иде. Бу сөйкемле егет тә күңелем каршында ниндидер бер хак казанды. Йомыш белән барган чакларымда бик матур кыланадыр иде.

Казан миндә яхшы эз калдырды. Монда торырга димләделәр. Г.Ибраһимов та Казанда торырга киңәш бирә.

Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге. 1920 ел

Шундый сәбәпләр белән: «Кыш Казанда торыргамы әллә?» – дигән уй туды.

Садыйкка хат яздым. Орскига: «Шодага барам», – дип телеграмм бирдем.

* * *

Бүген сәгать 5тә Екатеринбургка поезд китә иде. Мин дә шуңа хәзерләндем. Номерга 14 көнгә 377 миллион сум түләп чыктым. Извозчик алып, вокзалга төштем. Билетларны да носильщиктан алдырып, үзем нәрсәләрем яныннан аерылмадым. Шәймәрдәнгә кадәр билет 30 сумга алдым. Носильщик вагонга кертеп урнаштырды. Сәгать 5не суккач, Казаннан кузгалып киттек.

Товарный вагонда бару кызыклы түгел инде. Йөрер хәл дә юк. Тик утырып кына барам. Тирәне рәхәтләнеп карарга тагы уңайсыз. Әллә никадәр авылның татар егетләре кереп, гармуннары булып чыкты. Уйнап, җырлап барып рәхәтләндерделәр. Алар гел уйнадылар, мин гел тыңладым, һич туймадым.

Төнлә йокларга уңайсыз да булды. Шуның белән бергә, кайвакытта җитәчәгебезне белмәгәнгә, йокламаска уйладым.

18ендә, таң атып килгәндә, Шәймәрдәнгә җиттек. Юлда, хәзер сабан вакыты, ямщик булмас, дип куркытып килгәннәр иде. Үзем өчен авыррак булган ике кулымдагы ике багажымны сөйрәп, извозчик эзләп чапкалый башласам да, мәсьәлә тиз хәл ителде. Стансадагы бердәнбер агайны Шодага кадәр (45 чакрым җир) 250 миллионга яллап, шундук кузгалып та киттек. Кыйбатсынганнар торып калдылар.

Яңа гына яктырып килгән чак, тирә кругом агачлык, сандугачлар сайрый, бозтургайлар чүтләде. Шулкадәр матур, шулкадәр күңелле ки, уф, дип, бер рәхәтләнеп тын алдым. Урманның язгы яшеллекләрнең хуш, җиңел исләреннән күкрәгемне киереп-киереп иснәдем.

Кояш та чыкты. Тирә гаять ямьле. Әле урман эченнән барабыз, әле аланнан. Төрле агачлы урманның кояш чыккан чакта күгәреп, төрле яшелләрдән бер букет булып читтән күренеп утыруын сокланып-сокланып карыйм. Никадәр

карасам да туймыйм, рәхәтләнәм, зәвыкланам.

Юлда бер татар егете очрап, ул да килешеп безгә утырды. Бу ямьле, ипле генә егетнең эштән кайтып килгән бер авыл егете икәнен белгәч, миңа тагы күңелле булып китте. Ачлык елны иленнән чыгып киткән, Мәскәү тирәсендә бер электрический стансасына эләгеп, яхшук матур киенгән, хәзер авылына кайтып барган, Янгол Иле авылының 19 яшьлек Әхмәди Мөхәммәтшин дигән малай икән. Аның белән тиз дусландым.

Ямщикның авылы – Борбаш авылына кереп чәй эчтек. Әхмәдинең авылы моннан 7 генә чакрым икән. Йөрәге ярсып тора. Ничек итеп кайтып күрешәм дип түземсезләнә. Өс-башы ару, әнкәенә дә күлмәкләр, күчтәнәчләре бар. Их, күңелле инде аңа өенә кайту. Ул элек бер малай гына булып чыгып киткәндер инде. Хәзер тәмйиз бер егет булып кайтып керә. Сабынлап җуынып, итекләрен кремлап тазартып, киемнәрен щеткалап хәзерләнүен тирән бер зәвык белән карап тордым. Чынлап та, күңелле бит!

Их, алама да инде бу якның юллары. Җитмәсә тагы, такта арба. Һичбер йөртеп барыр хәл юк. Безнең як юллары кебек рәхәт булу кайда ул!

Янгол Иленә җиткәндә Әхмәди, кертеп чәй эчереп җибәрәм, дип бәйләнә башлады. «Махсус кунакка килермен», – дип карасам да, ышандыра алмадым, кыстап алып керде. Әнкәе белән күрешкәндә җылаштылар. Бик кадерле кунак булып каршыландык. Әнкәе Ләтифа карчык Сәетгәрәй абзыйларны да белә икән. Бары белән сыйлап, күңелләнеп йөрде. Бик күңелле булды. Киткәндә Әхмәди белән дустанә күрештем. Җыенга кил, дип чакырып калдылар. Шулай итеп авыл егете белән рәхәт уздырдым ярты юлны.

* * *

Юлның катылыгы тәмам изде. Һич йөртер хәл юк. Урбар, Пабайнур авылларын үтеп, сәгать 5тә Шодага җиттек. Меңнәрчә чакрым җирдә булып, барып җитә алу хыял кебек кенә күренгән Шодага җиттем. «Ни хәлдәләр икән?» – дип, куркып кына килеп керелде, әлбәттә. Йорт-җирләр төзек, борынгыча шәүкәтле хәлдә күзгә чалынды. Җиңги бакчада йөридер иде. Күрешү белән саулыкларын сорашып, тынычландым. Сәетгәрәй абзый да кайтып җитте. Балалары Һашим, Икрам, Әхмәт, Мөхәммәтләр дә өйдә. Зур куанычлар булды. Сәетгәрәй абзыйның сул гына фикерле мулла булуы, угылы Сәгыйтьнең коммунистлыгы аркасында, революция вакытларында да әйтерлек зарар күрми, ачлык елында да бик изелми, хәзер дә ару гына торалар икән. Уңай булып, тыныч булып, күңелле булып калды. Сәгыйть өйдә юк.

Шулай итеп рухан коммунист, дин хөкемнәренә ригаясез бер эне мулла агага кунакка килде. Тату торыр өчен рияләнергә мохтаҗ булынырмы, әллә турыдан-туры китәргә дә юл табылырмы, киләчәк күрсәтер. Абыемның халык арасындагы авторитетын какшатмас өчен, мәчеткә барып маташсам, үз юлым өчен бик зур җинаять, вөҗданым өчен бик зур газап инде ул. Безнең яшь дәртләр гаҗиз калырга тиеш түгел!

Мине элекке килгәннәрдә күңелемне сихерләгән «кечкенә өй»гә урнаштырдылар. Их, күңелле бу бүлмә! Шушындый матур бүлмәдә генә язып ятсаң икән... Куш тәрәзәле, клеенкалы ишекле, курчак өе кебек кенә бер өй. Җиһазы матур. Һавасы җиңел. Арып килгән кеше, йомшак урында рәхәтләнеп йокладым.

Текстны басмага
Рәйсә Шәрәфиева *әзерләде.* ■

КЫП-ЧАК-ЛАР

Кыпчак түрәсе. XIII гасырның беренче яртысы. *М.В.Горелик реконструкциясе*

КЕМНӘР СОҢ УЛ КЫПЧАКЛАР? АЛАРНЫҢ ТАТАР ХАЛКЫ ҺӘМ ТЕЛЕ ФОРМАЛАШУДАГЫ РОЛЕ НИ ДӘРӘҖӘДӘ?

Кыпчаклар турында русның иң мәртәбәле галимнәре В.Бартольд, С.А.Плетнева, Л.Гумилев бары тик яхшы яктан гына язган.

Кыпчаклар белән бәйле «дәште кыпчак», ягъни «кыпчак даласы» дигән төшенчә кулланышка керә.

Димәк, кайчандыр алар биләгән территория – иксез-чиксез дала – хәзерге Россия һәм Украина, күпмедер дәрәҗәдә Казакъстан җирләре.

XII-XIII гасырларда кыпчаклар Дунай, Днепр, Идел, Урал (Җаек), Иртыш елгаларының урта һәм түбәнге агымнарында, Кара, Каспий, Арал диңгезләренең, Балхаш күленең төньяк ярларында дәүләт корган, күчмә һәм утрак тормыш алып барган (КАРТАНЫ КАРАГЫЗ).

Кыпчаклар РУС КЕНӘЗЛӘРЕНЕҢ ЯРДӘМЕ белән берничә мәртәбә Киевны һәм башка дистәләгән рус калаларын яулап ала.

12 нче йөз ахырында иҗат ителгән «Слово о полку Игореве»да Игорь Святославичның кыпчакларга 1185 елгы уңышсыз явы тасвирлана.

Шулай ук кыпчаклар ҮЗЛӘРЕНӘ КАРДӘШ БУЛГАН болгарларга – Идел буе Болгар дәүләтенә дә һөҗүм итә, калаларын яулап ала.

Кыпчак гаскәре җиңел һәм авыр коралланган җайдаклардан гыйбарәт. Алар сугышта хәйләкәрлекләре, җитез булулары һәм тактикада осталыклары белән аерылып торган.

1223 елда Төньяк Кавказда һәм Калка елгасы буендагы сугышларда

Кыпчаклар биләгән мәйдан. XIII гасыр

кыпчаклар монголлар тарафыннан җиңеләләр. Әмма җиңелүнең уңай ягы да була: Идел буена килгән монголлар, кыпчаклар белән кушылып, тулысынча ассимиляцияләшә.

Шулай итеп, кыпчаклар 1240 нчы елларда яңа оешкан дәүләт – Алтын Урда халкының төп өлешен тәшкил итәләр. Сүз уңаеннан: болгарлар әлеге дәүләттә кечкенә утрау гына булып кала.

Ә ИҢ МӨҺИМЕ – туган телебез ТАТАР ТЕЛЕ ТӨРКИ ТЕЛЛӘРНЕҢ КЫПЧАК ТӨРКЕМЕНӘ КЕРӘ!

Татар әдәбиятының иң затлы әсәрләре – «Кодекс Куманикус» – «Коман мәҗмугасы», Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е, Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә»се, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗелфәрадис»е, Сәйф Сараиның «Китабе Гөлстан»ы кыпчак телендә иҗат ителгән.

Кыпчаклар үзләреннән бай матди мирас та калдыра. Әлеге хәзинә Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Казан музейларында саклана. ■

Кыпчак яугире. XII-XIII гасырлар.
М.В.Горелик реконструкциясе

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Казан ханлыгы тарихы

Җөри хан турында риваять

Рәшит Галләм

Борынгы шәһәрдә сәүдә мәйданы. ***Ф.Г.Халиков рәсеме. 2003 ел***

Хәзерге Теләче районының Иске Җөри авылында электән сакланып килгән бу тарихи риваять безнең тарафтан 2014 елда район җирлегендә уздырылган экспедиция барышында ул вакытта төбәкне өйрәнү музее директоры булып эшләгән Әлфия Белаловадан язып алынган иде. Риваять төбәкнең шул чордагы Җөри хан атлы җирле идарәчесе искә алыну белән кызыклы.

Теләчедән ун чакрым чамасы ераклыктагы Иске Җөри авылы Югары Мишә агымының сул як яр буенда урнашкан. Аның биек елга тугае ярындагы борынгы каберлегендә хәзергәчә сакланып, Казан ханлыгы чорына караган язулы каберташ авылның кадимилеген раслый.

Мәгълүм булганча, Казан ханлыгында, Арча, Алат, Гәреш, Нугай административ даругалары ише салым өлкәләре белән беррәттән, Җөри даругасы (өлкәсе) дә булган. Үз чиратында, алар, ханлык башкаласы Казаннан дәүләтнең төрле тарафларына илтүче олы юлларга (трактларга) бәйле оешып, йә шул тарафтагы бер зур, әһәмиятле торак пункт (мәсәлән, Арча, Алат калалары), йә булмаса, шул тарафта яшәгән төп кавем, сыйнфый-этник катлам исеме белән аталганнар (мәсәлән, Нугай даругасы һ.б.). Халкы Казанга кайсы юлдан (тракттан) йөрсә, авыл-калалар да шул административ даругага (өлкәгә) караган. Әйтик, Арча юлыннан йөрсә – Арча даругасына, Алат юлыннан йөрсә – Алат даругасына һ.б.

Казан ханлыгында «Җөри даругасы» дип аталган зур бер салым өлкәсенең булуы авылның ул чорда административ әһәмияткә ия торак пункт икәнлеге турында сөйли. Ул заманнардагы Җөри тракты (юлы) үзенең төп конфигурациясе, юнәлеше буенча, мәгълүм дәрәҗәдә, хәзерге Мамадыш, Чаллы трактларына тәңгәл килгән. Олы юл буйлап урнашкан авыл-калалар ханлыкның Җөри административ даругасын тәшкил иткән.

Соңрак, инде Мәскәү дәүләте шартларында, Казан өязенең Җөри даругасына хәзерге Татарстанның Чулман аръягындагы көнчыгыш җирләр дә кергән. Гомумән алганда, ханлык чорыннан калган бер мирас буларак, Казан өязендә административ даругаларга бүленеш 1781-1782 нче елларга тикле сакланган.

Казан ханлыгындагы даругаларның, салым өлкәләре генә булмыйча, анда яшәгән аерым аксөяк нәсел-ыруларның (Шириннарның, Аргыннарның һ.б.) ниндидер бер ярым мөстәкыйль билекләре («кенәзлекләре») булуы турында да фикер яшәп килә. Әмма әлегә моңа ачык дәлилләр юк. Соңрак, Мәскәү дәүләте шартларында, аларның бары тик административ функцияләре генә чагыла.

Бәян ителгәннәр Җөри ханның шул чорда яшәгән реаль шәхес булу ихтималын инкяр итми. Ул ханлыкның Җөри даругасында яшәүче ясаклы игенчеләрдән дәүләт казнасына салым җыю өчен билгеләнгән җаваплы түрәсе, «даруга бәге», икенче төрле әйткәндә, «даруга-бәк» буларак күзаллана.

Әмма ни өчен соң Җөри риваятьтә хан дип атала? Күрәсең, бу очракта тарихи риваятьләргә хас традиция чагыладыр. Бу күзлектән караганда, ханлыктагы һәр җирле идарәче ул – «хан». Шуны да искәртик: Шомбыт елгасы буендагы борынгы Чаллы төбәге – «Чаллы кенәзлеге» идарәчеләренә карата да риваятьләрдә «хан» төшенчәсе кулланылган. Бәлки, бу аларның Чыңгыз хан нәселеннән булуларына бер ишарәдер?..

Инде хәзер риваятьнең үзенә мөрәҗәгать итик.

Җөри хан

Бик борынгы заманнарда хәзерге Иске Җөри авылы яныннан ага торган Мишә елгасы бик киң һәм бик тирән булган. Җөри хан, үзенең гаскәрләре белән яудан кайтканда, тау итәгендә ял итәргә туктаган. Ул, бу урындагы табигать гүзәллегенә хәйран калып, шушында шәһәр төзергә уйлаган. Ләкин, аксакаллар белән киңәшкәннән соң, Мишә елгасының киңлеге су юлы өчен җитеп бетми дигән фикергә килгәннәр. Үзләре хыялланган шәһәрне, ераграк китеп, хәзерге Казан урынына салганнар.

Ханның каланы Җөри урынында төземәвенең тагын бер сәбәбе булган. Кала төзелә башлагач, кызы Зөһрә хасталанып китә һәм вафат була. Ханның йөрәге кызының фаҗигасе белән бәйле урында яшәү белән килешә алмаган. Һәм ул бу урыннан киткән.

***

Иске Җөридәге борынгы каберлекнең халык телендәге исеме – «Хан кызы каберлеге»*. Шулай итеп, Иске Җөри авылының атамасы Җөри хан исеменнән килеп чыккан. ■

* Риваятьтә «Хан кызы каберлеге» дип сөйләнсә дә, эпиграфист галимнәр Раиф Мәрданов һәм Ирек Һадиев әлеге ташның 1516 елда вафат булган **Илкилде(?) Исмәгыйль улы** каберенә куелганын әйтә.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Шәмсуар йолдызлыгы

Фәүзия Бәйрәмова

Суар шәһәрлегенең аэрофотосы. 2005 ел

Суар – Гайнетдин Әхмәров хезмәтләрендә

Тарихчы Гайнетдин Әхмәров, бу урынны өйрәнү максаты белән, 1893 елда Кузнечиха-Суар якларына килә. «Экскурция на место древнего Сувара» дип аталган мәкаләсендә: «От татар я узнал, что около села Кузнечихи есть место большого древнего города, где очень часто находят разные старинные вещи», – дип яза галим. Ул җирле халыкның Кузнечиханы һаман элеккечә Суар яки Свар дип атауларына игътибар итә. «Название «Кузнечиха» известно только русским, а все инородцы (даже в Чистопольском, Лаишевском, Мамадышском и в Самарской губернии) называют это село именем древнего города Свар или Суар». Ягъни, татарлар – «Суар», ә чуашлар «Свар» дип әйтәләр, ди. Гайнетдин Әхмәров, бу урынга килү белән, үзен озата йөрергә биредә яшәүчене ала. Ул кешенең әйтүенчә, Суар төрки шәһәре була, башкала булып тора һәм ниндидер сугыштан соң җимерелә: «Справившись предварительно в местном Волостном

Ахыры. Башы журналның 12 нче (2020) санында

правлении о Суварском городище и о его находках, я взял себе в проводники местного старожила Емельяна Кузнецова, который мне, между прочим, изъяснил, что село носит такое инородческое название (Свар) потому, что здесь был очень большой турецкий город Свар (как они обыкновенно называют и все находки турецкими); здесь была их столица, разрушившаяся после какой-то войны».

Әйткәнебезчә, Гайнетдин Әхмәров, Суар шәһәре урынында булып, аны җентекләп өйрәнә, борынгы каланың өч яктан тирән урлар һәм биек валлар белән, ә дүртенче яктан Үтәк елгасы белән уратып алынганлыгын искәртә. Көнчыгыш яктан шәһәргә керү өчен ике капка була. Гайнетдин Әхмәров йорт урыннарын да таба, аларның күп чакрымнарга сузылуын яза. Ул барганда биредә арыш кыры була, автор Суарда баш сөякләреннән артык әйбер таба алмый. Кузнечихага кайткач, җирле халык (урыслар) Суар урыныннан бик күп борынгы әйберләр табуларын әйтәләр, чөнки элек анда арыш кыры булмый, ә җирне сөрә башлагач, сука калагы төртелә, чөнки табылдыклар шулхәтле күп була! Әмма гади халык кыйммәтле табылдыкларны бай хуҗаларына тапшырырга мәҗбүр ителә. Галим бу турыда: «В самом городке и в окрестностях, на пашне, находили прежде весьма много и ныне часто находят древние татарские вещи. Некоторые говорят, что они прежде целыми корзинками имели таких старинных вещей с этого городка. Один крестьянин нашел старинную серебряную тарелку, другой – целый кувшин татарских монет, третий – 60 кусков серебра, похожих на бороновый зуб, и все находки отбирали у них владельцы селения», – дип яза.

Шуннан соң Гайнетдин Әхмәров янәшәдәге Яңа Баран – Яңа Рәҗәп (хәзер – Чәчәкле) исемле татар авылына китә, бу авыл халкы да Кузнечиха алпавытына, Суар кырларында эшли икән. Ул биредәге кешеләр кулында бик күп борынгы табылдыклар барлыгын ачыклый, берничәсен үзенә дә ала, әмма калганнарын кыйммәт бәягә сатып ала алмый. «В этой деревне один татарин нашел большой серебряный браслет старинной формы; другой нашел медный молоточек, один конец которого служил печатью (с надписью), у одного хранится медный кистень с шишечками и прочими», – дип искә ала галим бу турыда.

Ризаэддин Фәхреддин: «Үзендә зур мәчет бар»

Ризаэддин Фәхреддин дә үзенең «Болгар вә Казан төрекләре» хезмәтендә Суарны әйләнеп узмаган. «Әлеге шәһәр турында гарәп тарихчылары болай дип язалар: «Бу шәһәр мәшһүр Болгар шәһәреннән бик ерак түгел. Үзендә зур мәчет бар, йортлары нарат һәм чыршы бүрәнәләрдән төзелгән. Кешеләр кыш көнендә шул йортларда тора, әмма җәй көннәрендә җәйләүләренә чыга. Бу шәһәр урынында хәзер рус авылы бар, диләр. Кятиб Чәләби: «Бәһҗәтел-әнвар мин хакыйкатил-әсрар» исемле әсәрнең язучысы – Сөләйман бине Давыд әс-Суари», – дип сөйли. Бу болгар шәһәре булган шушы Суар шәһәренә мөнәсәбәтле түгелме икән? Суарның бу көндәге Сакмар шәһәре булуын уйлаучылар да бар», – дип яза ул.

Болгар-Биләр төбәгендә яшәүче мишәр-татарлар өчен Суар – Кузнечиха авылы янындагы Суар инде ул, аларның кан хәтерләренә шулай кереп калган… Әйе, элек монда кала, бәйсез бәклек булган, хан-солтаннар дәүләт тоткан. Алар исеменнән монда акча сугылган. Шәһәрнең Җәмигъ мәчете, хан сарайлары, кәрвансарайлары, базарлары, мунчалары, һөнәрчеләре, гаскәриләре булган…

«Ун мең кешелек шәһәр» дигәндә, кулына корал тота алырлык ир-атлар гына исәпкә кергән. Димәк, шуның хәтле яки аннан да күбрәк хатын-кызлар, һәр гаиләдә дистәләгән бала, әби-бабайлар... Шуларны исәпкә алсаң, Суарда да йөз меңгә якын кеше яшәгән дигән фикер туа.

Сәет Вахиди: «Бик күп чүлмәк ташлары бар»

1928 елның җәендә танылган археограф, галим Сәет Вахиди, борынгы ядкярләр җыю максатыннан, Спас кантонында фәнни сәфәрдә була. Ул, үзе дә шушы төбәк кешесе буларак, алдан ук эш планына уннан артык авылны кертә, шулар арасында Суар да бар. Сәет Вахиди турында җыентыкта бу сәфәрнең өлешчә генә хисабы басылып чыккан, әмма Суар, Йорткүл, Иске һәм Яңа Рәҗәпкә караган урыннары кертелмәгән. Алай да, Сәет Вахидиның кульъязмасыннан булса да, аның Суарга караган өлешен язмабызда файдаланырга булдык. Кульъязма Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә саклана.

«Суар шәһәренең урынында инде бүген зур гына урыс авылы тора. Шәһәрнең ныгытмалары, курганнары кайда икәнлеге турында без юлда очраган урыслардан сораша бардык. Мондагы урыслар Суар шәһәрен «Турецкий городок» дип йөртәләр. Димәк ки, халык зиһенендә бу шәһәр хәрабәсе һәм хуҗаларының исемнәре белән дөрес танылып калган. Авыл урыслары бик иске вакытлардан бирле бу би төрекләрен ялгышмыйча, дөрес хәтерләп киләләр икән. Суар шәһәренең берничә ныгытмасы бар икән. Безнең вакытыбыз бик аз булганлыктан, бу курганларның барын да тәфсилле рәвештә тикшереп йөри алмадык. Шулай да Суар шәһәренең берничә ныгытмасын тикшердек. Суар шәһәренең хәрабәләре урынында бик күп чүлмәк ташлары бар, әмма андан табылган иске нәрсәләрне урыс авылына барып тикшереп, сорашып йөри алмадык. Суар шәһәренең хәрабәләрен карагач, андан башка Рәҗәб аркылы Иске Рәҗәб авылына киттек...»

Сәет Вахиди

Сәет Вахидиның бу кульъязмасында яңарак фикер булып курганнар темасы тора, әмма ул ачылып бетмәгән. Сүз нинди курганнар турында бара, әллә галим каберлекләрне шулай атаганмы? Аның «би төрекләре» дигән атамасы да тарихи чынбарлыкка туры килә, әмма «би төркиләре»н беләр дип аңларга кирәктер. Урысларның Суарны «Турецкий городок» дип атаулары да шул ук «төрки-татар шәһәре» дигәнне аңлата инде ул. Сәет Вахидиның бу хезмәтенә без әле тагы тукталырбыз, ә хәзер фәнгә аның артыннан килүчеләргә сүз бирик.

Археологлар – Суар турында

Узган гасырның 70 нче елларында бу төбәктә тарихчы Равил Фәхретдинов та була һәм анда эзләнүләр алып бара. Үзенең «Шәм Суар» дип аталган мәкаләсендә ул Суарның борынгы тарихына анализ ясый, каланың үзенә, бәк-ханнарына, алар суккан акчаларга, халыкның яшәү рәвешенә бәя бирә. Галим Суарны өйрәнү тарихына, фәнни әдәбиятта аның исеме кайсы чорга кадәр чагылыш табуына да туктала: «Суарның исеме көнчыгыш әдәбиятында соңга таба да очрый әле. XIII гасыр географлары Якут һәм Фәхретдин Мөбарәк шах Мәрвәретдин, 10-11 нче йөз авторларына таянып, Болгар белән Суар шәһәрләрен телгә алып үтәләр. Ә 14 нче йөз фарсы язучысы Хәмдулла Суарны Алтын Урданың һәм болгарларның зур шәһәре дип атый. Бу – Суар турында соңгы тарихи мәгълүматлар. Шуннан соңгы язма истәлекләрдә аның исеме күренми».

И.А.Износков әле 1895 елда ук Суар шәһәрлеген археологик картага төшергән. Ә археологлар үзләре булганмы соң бирәдә? Әйе, алар да, Суарда булып, казу эшләре алып барганнар, бу җирлекне фәнни яктан өйрәнгәннәр. Әйтик, 1917 елда биредә профессор В.Ф.Смолин була һәм беренче казу эшләрен башкара. Заманында Гайнетдин Әхмәров та Суарга аның тәкъдиме белән килгән була. Смолин шулай ук халыктан кайбер кыйммәтле табылдыкларны да сатып ала. Ә күләмле, планлы зур казу эшләре 1933-1937 нче елларда Мәскәү археологы А.П.Смирнов тарафыннан башкарыла. Аның тарафыннан ачылган бай йорты соңыннан Суарның визит тамгасына әйләнә, ул картиналарга, китапларга күчә. Әмма, вакытлар узу белән, ул йортның нигезен яңадан ябып куярга мәҗбүр булалар, чөнки кирпечләре кар-яңгырдан уалып, юкка чыга башлый.

1974-1975 нче елларда Суарда казу эшләрен Смирновның шәкерте Т.А.Хлебникова дәвам итә. Ә 1990 елда археолог Р.Ф.Шәрифуллин һәм Фаяз Хуҗин җитәкчелегендәге экспедиция монда кабат эш башлый, галимнәр өч җәй буе борынгы Суарны өйрәнәләр. Алар да күп кенә савыт-саба, чүлмәк ватыклары, бизәнү әйберләре, ук очлары, ачкычлар, төзелеш калдыклары, йорт урыннарын эзләп табалар. Бу ядкярләрнең күпчелеге хәзер Болгар һәм Суар музейларында саклана. Кызганыч, хәзер Суарда казу эшләре алып барылмый.

Суар әле ачылмаган планета

Әлбәттә, мең ел элек даны бөтен тирә-юньгә таралган, һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге булган Суар өчен бу аз, бик аз! Әлеге кырлар инде гасырлар буе кат-кат сөрелгән, таланасы таланган, җир өстендә борынгы шәһәрдән таш өстендә таш калмаган. Ә җир астында хәзинә бар әле һәм бик күп ачылмаган серләр саклана… Шуңа күрә «X-XIV гасырлар Суар шәһәрлеге» федераль дәрәҗәдәге ядкяр булып санала, тарихи тыюлык булып исәпләнә һәм 1998 елдан Кузнечихада Болгар музееның филиалы эшли.

Без дә бу тарихи төбәк белән танышуыбызны нәкъ менә шушы музейдан башладык… Без дигәнебез – Чаллыдан мин, тарих фәннәре кандидаты, язучы Фәүзия Бәйрәмова, Аксубай районының Түбән Татар Майнасы урта мәктәбе директоры, тарих фәннәре кандидаты Рафик Насыйров, Болгардан аталы-уллы тарихчылар Җәмил һәм Илшат Мөхәммәтшиннар.

Суар музеендагы экспонатлар

Безне биредә Суар музее директоры, үз эшенең зур фидакяр-патриоты Нинель Мәсгут кызы Садриева каршы алды һәм озатып йөрде. Шунысын да әйтергә кирәк: Нинель ханым Суарны беренче ачучы, тарихчы һәм дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең ерак туганы да әле. Ул – аның бертуган энесе Садретдиннең оныкчыгы. Нинель ханымның әтисе Мәсгут Арча районының Ташкичү авылыннан. Заманында ул шушы якларга эшкә җибәрелә, биредә рус кызына өйләнә һәм монда төпләнеп кала, балалары да Кузнечихада туа. Нинель Садриева, Казан дәүләт педагогия институтын читтән торып тәмамлап, гомер буе туган ягында яши һәм эшли. Мәктәптән башланган хезмәт юлы, тарих белән нык кызыксынуы сәбәпле, аны шушы музейга китерә. Ул биредә инде утыз ел эшли, Хезмәт ветераны, мәгариф отличнигы.

Узган гасырларда бер урыс баеның бинасы булган бу йорт соңгы елларда заманча ремонтланган, әйткәнебезчә, хәзер Болгар музей-тыюлыгы канаты астында яши һәм эшли, шуңа күрә аңа игътибар да башка. Музей Кузнечиха дип аталган рус авылына урнашкан, ул Суар шәһәрлегеннән аз гына читтәрәк. Бу урында Кузнечиха авылы турында да бераз мәгълүмат биреп үтик. Әлбәттә, монда Суарга хәтле дә кешеләр яшәгән, авыл уртасында 15 мең еллык ядкярләр табылуы шул хакта сөйли. Әйткәнебезчә, Суар каласы заманында үзе дә шушы авыл урынына кадәр таралып утырган. Безнең фикеребезчә, биредә татар тормышы Болгар һәм Алтын Урда чорлары белән тәмамланмаган, ә Казан ханлыгы юкка чыгарылганчы дәвам иткән.

Аннан соң инде бу җирләр урысларга бирелгән, борынгы төрки-татар шәһәрләре өстендә урыс крепостьлары барлыкка килгән. Болгар, Биләр, Суар җирләренә хәрби стрелецлар килеп тулган. 1691 елда әлеге җирләр Спас монастыре тимерчесе Дорошко Гавриловка бирелә, төрле яклардан качкын крестьяннар килеп урнаша. Әмма бу хәл патша хакимиятенең ачуын чыгара. 1703 елны махсус отряд килеп, авылны ут төртеп яндыра. Шуннан соң Кузнечиха берничә алпавытка бүлеп бирелә. XIX гасыр уртасында биредә инде мең ярым крепостной крестьян исәпләнә. Кузнечиха ул вакытларда ук зур урыс авылы, чиркәүле-мәктәпле волость үзәге

була. Шуңа күрә, биредә совет власте урнашкач та, ул үзәк булуыннан туктамый. 1930-1960 нчы елларда хәтта район үзәге дә булып тора. Хәзер исә Кузнечиха биш йөзгә якын кеше яши торган, урта мәктәпле, китапханәле, музейлы, шактый бетеренгән бер авыл. Халкының 90 проценты – урыслар. 1874-1878 нче елларда алпавыт Михаил Немирович-Данченко акчасына салынган таш чиркәү җимерек хәлдә. Дини йолалар янәшәдәге бер кечкенә бинада уздырыла икән...

«Суар табигате... Җәйрәп яткан тип-тигез кыр. Элек монда шәһәр булган дип һич кенә дә уйларлык түгел. Алай да, ур-чокырларга җитәрәк, аяк астында чүлмәк ватыклары очрый башлый.

Без Суарга сәфәребезне музейны караудан башладык. Тышкы ягы әллә ни булмаса да, эче шактый ук килешле, мәдәни рух бөркелеп торган бер җыйнак бүлмә иде ул. Һәм, әлбәттә, монда иң кыйммәтлесе – борынгы ядкярләр. Аларны археологлар казу эшләре вакытында да тапкан, музей хезмәткәрләре үзләре дә язын, кар эрегәч, кырдан җыеп алганнар. Бу табылдыкларга кимендә мең ел, аларның бер өлеше әле Болгарда да саклана һәм килгән халыкка күрсәтелә. Киштәләрдә, пыяла тартмаларда сугыш һәм эш кораллары да, йорт кирәк-яраклары да, хатын-кызларның энҗе-мәрҗәннәре дә кадерләп саклана. Музей директоры Нинель Садриеваның әйтүенчә, биредә ике меңнән артык ядкяр тупланган, әмма аларның барысын да күрсәтергә урын җитми.

Безнең игътибарны, эскпонатлардан тыш, Суар табылдыкларына багышланган берничә китап-брошюра да җәлеп итте. Алар – «Древний Сувар: археологические исследования и находки». Справочное пособие. 2009; «Древний Сувар». Каталог археологических находок. 2012; «Путеводитель по Спасскому району Республики Татарстан». 2012. Бу китапларның төп авторлары һәм җыеп чыгаручылары – Суар музее директоры Нинель Садриева һәм юридик фәннәр докторы, төбәкне өйрәнүче Альберт Хәйдәров. Ә аларга фатихасын биреп, кереш сүз язучы – тарих фәннәре докторы Фаяз Хуҗин. Альберт Хәйдәров – Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты укытучысы, галим, майор дәрәҗәсендәге яшь кеше, төбәк тарихы белән кызыксыну аны Суарга китергән. Бу эшләре өчен зур рәхмәт аңа! Альберт Әнвәр улына Казандагы мөмкинлекләре Суар өчен әле тагы күп яхшылыклар эшләргә ярдәм итәр дип өметләник! Әле бу урыннарның сканер белән сурәт-күчермәсен алып, җир астында кайда нәрсә ятканын ачыкларга кирәк. Ачыклагач, аларның иң әһәмиятлеләрен казый башларга вакыт... Суар әле ачылмаган планета, йолдыз, анда барыбызга да эш җитәрлек!

Суар табигате... Җәйрәп яткан тип-тигез кыр. Элек монда шәһәр булган дип һич кенә дә уйларлык түгел. Алай да, ур-чокырларга җитәрәк, аяк астында чүлмәк ватыклары очрый башлый. Шәһәрне әйләндереп алган урлар хәзер дә шактый тирән, коры елганы хәтерләтә. Суар каласы эчтән биек имән дивар белән сакланган, ул урыннарда хәзер куаклар үсеп чыккан. Урларның ар ягында, тыюлыктан бераз читтә, чуашлар килеп, үзләренең хәтер баганаларын утыртып киткәннәр, ул чүпрәк-чапрак белән тулган. Кызганыч, биредә татарларның тарихи Шәмсуар каласы булуы турында бер истәлек тактасы, бер билге дә юк. Шиһабетдин Мәрҗани дә, Гайнетдин Әхмәров та, башка галимнәр дә монда мөселманнарның борынгы зиратлары булганлыгын язып калдырганнар. Хәзер алар да юк инде...

«Мәчет кайда булды икән?» – дип сорыйм. Ялан кыр уртасында берничә төп каен агачы үсеп чыккан, мәчетне шунда булган, диделәр. Моны аэросъемка ярдәмендә ачыклаганнар. Шул урынга барып, тезләнеп намаз укыйм, динебез, илебез-җиребез өчен шәһит киткән әби-бабаларыбыз рухына дога кылам... Кем булсалар да, кайдан килсәләр дә, алар биредә тамыр җибәреп, ил-җирләр тотканнар, кала һәм салалар салганнар, ислам динендә булганнар, шушы урында намаз укыганнар...

Суар халкы кая таралган?

Кемнәр килеп, бу халыкның нурлы оясын туздырган, таш өстендә таш, баш өстендә баш калдырмаган? Таланган, йорт-җирсез калган халык кайларга таралган, кемнәр янына барып сыену тапкан? Бу сорауга тарихчы, үзе дә золым корбаны Сәет Вахиди җавап биреп калдырган: «Ташбилге кешеләре шәһре Болгарга, Бүләргә зиярәткә йөрергә изге эш дип карыйлар. Алар каршында шәһре Болгар, Суар, Бүләр бөтенләй үзләренең борынгы изге бабаларының шәһәрләре. Аларның риваятьләренә караганда, шәһре Болгарны әүвәле Аксак Тимер харап иткән, андан соң әле Болгар мәмләкәте тагы яшәгән, иң соңында шәһре Болгарны, Бүләрне, Суарны вә башка бөтен Болгар илен урыслар талап, шәһәр вә авылларны яндырып, малларын талап, халкының ирләрен үтереп, хатын вә балаларын тоткын иткәнләр. Менә шундан соң инде шәһре Болгар да, Суар да, Бүләр дә яңадан рәтләнә алмаслык булып җимерелгәнләр. Болгар иле урысларның һөҗүме белән һәлак ителгән». (Сәед Габделманнан углы Вахидинең хатирә дәфтәрендән бер кисәк / Рухи мирас. Эзләнүләр һәм табышлар. – Казан, 2017, 53 б.)

Әйе, татарларның илләре, дәүләтләре, таш калалары җимерелгән, халык та бик зур югалтулар күргән, әмма бөтенләй юкка чыкмаган! Бу гарасатлардан могҗиза белән исән калган халык, монда яшәргә көн беткәч, башка урынга барып сыенган, кемдер бик еракка – Кавказ, Төркестаннарга хәтле киткән, кемдер якын-тирә татар авылларына барып төпләнгән. Суар халкы белән дә шулай булган, аларның бер өлеше янәшәдәге татар авылларында тормышын дәвам иткән. Бу тирәдәге Иске Рәҗәп, Йорткүл, Чәчәкле, шулай ук Болгар-Биләр-Әлки төбәгендәге мишәр-татар авыллары, күршедәге Ульян өлкәсе татарлары – борынгы Суар халкының нәсел дәвамчылары. Алай гына да түгел, суарлар аша бортасларга, хәзәрләргә, һуннарга барып тоташа аларның бөек тарихлары!

Әйе, Суар әле ачылмаган, Суар әле өйрәнелмәгән, Суар әле үз сүзен әйтмәгән... Монда казу эшләрен яңадан башлап җибәрмичә, фәндә ул яңа сүз әйтелмәячәк тә. Әмма хәзер бөтен игътибар – Болгарда, галимнәр дә, туристлар да, акча да шунда. Суарны да Болгарның туристлык маршрутына кертергә була, әмма килгән халыкка нәрсә күрсәтәсең? Буш кырнымы? Шулай ук Кузнечихада туристлар өчен алып кереп ашатырлык, кертеп кундырырлык кунакханәләр дә юк. Музей эше дә бер фидакяр хатын җигелеп тартканга бара, әмма ул да өлкән яшьтә бит инде! Бу эшләр кабынган җирендә сүнеп калмасмы? Кемнәр дәвам итәр? Көн саен халкы кими барган Кузнечиха авылы үзе яшәп калырмы әле? Аның үзен дә борынгы Суар язмышы көтмәсме? Тарих кабатлана, диләр бит...

Суар турындагы бу мәкаләм фәндә нindидер яңа сүз әйтү өчен түгел, ә булган тарихны халыкның исенә төшерү, популярлаштыру максатыннан язылды. Гыйбрәт алу, нәтиҗә чыгару, алга таба маякларны билгеләү өчен, бу хәлләр бәян ителде. Бәлки, бездән соң да бирегә кемнәрдер килеп, әлеге тиңсез бөек тарихны өйрәнер, фәндә яңа сүзен әйтер, дөньяга Шәмсуар йолдызлыгын ачар дигән өмет белән язылды... ■

Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан

Секира

1881 елда Кама буенда табылган секира

Бронза зооморф секира ТР Милли музеенда тимер гасыр осталарының уникаль хәзинәсе булып тора. Ул 1881 елда Кама буенда табылган һәм Казан университеты профессоры А.А.Штукенбергка тапшырылган була.

Секира – борынгы һәм урта гасырлардагы салкын коралларның иң куркыныч төрләреннән берсе. Бу сүз латин теленнән «балта», чиркәү-славян фигыле «яру» һәм борынгы «пычкы» сүзе белән тыгыз бәйләнгән. Гадәттә, ул җәяүле сугышчылар тарафыннан кулланылган.

Милли музейда саклана торган секира – суда йөзүче хайванның йөзгече рәвешендә эшләнгән, яссы чөйле трапеция формасындагы балтадан гыйбарәт. Чөй беркайчан да кайралмаган. Секираның фигуралы түтәсе колаклары вертикаль рәвештә күтәрелгән, авызы ачылган зур бүре башы сыйфатында. Чөй һәм түтәне бөке белән тоташтыру алты һәм җиде валик рәвешендәге гофрировка белән гамәлгә ашырылган. Бөкенең югары очы спираль «алкалы» бөркет башы рәвешендә. Бу секира корал итеп файдаланылмаган. Ул хакимият символы буларак хезмәт иткән һәм Ананьино кабиләләренең ритуалларында кулланылган.

*Журналга **Ленар Нәгыймов** әзерләде.* ■

Татар китабы

Казаннан читтә татар китабын бастырган матбагалар

Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев



Петроград мәчете

Петербургта

XVIII гасыр ахырында Петербургта **Иоһанн Карл Шнор**ның «Азия» типографиясе эшли һәм анда татар китаплары да бастырыла. Императрица Екатерина II, татарларның үтенечләрен исәпкә алып, махсус фәрман белән хөкүмәт хисабына Шнор типографиясендә 1787 елда Россиядә беренче мәртәбә Коръән китабын бастырткан. Аннан соңгы 1790, 1793, 1796 һәм 1798 нче елларда Коръәнне тагын бастырганнар.

Бакчасарай шәһәрендә дөньяга килгән Кырым татары **Ильяс мирза Бораганский** 1894 елда Петербург шәһәрендә хосусый типографиясен ачкан. Бу типография 1840 нчы елларда, Казанда ачылган хосусый матбагалардан кала, Россиядәге беренче хосусый татар басмаханәсе булган.

Бораганский, Кырымда белем алгач, Төркиядә укыган. Шул чорда ул гарәп каллиграфиясен өйрәнеп, граверлык һәм рәссамлык серләрен үзләштергән. 1882 елда Петербургка барган. Анда Бораганскийның Шәрык әдәбиятын һәм күп телләр белүенә игътибар итеп, Петербург университетына каллиграфия

укытучысы һәм төрек теле лекторы итеп эшкә чакырганнар. Шәрыкны өйрәнүче галимнәрнең киңәше белән ул «И.Бораганский һәм ширкәте» типографиясен ачып җибәргән. Бораганскийның компаньоны Петербург ахуны Гатаулла Баязитов булган.

Петербургта гарәп хәрефләре белән китап бастыра торган матбага ачылу үз чорында башкала тормышында зур яңалык буларак бәяләнгән. Ул Шәрыкны өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләрен бастыру өчен кулай булуы белән бергә, татар һәм мөселманнарның мәдәни яшәешенә дә зур өлеш керткән.

«Бөтен Россиядә мөселман матбугаты көчле эзәрлекләнгән чорда Бораганский типографиясендә 1911-1917 нче елларда Шәрык телләрендәге китаплар чыкмаган.

Гатаулла Баязитов тарафыннан 1905-1914 нче елларда нәшер ителгән беренче татар газетасы «Нур» шул типографиядә басылган һәм әлеге матбага да «Нур» типографиясе дип аталган. Бу матбагада 1894-1900 нче еллар эчендә гарәп хәрефләре белән 270 мең данәдә 60 китап басылып чыккан. 1901-1910 нчы еллар арасында Бораганский («Нур») матбагасында 68 исемдәге татар китабы 148 440 данә тираж белән басылган. Югары полиграфия сыйфаты өчен бу типография медаль белән бүләкләнгән.

Бөтен Россиядә мөселман матбугаты көчле эзәрлекләнгән чорда Бораганский типографиясендә 1911-1917 нче елларда Шәрык телләрендәге китаплар чыкмаган.

Татар җәмәгать һәм дин эшлеклесе **Габдерәшит Ибраһимов** тарафыннан Петербургта 1906 елда икенче татар типографиясе оештырылган. Ул, нигездә, «Өлфәт» газетасын һәм бүтән вакытлы матбугат органнарын бастыру өчен ачылган булса да, анда китаплар да нәшер ителгән. Бу матбагада 1906-1907 нче елларда 25 исемдәге татар китабы 66 900 данә тираж белән дөнья күргән. «Өлфәт» типографиясе, эшли башлагач та, цензура һәм полиция тарафыннан эзәрлекләнгән, аңа штрафлар салынган, ябылган һәм яңадан ачылган...

1914 елда Петербург каласында Мөхәммәтгалим Максудовның татар типографиясе ачылган. 1914-1916 нчы елларда анда 24 исемдәге татар китабы 84 113 данәдә басылган. Бу типографиядә чыккан китапларның шактые Беренче бөтендөнья сугышы белән бәйле законнар турындагы басмалар булган.

Оренбургта

XX гасыр башында Оренбург шәһәре татар милли-мәдәни үзәкләренең берсе булган. Анда яшәгән **Берк Бреслин** дигән кеше, 1880 нче елларда үз типографиясендә гарәп шрифты булдырып, татар китаплары бастыра башлаган. Ләкин анда чыккан китаплар санаулы гына булган.

1900 елда **Гыйльман ахун Кәримов**, Оренбургтагы бер рус кешесеннән – типография, Бреслиннан исә гарәп шрифтларын сатып алып, үз матбагасын оештырган. Анда 1901 елдан алып 1902 елның уртасына кадәр 27 исемдәге



Ризаэддин Фәхреддин «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр». – Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1914



Фатих Кәрими «Истанбул мәктүбләре». – Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1913 ел

татар китабы басылган, гомуми тиражы 52 400 данәне тәшкил иткән. 1902 елда Гыйльман ахун вафат булгач, типография аның улы Фатих Кәрими карамагына калган. Ул, Төркиядә белем алганда һәм аннан соң Кырымда, 1898 елда Шакир Рәмиев белән Европа илләренә (Германия, Франция, Бельгия, Италия һ.б.) сәяхәт кылганда, аннары Мәскәү белән Петербургта, типография эшенең серләрен өйрәнеп кайткан була.

Кәримов матбагасы яхшы гына эшләп китә. 1905 елның ахырында Ф.Кәрими тәкъдиме белән «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» исемендәге нәшрият оештырыла. 1906 ел ахырында социал-демократик һәм большевистик брошюралар бастырылып, типографиянең ябылу куркынычы тугач, 1907 елда Ф.Кәрими үз матбагасын шушы нәшрият исеменә күчергән. Типографиядә 1907 елда да русчадан тәрҗемә ителгән социал-демократик китапчыклар басылганнан соң, патша цензурасы шикаяте нигезендә аңа арест салына, һәм ул 1908-1909 нчы елларда эшләми. 1910 елда биредә берничә китап кына басылган.

«Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» Оренбургтагы рус типографиясен дә сатып алып үзенә кушкан. Яңа техник җиһазлар һәм шрифтлар алганнан соң, бу типография Оренбургтагы иң куәтле басмаханәгә әверелгән. Анда, китаплардан тыш, татар һәм рус вакытлы матбугаты да нәшер ителгән. Әлеге нәшрият Уфа шәһәрендә дә бүлекчәсен һәм матбагасын («Шәрык» матбагасы) ачып җибәргән.

1901-1917 нче еллар арасында «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» типографиясендә 384 татар китабы басылып, аларның гомуми тиражы миллионга якын булган. Фатих Кәриминең күпсанлы үз әсәрләре һәм дәреслекләре, шулай ук тәрҗемәләре бу типографиядә чыккан. Ризаэддин Фәхреддиннең дини,

әдәби һәм тарихи хезмәтләре дә әлеге матбагада дөнья күргән. Башка татар авторларының дәреслекләре, педагогик, тарихи һәм фәлсәфи хезмәтләре, әдәби әсәрләре, фәнни-популяр китаплар нәшер ителгән.

1906 елда Оренбургта иске карашлы татар дин әһелләре үзләренең матбугат органы «Дин вә мәгыйшәт» журналын чыгара башлаганнар, һәм шуны бастыру өчен типография оештырылган. Журнал исеме белән үк аталган басмаханәдә китаплар да нәшер ителгән. Анда күбесенчә кадимчелек тарафдарларының китаплары чыккан. Бу типографиядә барлыгы 104 исемдәге китап 175 750 данә тираж белән басылган.

Оренбургта яшәгән Закир һәм Шакир Рәмиевләр, 1906 елда «Вакыт» газетасын һәм 1908 елда «Шура» журналын нәшер итү максаты белән, үз типографияләрен оештырганнар. Рәмиевләрнең 1909 елда эшли башлаган «Вакыт» матбагасында, газета һәм журналдан тыш, китаплар да бастырылган. Анда 1909-1917 нче елларда барлыгы 116 исемдәге татар китабы 322 450 данә гомуми тираж белән нәшер ителгән. Галим Әбрар Кәримуллин мәгълүматларына караганда, «Вакыт» типографиясенең җитәкчесе шул ук исемдәге газетаның мөхәррире Фатих Кәрими булган.

Оренбургта чыккан татар китаплары, Казан басмаларына караганда арзанрак булу сәбәпле, тиз арада таралып беткән. Әлеге матбагада шулай ук казакъ телендәге китаплар да басылган.

Уфада

XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында Уфада эшләүче рус типографияләрендә берничә исемдә генә татар китабы дөнья күргән.

Мәҗит Гафури «Тәэссоратым». – Уфа: «Шәрык матбагасы», 1910 ел

1905 елдан алып Уфа губерна идарәсе типографиясендә гарәп шрифтлары белән татар китаплары бастыру эше җанланган. Бу басмаханә 1908 елга хәтле Уфада татар китаплары чыгарып килгән бердәнбер матбага булган. Анда барлыгы 15 исемдәге татар китабы нәшер ителгән.

Уфада беренче хосусый типография 1908 елда «Шәрык» матбагасы исемендә, Оренбургтагы «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе»нең филиалы буларак ачылган. Бу типография 1914 елда Казан китапчылары – бертуган Кәримовларга сатылган, ә исеме сакланып калган. Ләкин миссионерларның шикаятьләре аркасында типография эшенә зур зарар салынган, китап бастыру шактый кимегән.

1908-1917 нче елларда бу матбагада 600 мең данәдән артык тираж белән 200 исемдәге татар китапарына-

бы чыккан. Шулардан дини эчтәлектәге китаплар аз булып, басмаларның күпчелеген матур әдәбият һәм халык авыз иҗаты әсәрләре, дәреслекләр һәм фәнни-популяр китаплар тәшкил иткән.

Уфа каласында 1914 елда «Тормыш» типографиясе оештырылган. Анда 1917 елга кадәр 42 400 данә тираж белән нибары 11 татар китабы чыккан.

Троицкида

XX гасыр башында Троицки шәһәрендә «Хезмәт» китап нәшрияты оештырылган. Әлеге нәшрият тырышлыгы белән 1905 ел ахыры-1906 ел башында Троицкидагы рус типографиясендә дистәләп татар китабы басылган.

Мәскәүдә

XVIII гасырның соңгы чирегендә Мәскәү университетында гарәп шрифтында чыккан китаплардан соң, бу шәһәрдә XIX гасырда санаулы гына татар басмалары дөнья күргән. XX гасыр башында да **Отто Гербек** типографиясендә, Шәрык телләре институтында (Лазарев институты), 1910-1915 нче елларда Михаил Осипович Аттай матбагасында берничә генә татар китабы чыккан. Боларда һәм Мәскәүнең тагын берничә типографиясендә XX гасыр башында нибары 14 татар китабы 28 мең данә гомуми тираж белән басылган.

Әстерханда

Ярулла Моради, «Тукаев Уральскида». – Әстерхан: Г.Гомәри матбагасы, 1913 ел

Әстерхан шәһәрендә Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте **Габдрахман Гомәри**, матбага ачып, XX гасыр башында татар китаплары бастыра башлаган. 1908-1914 нче елларда «Г.Гомәри вә шөрәкясе» типографиясендә 58 татар китабы 123 425 данә гомуми тираж белән дөнья күргән. Әлеге китапларның бөтенесе диярлек Г.Гомәри тарафыннан нәшер ителгән.

Әстерханда цензура аеруча рәхимсез булганлыктан, андагы татар матбугаты эзәрлекләнгән, газета һәм журналлар яптырылган. Цензураның тагын да көчәюе нәтиҗәсендә, Әстерханда 1914 елда татар китапларын бастыру бөтенләй тукталган. Андагы татар матбугаты һәм мәдәнияте әһелләре башка шәһәрләргә күчеп китәргә мәҗбүр булганнар.

1917 елның Февраль революциясеннән соң, Әстерханда татар матбугатын бастыру яңарган, анда «Нәшрият» типографиясе ачылган.

Сулдан: Г.Тукай Уральскидагы иптәшләре арасында. 1907 елгы фоторәсем. Сулдан Нәҗип Нигъмәтуллин (буфетчы), Курушкин (бухгалтер), Рәхмәтулла Хәйруллин (приказчик), Габдулла Тукай, Сираҗетдин Белюков (шәкерт Тукай белән бергә мәдрәсәне ташлап чыга).

Эстәрлетамакта

1910 елда Эстәрлетамак шәһәрендә «Нур» татар типографиясе ачылган һәм 1914 елга кадәр (хөкүмәт тарафыннан ябылганчы) анда 30 татар китабы басылган. Чыккан китапларның гомуми тиражы 52 мең данә тәшкил иткән.

Уральскидагы Камил Мотыйгый матбагасында һәм Семипалаттагы «Ярдәм» ширкәте тарафыннан дистәләгән исемдәге татар китаплары басылып чыккан.

* * *

Әбрар Кәримуллин мәгълүматларына караганда, XX гасыр башында ел саен 500дән артыграк китап чыгып килгән. 1901-1917 нче елларда барлыгы 7 меңгә якын исемдәге татар китабы басылган, һәм аларның гомуми тиражы 47 миллионнан артып киткән. 1917 елга кадәр барлыгы 15 мең исемдәге татар китабы нәшер ителгән. Ул чор татар китапларының гомуми тиражлары Россия халыклары арасында руслардан кала икенче урында торган. Татар авторларының китаплары белән беррәттән, Көнчыгышның бөек әдипләре һәм философлары Газали, Мәгарри, Фараби, Низами, Фирдәүси, Рудаки, Хәйям, Дәһләви, Европаның бөек классиклары Ж.-Ж.Руссо, Һ.Һейне, Ф.Шиллер, Дж.Байрон, Г.Сенкевич, Х.-К.Андерсен, Ж.Верн һ.б. язучыларның әсәрләре дә туган телебездә басылып чыккан. ■

Коточкыч ачлык

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА ҺӘМ АЧЫГЫП ҺӘЛАК БУЛГАН МӘРХҮМНӘР РУХЫНА БАГЫШЛАНА.

Ач балалар. 1921 ел. *Ф.Нансен фотосы*

Соңыннан үкенерлек булмасын

Ачлыкның киң мәйдан алып җәелә баруы авыл хуҗалыгының төбе-тамыры белән җимерелүенә сәбәп була. Крестьян халкы икмәк артыннан анда чаба, монда чаба, ахыр чиктә, йорт-җирен, туган илен ташлап, Себергә, Төркестанга – әүвәлдә колагы ишетмәгән ерак җирләргә кача. Менә шул хәл инде ничә айлардан бирле дәвам итеп килә. Хәзердә дә күчүчеләр гайре рәсми рәвештә күчәләр.

Кайбер авыл халыклары, ул рәвешчә күченүне мәгъкуль күрмичә, яки мәгъкуль күрсә дә, аты булмаганлык сәбәпле күчә алмаганлыктан, үзләренең хуҗалыкларын урыннарында торып туздыралар. Минем алдымда Чистай кантоны Кукуш волосте Утыз-Имән авылыннан килгән вә авыл советы тарафыннан пичәт белән тәсдыйк ителгән *(расланган)* бер хат тора. Ул хатта менә нинди сүзләр язылган: «*Ташкентта, Төркестан якларыннан малга алмашып, он китерергә мөмкинлек хакындагы декретның чыкканлыгы ишетелгәч тә, Утыз-Имән авылы халкы, түбәндәге нәрсәләрне җыеп, волостьтән бер комиссия чакырып, бәһа тәгаенләтте: 109 сабан, 114 камыт, 70 чөчән, 65 дуга, 112 тун, 225 урак, 85 чалгы, 1875 данә тырма теше, 34 бәрхет камзол, 95 стена сәгате, 20 кесә сәгате, 87 самавыр, 27 пар күн итек, 665 агач көрәк, 70 пот мунчала, 15 лом, 25 арба кәндугы, 35 арба, 41 чана, 22 ыстан тимерле көпчәк, 187 баш эшләнгән тире, 15 агач кисмәк, 17 тарантас, 1 повозка, 100 агач чиләк, 1 урак машинасы, 1 ашлык суга торган машина*».

Менә шушы фактны төптәнрәк уйлап караганда, әүвәлдә дә фәкыйрь булып, 6 ел сугыш буена авыл хуҗалыгы кораллары ала алмаган авыл халкы кулында булган иген коралларын ычкындырып бетергәч нишләячәген белү бик читен түгел. Ләкин бу урында бөтене белән крестьян халкын гаепләргә тугры килми, чөнки аны ачлык шуңа мәҗбүр итә.

Менә шул ачлык аркасында ул үзенең оясын туздырып бетермәсен өчен, чаралар күрергә кирәк. Әле кыш көне ул кораллар кирәк түгел, әмма яз килү белән нишләрбез? Мәркәз Татар җөмһүриятенә 5 миллион потка якын чәчү орлыклары

Бер төркем ачлар санитар-ашханә поезды янында. Аларның күбесе балалар

бирергә карар кылды. Ул орлыкларны китерү өчен тиешле органнар тарафыннан ашыгыч рәвештә чаралар күрелә башлады һәм эш орлыкка терәлеп калмас дип уйлана, ләкин крестьян иген коралларын икмәккә алыштырып җиткергәч, ул орлыклар белән нишләр? Менә мәсьәлә шунда, бу мәсьәләне хәл итүне Наркомзем Посевком беренче нәүбәткә куярга тиешләр. Бәлки, бу хакта чаралар күрелә торгандыр, ләкин моңа кадәр безгә ул хакта ишетелгәне юк. Бу мәсьәләне хәл итүдә соңга калмаска кирәк. Әүвәлдән дә җитешми торган иген машиналарын читкә тараттырмаска кирәк. Юкса крестьян халкы күренеп тора торган корылыкка каршы көрәшкә кулында бер коралы да булмаган хәлдә чыгарга мәҗбүр булачак. Шуны булдырмас өчен, ул эшкә чик куярга кирәк. Соңыннан үкенерлек булмасын.

Татарстан хәбәрләре. –
1922. – 3 гыйнвар.

Швециянең ярдәме

Швециядә сәүдә-сәнәгать ияләре Русия ачларына ярдәм итү өчен бер җәмгыять төзегәннәр иде. Җәмгыятьнең вәкиле Драйер Казанга килеп эшкә кереште. Ул үзе белән бергә 11 вагон арыш оны алып килде. Аның 5 вагон икмәге Мәскәүдән монда килергә чыккан. Шушы арада Мәскәүгә тагы 7 вагон төрле маллар киләчәк вә ул нәрсәләр Центросоюз тарафыннан икмәккә алмаштырылачак.

Швеция җәмгыяте хәзерге Тәтеш һәм Спас кантоннары ачларына ярдәм итә. Икмәкнең 75 проценты – балаларга, 25 проценты зурларга өләшенәчәк. Хәзергә кадәр Швециядән ачлар файдасына, Русия акчасы белән исәпләгәндә, 11 миллиард сумлык азык китерелгән.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 9 гыйнвар.

Ачлык булган җирләрдә

Петербургтагы табибларның җыелышында Америка һәйәте белән бергә Идел буеннан йөреп кайткан табиб Гран доклад ясаган. Алар Самар, Сарытау,

1921 елгы плакатлар

Сембер, Уфа вилаятләрендә һәм Чуваш, Вятка вә Татарстан җөмһүриятләрендә булганнар.

Табиб Гран үзенең докладында менә нәрсә ди: «*Самар вилаятенең 93 процент халкы 1921 елның июленнән бирле үк җәгъли (ясалма) азыклар ашап тора башлаган. Хәзерге көндә андагы халыкның 99,6 проценты икмәккә мохтаҗ. Бөтен Самар вилаяте халыклары диярлек хәзер төрле тамырлар һәм* «*икмәк ташы*» *ашап торалар. Бу* «*икмәк ташы*» *дигән нәрсәдә һичбер төрле туклыклы әйберләр булмаса да, базарда поты 25030 мең сум тора. Ач калгач, җирләрдән халык бик күп кача. Бунда икешәр меңләп җыелган качакларга очрарга туры килгәләде. Кайсыбер авылларда бөтен крестьян йортларының биштән бер өлеше ябылган*».

Ачлыкның икътисади яклардан куркынычы булган шикелле, йогышлы авырулар тарату ягыннан да куркынычы бик зур. Ун меңнәрчә зурлар һәм балалар тиф, зәңгелә *(урт шеше авыруы, цинга)* шикелле авырулар белән авырыйлар. Балалар чебен шикелле үләләр. Ачлар арасында саз бизгәге дә бик нык хөкем сөрә. Беренче ярты ел эчендә Татарстан җөмһүриятендә һәм Уфа вилаятендә зәңгелә белән авырган 20 мең авыру теркәлгән.

Самар вилаятендәге шифаханәләрнең 50 проценты азык булмаудан ябылган. Табибларның ала торган паеклары да ачлар ашый торган җәгъли азыклардан гыйбарәт. Кайсыбер җирләрдә табиблар айга 4 кадак алабута оны алалар һәм, атлар булмаганлыктан, шундый паекларны алырга 60-100 чакрым җәяү баралар. Күп шифаханәләрдә утын һәм дәвалар юк.

Бу турыда да табиблар җыелышында күп сүзләр сөйләнгән һәм ачлык булган җирләрдә авыруларны карау эшләренең канәгать хасил итәрлек булмаганлыгы вә шул сәбәптән аны тиешенчә юлга куярга кирәклеге хакында резолюция кабул ителгән.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 6 гыйнвар.

Германия Кызыл Хач җәмгыятенең ярдәме

Германия Кызыл Хач җәмгыяте ачларга башлыча дәва әсбаплары белән ярдәм итә. Ноябрь-декабрьдә Татарстан җөмһүриятенә 26 тонна дарулар килде һәм соңгы көннәрдә тагы 4 вагон тапшырылды. Бу дәвалар Татарстан җөмһүриятендәге хастаханәләргә өләшенәчәк.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 9 гыйнвар.

Бөгелмә кантонында

Авыл хуҗалыгының бетмәс-төкәнмәс хәзинәсе булган хайваннары да бу елгы ачлыкның каһәрен татыйлар. Авыл халкы алабута, тамыр, кибәк вә башка шуның кебек нәрсәләрне ашап бетергәч, актык күз нарасый хайваннарыннан да яза башладылар.

Хайваннарның буынсызлык, корчаңгы авыруы белән җәфаланулары аларның санын тагын да киметә. Буңар бер генә чара бар: «Хайваннарны саклау атнасы» ясап, ударный рәвештә бөтен балта осталарын, тимерчеләрен җыеп, салам турый торган машиналар ясатып, бөтен мастерскойларны эшләтү кирәк: хайваннар каткан «пәри үләне»н, суыкка, ачлыкка чыдамыйча, көн-төн кимерәләр, шуның сәбәпле ат, сыер хайваны буынсызлана, тамаклары туймый. Әгәр «пәри үләне»н ваклап, йомшатып ашатсак, хайваннарны саклап калыр идек.

Г.Әсәнов

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 16 гыйнвар.

Арча кантоны

Бу арада Арча кантонында үлгән кешеләрнең саны артып бара, бигрәк тә Кармыш волостенда зурлар өчен ашханәләр ачылып торса да, ачыгучыларның саны күплек сәбәпле, җитәрлек түгел. Балаларның торышы хәзерге көндә яхшы булып бара, чөнки американский ашханәләр өстенә, ачларга ярдәм комитеты да яхшы гына ярдәм күрсәтә. Шулай ук тиф авыруы да күтәрелеп бара. 1921 елда 30 декабрьдә Ревтрибуналның выездной сессиясе, Арчага килеп, сабикъ *(әүвәлге)* кантисполком рәисе Дашковның эшләрен карады. Дашков уездный начальник милиции булып торганда конфисковать ителгән нәрсәләрне үзенә алып яки сатып файдаланган кебек, исполком рәисе булып та байтак эшләр эшләгән икән. Шулай ук, кантпосевком рәисе булып та, күп орлык арышны кирәкмәгән җирләргә тараткан өчен трибунал Дашковны 5 елга төрмәгә хөкем итеп, амнистия сәбәпле, өч ел да 4 ай төрмәгә утыртырга карар ясалды.

Борһан Минһаҗетдинов

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 18 гыйнвар.

*Сәхифәне **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Мәхмүд Мәрҗанинең кабер ташы

Айдар Гайнетдинов

Ш.Мәрҗанинең газиз улы Мәхмүд һиҗри 1283 елның 27 җөмадиәл-әүвәлендә (1866 елның 7 октябрендә) дөньяга килгән. Бик зиһенле булуы сәбәпле, атасы аңа бик күп өметләр баглаган булган. Тик, аяныч ки, Мәхмүд аягына салкын тидереп, аның бер аягын ампутацияләгәннәр, соңрак инде, дәваланды дигәндә генә туберкулез авыруы белән каты чирли башлап, ул 1885 елның 17 декабрендә бик яшьли вафат булган. Мәхмүд Казанның Яңа Татар бистә зиратына атасы янынарак (15 һәм 16 нчы аллеялар арасында) җирләнгән. Кабер ташын атасы Шиһаб хәзрәт үзе яздыртып куйган.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1. «Мәшһәд-
2. –үш-шәәббил-галләәмәти
3. Баһаэддин Әбүл-Фазыл
4. Мәхмүд бине Шиһабеддин
5. әл-Мәрҗани интәкадә иләә
6. рахмәти Раббиһи сәхәра йәүмил-хамииси ли-гашрин
7. халәүнә мин шәһри рабиигыйль-әүвәли
8. сәнәтә 1303 сәлә[сә] бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәтин минәл-һиҗраһ».

Уң ягы (уеп язылган):

«Иләәһии габдукәл-гаасыый әтәәкә мукыйрран биз-зунууби фә-кад дәгаакә фә-ин тәрхәм фә-әнтә әһлүн ли-зәәкә вә ин тәтъруд вә мән йәрхәм сиваәк».

Сул ягы (уеп язылган):

«Йәә вәәкыйфән би-кабрии мутәфәккиран би-әмрии бил-әмси күнту мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Арткы ягы (уеп язылган):

1. «Вәәдыйгу
2. һәзәәл-ләүхи
3. вәәлидүһү Шиһабеддин
4. бине Баһаэддин
5. әл-Мәрҗани сәнәтә 1306
6. ситтә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1. «Күренекле
2. яшь галим
3. Баһаведдин Әбел-Фазыл
4. Мәхмүд бине Шиһабеддин
5. Мәрҗани Раббысы
6. рәхмәтенә таң атканчы пәнҗешәмбе көн
7. һиҗри 1303 (мең өч йөз өченче) елның
8. унынчы рабигыль-әүвәлендә күчте».

Уң ягы:

«Илаһым, Синең гөнаһлы колың Синең янына гөнаһлар белән килде һәм Сиңа ялварды. Әгәр рәхим кылсаң, Син моны эшли аласың, әгәр куып җибәрсәң, Синнән башка кем рәхим кылсын».

Сул ягы:

«Әй, минем каберем янында басып

Алгы ягы

Арткы ягы

торучы, минем хәлем хакында фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, таңда син минем кебек булырсың».

Арткы ягы:
1. «Бу ташны
2. куючы:
3. аның атасы Шиһабеддин
4. бине Баһаведдин
5. Мәрҗани, 1306 (мең
6. өч йөз алтынчы) ел».

Ташның үлчәмнәре: *134x36x18.*

Кабер ташындагы тексттан аңлашылганча, Мәхмүднең икенче исеме, ягъни кушаматы – Баһаветдин, куньясе – Әбел-Фазыл. «Мөстәфадел-әхбар...» китабында Мәхмүдкә атасы мондый характеристика биргән: *«Гаять акыллы, сабыр, укырга бик ярата торган, яхшы хәтерле, күп нәрсәне яттан белгән, бик күп яхшы сыйфатларны үзендә туплаган, нечкә билле, матур йөзле, төз һәм озын буйлы, кара кашлы, кара күзле, кара чәчле кеше иде».* ■

Уразмәтнең фаиз углы

Марат Әмирханов

«Сөембикә» журналында эшләгән чагым. Ул чорда редакция авторлар белән гөж килеп тора иде: кайсы мәкалә китерә, кайсы корректура укырга килә, кайсы зарын сөйли, ярдәм сорый. Хак, матбугатның үз укучыларына ярдәм итә ала торган абруйлы вакытлары бар иде.

Шундый гадәти көннәрнең берсендә бүлмәгә, ишекне йомшак кына кагып, борчыйм инде, гафу итегез, дигәндәй, кыенсыныбрак кына, мөлаем йөзле, ыспай киемле урта яшьләрдәге бер кемсә килеп керде.

– Сез тарих фәненә кагылышлы мәкаләләр бастырасызмы? – дип белеште аягүрә хәлендә.

– Мәкаләсенә карап инде, – дидем керүчегә, ым белән генә урын тәкъдим итеп. – Сез кем буласыз?

– ИЯЛИдә эшлим, тарихчы Фәйзелхак Ислаев булам.

– ИЯЛИ галимнәре белән танышлыгым бар-барын, ә Сезне, нигәдер, беренче күрүем, – дидем.

– Мин әле Казанда яңа кеше, танымавыгыз һич тә гаҗәп түгел.

Фәйзелхак Габделхак улы белән аралашу, дуслашу шул көннән башланды. Искиткеч вәгъдәле, эчкерсез һәм чын инсаф иясе дус. Тарихи жанрда иҗат итүче язу-

чы буларак, мин аңа бик еш мөрәҗәгать итәм. Рәхмәт, һәрвакыт якты йөз күрсәтә.

Ул борынгы төрки бабаларыбыз гомер сөргән искиткеч бай Урал – Урал итәге төбәгеннән, хәзерге административ бүленеш буенча Пермь өлкәсенең Октябрь районындагы Уразмәт исемле уртакул авылында туып үскән.

Фәйзелхакның әтисе Габделхак Исламетдин улы (1906-1963)

– Туган авылымда сигезьеллык белем алгач, күршедәге Янапай мәктәбендә үз ана телемдә урта белемгә ия булдым, – диде ул, ниндидер сәмави горурлык белән.

Горурланырлык та шул. Милли телле мәктәпләр бетеп барган бүгенге БДИ вазгыяте белән чагыштырырлыкмы соң? Көнләшергә, сыкрарга гына кала. Кызганыч, нинди көннәргә калып барабыз бит... Пермь өлкәсендә инде татар мәктәпләрен, көндез чыра яндырып эзләсәң дә, таба алмассың.

Фәйзелхакка да, белем олимпына менү өчен, шактый кыенлыклар, ураУ юллар аша үтәргә туры килә. 1 сыйныфка кергәндә, әнисе Нәгыймә апа вафат була, 10ны тәмамлаганда, әтисе дөнья куя. Аңа шулай бик иртә, үги анасы Асия ханымга терәк булып, гаилә мәшәкатьләренә алынырга туры килә. Әле ярый, мәктәпкә лаборант вазыйфасына алалар, азмы-күпме акчасы килеп тора. Ләкин вакыт уза, әнә, егермесе дә килеп җитте, ә киләчәге томан эчендә, билгесезлек: ни белеме, ни һөнәре юк, барысы да ярты юлда...

– Мин Пермьгә китеп, үз тормышымны үзем көйләргә телим, зинһар, хәер-фатихаңны бир, сине ярдәмемнән калдырмам, кайтып йөрермен, – дип мөрәҗәгать итә ул көннәрдән беркөнне әнисенә.

Бу вакытта яшь авыл егетенең бердәнбер омтылышы – фәкать ният кенә. Хәер, ният кенә димик, мөселман өммәтендәге иманлы кешенең һәр гамәле шул изге нияттән башлана бит инде. Ниятенә, үзе әйтмешли, эш сөючәнлеге, тырышлыгы, үҗәтлеге канат куя.

Пермь чоры егерме җиде елга сузыла. Хезмәт кенәгәсенә беренче булып өйрәнчек слесарь-техник һөнәре теркәлә. Төзелештә хәйран гына тәҗрибә туплый. Аннан соң – Киров исемендәге дары заводы. Әлеге завод зыялылары белән дан тота. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, диләр бит, бу вазгыять яшь эшчегә дә йогынты ясамый калмый, әлбәттә. Әле бөреләнеп кенә килүче сәләтен ачуга мөмкинлек туа. Университетка читтән торып укырга керә, перспективасын күз уңында тотып, аны тиздән парткомга эшкә чакыралар. Бер ел солдат боткасын ашарга да өлгерә.

Ниһаять, чын фән дөньясына аяк баса: аспирантурада укый, 1983 елда КПСС тарихы буенча диссертация яклый, Авыл хуҗалыгы институтында мөгаллимлек итә, доцент дәрәҗәсен ала.

Пермь чорына шушы урында ашыгычлык белән нокта куйсак, рисаләбез каһарманы гафу итмәс иде. Чөнки чал Чулман буендагы бу матур шәһәрдә ул гомерлек тәүге мәхәббәтен дә таба. Нәкъ «Идегәй» дастанындагы гүзәлкәй:

«Кашларын карасам,
Каләмнән пәйда булгандай;
Күзләренә карасам,

Күгеннән пәйда булгандай;
Буйларына карасам,
Нурдан пәйда булгандай!»

Бер сәниядә күңел мәшрикъ илә мәгъриб арасында йөреп кайтыр, дип тәкърарлый шагыйрь. Сания – тизлекне белдерә – секунд!

Казанда химия-технология техникумын тәмамлап, Пермь дары заводына эшкә җибәрелгән Арча кызына әтиәнисе, бик белеп, Сания исеме кушкандыр, күрәсең. Туташның күз карашы да, хисләре дә, йөреше дә – ут, көйдереп кенә ала. Гашыйк егет шушы ялкын эченә атыла...

Фәйзелхак Ислаев хатыны Сания белән

Фәйзелхак-Сания! Инде ярты гасыр татулыкта, куанычта гомер кичерәләр. Буйга җиткән ике кызлары, бер уллары бар. Һәр өчесе дә җиһанга чәчәкле май аенда аваз салган: Чулпан – 21 майда, Алсу – 16 майда, Азат – 9 майда. Сигез онык. Үзе бер мәгънәви фазыйләт.

Азат татар яшьләренең милли азатлык хәрәкәте лидеры, Казан Шәһәр Думасы депутаты, юрист, эшмәкәр булды. Хәзерге көндә Владивостокта шәһәр мэры урынбасары вазыйфасында.

Чын милли татар гаиләсе, үрнәк гаилә. Галимнең тылы ышанычлы. Арабызда Ислаев ишеләр күбрәк булса, киләчәк язмышыбыз турында бүгенге кебек үк борчылу кичермәс идек, бәлки.

1993 елда Барда район үзәгендә галимнәрне, тарих сөючеләрне конференциягә җыялар. Көн тәртибендә – милли мәсьәлә. «Бу төбәк халкының этногенезында татар этник нигезе ятамы, башкорт этник нигезе ятамы?» дигән гипотеза буенча фикер алышалар.

Фикер алышу һәр ике якның да тарткалашуына кайтып кала, уртак нәтиҗәгә киленми. Хәлбуки, Барда төбәге – татар төбәге. Шул ук вакытта башкорт эзләре дә саклана.

Фәйзелхак Ислаев шушы җыенда ИЯЛИ галимнәре Дамир Исхаков, якташы Рәшит Ягъфәровлар белән якыннан таныша һәм Казанда эшләү мөмкинлеген белешә.

Бу – милләтләрнең, шул исәптән татарларның да уянган чоры, үз тарихларын өйрәнүгә чын-чынлап тотынган шанлы вакытлары иде. Дусларының тәкъдиме белән, ИЯЛИ директоры Мирфатыйх Зәкиев тарихчы яшь галимне ике куллап эшкә ала.

«И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!»

Әйе, кайчандыр Казанга ашкынган әүлия шагыйребез кебек үк, ошбу мәдәни үзәк гыйрфани мәзһәп[1] дулкынында кайнаучы барча зыялы инсаннарыбызның да галиел-гальдән гали[2] хыялы. Аның тормышка ашуы – бәхет!

Фәйзелхак әфәнде кырык җиде яшендә, гаиләсе белән берлектә, шушы бәхетне татый.

---

[1] Гыйрфани мәзһәп – аң-белемгә, мәдәнияткә тоткан юнәлеш.
[2] Галиел-гальдән гали – югарыдан да югары.

– Без төрле төбәкләрдә яшәүче татарларның тарихын барлау буенча махсус программа булдырдык, – ди директор. – Мәсәлән, Габделбәр Фәйзрахманов Себер татарлары тарихын тергезү юнәлешендә зур тырышлык куя. Сезгә үзегезнең Пермь татарлары тарихын язу йөкләнә, уңышлар телим.

1993 елның 1 октябрендә Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих интитутының бүлек мөдире, танылган тарихчы Сәлам Хатип улы Алишев аны хезмәттәшләренә тәкъдим итә.

Казан чоры менә шулай башлана. Күп тә үтми, матбугатта Пермь татарларының XVI-XVIII гасыр тарихын чагылдырган мәкаләләр күренә башлый.

– Озак еллар көн күргән яшәү урынын үзгәртү, әлегә таныш булмаган фән дөньясында, зыялылар арасында үземне таныту җиңел булмады, – дип искә ала галим ул вакытларны. – Шушы сыналу чорында миңа кул сузучы – бүлмәдәшем, яшьтәшем Равил Әмирхан булды, мин бу дуслыкка әле дә горурлык хисләре кичереп яшим.

Равил ошбу язма авторының да якын дусты иде. Фамилиядәшләр дә, фикердәшләр дә. Арабыздан бик иртә китеп барган бу искиткеч талантлы тарихчы галим – фән дөньясында тирән эз калдырган шәрәфле шәхес.

«Ике энә бер җептә, ике имән бер төптә» – кеше һәрвакыт үзенә тиң кешегә тартыла.

Тарихчылар буларак, Чыңгыз ханның «Белек»ләренә мөрәҗәгать итик әле.

«Олуг буласы килгән кеше аз сөйләсен, сорашмаганга бернәрсә дә дәшмәсен, җавап биргәндә дә уйлап бирсен. Кеше халык арасында юаш, йомшак күңелле, әмма сугышта ач лачын күк булырга тиеш», – дип яза җиһангир.

Әлеге сыйфатлар бу ике дуска «суйган да каплаган». Сугыш дигәне исә алар өчен – фән. Фәндә алар, дөрестән дә, лачын!

Фәйзелхак әфәнде тарих диңгезендә үзен судагы балыктай хис итә: аны аркылыга-буйга иңли. Шуларның бер-ике утравына гына тукталып алыйк әле.

Аңа тамгалар җене кагылган. Коллекциясендә 10 000 тамга исәпләнә. Тамга дигәннән, без үскәндә дә кулланышта иде әле алар. Безнең авылда, мисал өчен, һәр гаиләгә кырда бәрәңге җире бүлеп бирәләр иде. Үлчәп торалар, хуҗалар таякчыкларны кага торалар. Һәр таякчыкта – тамга: ярымай, түгәрәк, сәнәк, тырма... сурәтләре. Халык ул тамгаларның кемнеке икәнен бик яхшы белә иде. Ялгышу да, буташтыру да юк.

– Тамга фәлсәфи мәгънәгә ия, – ди галим, – ул халыкның этник тарихын тәгаенләүдә бик ышанычлы ярдәмче. Мин аны өйрәнүне фәнни дәрәҗәгә күтәрергә омтылдым, мәкаләләр язып бастырдым, китап рәвешенә җиткерәсе калды.

> **«Олуг буласы килгән кеше аз сөйләсен, сорашмаганга бернәрсә дә дәшмәсен, җавап биргәндә дә уйлап бирсен. Кеше халык арасында юаш, йомшак күңелле, әмма сугышта ач лачын күк булырга тиеш».**

Икенчесе – Шәҗәрә утравы. Мәгълүм ки, соңгы елларда нәсел-нәсәп агачын барлауга игътибар артты, һәркем үз тамырларын барлый башлады. Шул тамырлардан Марсель Әхмәтҗанов, Фәйзелхак Ислаев һәм башка галимнәребез үсеп чыкты. Ф.Ислаевның ун мең данәдә басылган «Я и моя родословная» китабы, әйтик, мәктәпләрдә дәреслек буларак тәкъдим ителде. Ул, гомумән, балалар матбугаты белән ныклы элемтәдә тора. Моннан алда «Ялкын» жур-

Гаилә – ныклы терәк

налында аның җитәкчелегендә «Шәҗәрәдә – гаилә тарихы» бәйгесе үткәрелгән иде. Күптән түгел, Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан, «Сабантуй» журналында узган «Шәҗәрәдә – Бөек Ватан сугышы» дигән бәйгегә йомгак ясалды.

Шәхсән, галим үзенең унөч буын нәсел-нәсәбен ачыклаган.

Кайберәүләрнең, карале, бу кемсәнең гыйльми карьерасы такыр юлдан элдерткән тәгәрмәч кебек бик җиңел тәгәрәгән икән ләбаса: нәрсә теләгән – шуны эшләгән, барыр юлында һичнинди киртәләргә дә юлыкмаган дип уйлаулары ихтимал. Әмма фән ул шундый четерекле өлкә ки, кайчакта гади генә бер датаны яки вакыйганы ачыклау өчен архивларда казынырга, дистәләгән чыганакларга мөрәҗәгать итәргә, шул карурман эченнән иң дөресен тәгаенләргә, җаваплылыгын үз өстеңә алырга туры килә.

Фән – батырлыкка тиң хезмәт. Хәлбуки, батырлык дигәндә, без, башлыча, кулына корал тотып дошманга каршы сугышкан яугирне күз алдына китерергә күнеккәнбез. Әлеге җәһәттән, миңа ХХ гасырның бөек сәясәтчесе Черчилльнең: **«Кайда тәртип юк – шунда батырлык»**, – дигән билгеләмәсе ошый. Монда тәртип сүзен киң мәгънәдә аңларга кирәк. Без сүз алып барган фәнгә карата бу, мөгаен, ниндидер сәбәпләр аркасында әлегәчә ябык дип саналган, гыйльми әйләнешкә кермәгән тема ишеген ачу, фәндә үз сукмагыңны салудыр.

Фәйзелхак Ислаевка менә шушы батырлык насыйп була.

Хәл болай. Пермь төбәге татарлары тарихы нигездә инде әзер. Ул бу эшләрен докторлык диссертациясен яклауга юнәлеш тотып тәгаенли. Абруйлы галимнәрдән хәер-фатиха аласы гына кала. Шушы үтенеч белән Казан университетының татар халкы тарихы кафедрасы мөдире Миркасыйм Госмановка мөрәҗәгать итә.

Миркасыйм әфәнде аны дикъкать белән тыңлый да турысын бәреп әйтә:

– Сезнең бу темагыз докторлык диссертациясе дәрәҗәсенә күтәрелмәгән, икенче тема сайлагыз, – ди.

– Зур галимнән бу сүзләрне ишетүнең никадәр авыр икәнлеген үз башыннан үткәргән кеше генә беләдер, – дип искә ала Фәйзелхак әлеге очрашуны, – төн йокыларым качты, бик борчылдым.

Борчыла, әмма сыгылып төшми. Чөнки бу – СССР таркалып, демократия дигән тылсымлы бинаның ишекләре ачылган чак, милли хәрәкәтнең ярсу дулкындай ташкын булып гөрләгән вакыты, мөмкинлекләр заманы.

Әйтерсең лә, үзен әлеге хәлнең сагалап торуын алдан тоемлаган, бер үк вакытта аның керәшен кантуры тарихы турында материаллар туплап, китап әзерли башлаган чагы була бу. Дин юлында башын салган мәшһүр якташы Батыршага багышлаган мәкаләсе матбугатта дөнья да күреп өлгерә.

Тарихны җиңүчеләр яза дигән гыйбарә яши. Җиңелгән халык үз тарихын объектив яза алмый дигәне дә бар.

«Без, гадәттә, тарихта, нәрсә күрергә телибез – шуны гына күрәбез, – дип шәрехли күренекле тарихчы Искәндәр Гыйләҗев. – Бу – бик зур хата. Тарих ул күпкырлы. Анда күңелгә ошаган яки ошамаган нәрсәләр булмый. Тарих ул – булган фактларны торгызып, сөйләп чыгу».

«Объектив тарих беркемгә дә кирәкми», – дип тәкърарлый урыс язучысы Борис Акунин.

«Тарихны, ничек бар – шулай язу бик авыр» – монысы Фәйзелхак Ислаев фикере.

Бәхәсләшергә урын бар, әлбәттә. Әмма бу сәбәп түгел. Сәбәп – идарәче даирәләрнең үз мәнфәгатьләрендә тарихны идеологиягә буйсындыруы.

Тарихка «яңача» караш, ревизияләр шул җирлектә туа.

Татар тарихы бу яктан – күп эзәрлекләүләргә дучар ителгән, шул ук вакытта көрәшә-көрәшә түл җыйган тарих. Хәтта сугыш вакытында да аны кысрыклау, яла ягу тынып тормады. КПСС Үзәк Комитетының 1944 елда кабул иткән карары нигезендә, мәсәлән, татар тарихын болгар чоры белән генә чикләп, Алтын Урда дәверен өйрәнүне тыю – моңа ачык мисал.

Сүз дә юк, фәндә юнәлеш үзгәртү – галим өчен инкыйлабка тиң кискен борылыш. Бу борылышны ясау өчен, үзеңнең көчеңә, гыйльми потенциалыңа, сайлаган юлыңның хаклыгына тәкъва затлар кебек тирәннән ышану зарур.

Фәйзелхак әфәндедә әлеге сыйфатлар, кем әйтмешли, буа буарлык. Дуслары да хәерхаһ. Равил дә, Рәшит тә, башкалар да ярдәм итәргә, һичьюгы, рухи терәк булырга әзер.

Шул рәвешле Фәйзелхак Габделхак улы Ислаев моңарчы башкалар аяк басарга өлгермәгән татарларны христианлаштыру (чукындыру) темасына баш-аягы белән кереп чума.

Галимнең хезмәтен кәгазьдә тасвирлап булмый. Аны билгеле дәрәҗәдә бакчачы хезмәте белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Агач җимеш бирсен

«

Фән – батырлыкка тиң хезмәт. Хәлбуки, батырлык дигәндә, без, башлыча, кулына корал тотып дошманга каршы сугышкан яугирне күз алдына китерергә күнеккәнбез. Әлеге җәһәттән, миңа XX гасырның бөек сәясәтчесе Черчилльнең: «Кайда тәртип юк – шунда батырлык», – дигән билгеләмәсе ошый.

өчен, иң элек аның мәгъкуль үсентесен сайлап алырга, утыртырга, тамырландырырга, дымландырырга, ашларга, чыныктырырга, артык-портык ботакларыннан арындырырга, серкәләндерергә, чын мәгънәсендә нарасый баланы тәрбияләгән кебек тәрбияләргә кирәк. Шулай эшләгәндә генә, җимешкә өмет итә аласың. Бу – күп вакыт, зур тырышлык сорый торган дәвамлы гамәл.

1999 елда, ниһаять, галимебезнең гыйльми агачы да җимеш бирә – «Православные миссионеры Поволжья» монографиясе басылып чыга.

XVIII гасырда Россия дәүләтенең Идел-Урал төбәгендәге дини сәясәтен тормышка ашыруга багышланган диссертациясен Фәйзелхак 2005 елда Казан дәүләт университетында яклый. Комиссия рәисе – чын милләтпәрвәр академигыбыз Индус Ризак улы Таһиров.

– Индус Ризаковичның эчкерсез ярдәме тимәсә, ай-һай, ерып чыга алган булыр идем микән?! – дип, Ислаев җитәкчесенә ихлас рәхмәтләрен җиткерә.

Ул еллардан соң һәм сәяси, һәм милли-мәдәни вазгыять зур үзгәрешләр, чигенешләр кичерде. Галим, мәсәлән, 2000 нче еллардагы хезмәтләремне хәзер чыгарып булмас иде дигән фикердә тора.

Әйтерең бармы, чукындыру – искиткеч гаделсез, гаять дәрәҗәдә катлаулы вә каршылыклы, шуның белән бергә, гадидән-гади гамәл. Гадилеге – максатында: татарны ислам диненнән, халкыннан аеру, урыс ясау. Фаҗигасе генә – халык язмышында. Анысы инде миссионер әфәнделәрне кызыксындырмый.

Иң аянычы шул: әлеге мәнсез адәмнәр чәчкән орлык бүген дә шытымда. Аллам сакласын, бу һич тә бергә-бергә кулга-кул тотынышып яшәүче керәшен кардәшләребезнең гаебе түгел, ә бәласе. Үзәктәге шовинистик рухтагы даирә татар милләтен бүлгәләү, таркату юнәлешендә хәзер дә эзлекле эш алып бара, җае чыккан саен, әйтик, җан исәбе алу вакытларында моны бик оста файдалана да. Югыйсә тарихчыларыбыз, аерым алганда, Дамир Исхаков, милләтләрне нинди дин тотуга карап бүлүнең нигезсез икәнлеген даими рәвештә саллы дәлилләр белән исбатлап килә үзе.

Без хәзер дә шушы кампания алдында торабыз. ИншәАллаһ, урыс фамилиясен йөртүче асыл милләттәшләребез, ялган пропагандага бирелеп, хаталы юлга басмаслар.

Фәйзелхак Ислаев туган ягының, Пермь татарларының тарихын өйрәнүне әле дә күз уңыннан төшерми, тарихка мөкиббән һәвәскәр якташларын үз канаты астына алып килә. Җирле хакимият тә әлеге башлангычны хуплап каршы ала. Хәзерге вакытта китап чыгару мәшәкате белән мәшгульләр. Бирсен Ходай!

Коҗмакты (Барда) ягы – татар халкы өчен бик кадерле як. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның бабасы мелла Әмирхан бине Зәйнелбәшир бине Зиннәтулла хәзрәт шушы авылда туып үскән. Шуңа күрә андагы хәлләргә битараф кала алмыйбыз.

Тарих фәннәре докторы, профессор Фәйзелхак Ислаев үзен мөгаллим-галим дип саный. Бу аның эшчәнлегенә бик тә туры килә. Мөгаллимлеге, Пермьдә башланып, Казанда дәвам итә. Ул дистә ел Укытучылар белемен күтәрү институтында кафедра мөдире вазыйфаларын башкара, соңгы вакытка кадәр Россия ислам институтында лекцияләр укыды.

Фәйзелхак Ислаев – дистәдән артык китап, өч йөздән дә күбрәк фәнни мәкалә, күп кенә дәреслекләр авторы. Аңа 2021 елда 75 яшь (биологик яше 50 тирәсе!) тула. Ул – бөтен гомерен татар халкына, хак тарихыбызга эчкерсез хезмәт итүгә багышлаган олуг галим. Әмма шигырь язмаган. Моңа шуның өчен игътибарны юнәлтәм, бер интервьюсында ул: «Чын ир-егет йорт салырга, агач утыртырга һәм шигырь язарга тиеш», – дигән иде.

Тарих фәннәре докторы, профессор Фәйзелхак Ислаев «Ком сәгате» тапшыруында. Март, 2020

Шигырь язылмаган, ә дан бар. Ләкин рәсми даирәләр тарафыннан танылмаган дан: әлегәчә мактаулы исемнәргә дә, орден-медальләргә дә лаек табылмаган…

Кызганыч, Фәйзелхакның атасы Габделхак агай да нәкъ шушы язмышны кичергән кеше. Бай биографияле үзе. Колхоз эшендә тир түгә, «Мәскәү-Идел» каналын төзүдә дә катнаша. Фронтта – кече командир. Чолганышта калып, әсирлеккә эләгә. Кача. Янә корал тотып, инде рядовой погоннары элеп, фашистларны дөмбәсли. Каты яралана, госпитальдә бик озак дәвалана… Ә сугыштан буш күкрәк белән, бер медальсез, бер бүләксез килеш, авылына кайтып егыла.

Без хәзер кыргый базар мөнәсәбәтләре хөкем сөрүче катгый һәм гафил җәмгыятьтә яшибез. Шәхесеңне таныту өчен, башкарган эш-гамәлләрең генә җитми, компетентлы оешмаларның сине күрүе, ишкә куюы шарт. Гади генә әйткәндә, арттан төртүче кирәк. Бу инде тәрбиядән. Фәйзелхак исә гаделлек, әдәплелек, итагатьлелек, сабырлык, тыйнаклык кебек илаһи сыйфатлар рухында тәрбияләнгән инсан. Ул үзе өчен яшәүче, үз мәнфәгатьләрен хаклап йөрүче түгел.

Хәер, калкытыбрак язсам да, ул үзе, галим буларак, бу мәсьәләгә фәлсәфи кимәлдә якын килә. Ул зар кешесе түгел, оптимист.

Кем белсен, бәлкем әле, яшьлек хыялларына бирелеп, шигырь дә яза башлар?!.

ИншәАллаһ.

Менә шундый егет ул Уразмәтнең фаиз *(җиңүче, максатка ирешүче. – **Ред.**)* углы Фәйзелхак. ■

Редакциядән:

Даими авторыбыз, күренекле галим Фәйзелхак Габделхак улы Ислаевка 2 гыйнварда 75 яшь тулды. Аны әлеге күркәм гомер бәйрәме белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек белән хәерле озын гомер, халкыбызга игелекле хезмәтендә уңышлар теләп калабыз!

Җәүһәр иясе Җәүһәриягә

(Кыйсса)

Әхтәм Зарипов

Исеменнән күренгәнчә, язмам Җәүһәриягә багышланса да, тасвир ителәчәк вакыйгаларда туган авылымны да, авылдашларымны да, туган якның табигатен дә очратырсыз.

Елга-күл, урам-тыкрык, кеше исемнәре, кушаматлар бәян итүгә җиңеллек өчен авылым Таҗыйдан «аренда»га гына алынганлыктан, авылдан әллә ни ерак китеп булмастыр. «Исем җисемне тарта» дигән мәкаль хакыйкатькә нигезләнгән.

Авылымны Станбул дисәм укучыга кызыклырак булыр иде, бәлки. Ләкин мин инде Таҗый дияргә өлгердем. Башка татар авылларыннан төзелеше белән әллә ни аерылмаса да, кешеләренең Таҗыйдан булуын бер күрүдә танyйсың.

...Кеше авылдан шәһәргә акча эшләр өчен китә, диләр. «Шагыйрьләр авылда туа, шәһәрдә үлә» дигән гыйбарә дә бар. Икенчесенең беренчесен юкка чыгаруы кебек бу. Шагыйрь булмасам да, шигырь яратканлыктан, үзем дә иҗат кешесе булганлыктан, ике гыйбарәгә дә искәрмәләр белән генә кушылам.

Безнең буын кешеләре шәһәргә акча эшләргә дип түгел, һөнәр үзләштерергә дип килде. Укуны тәмамлап, һөнәре буенча авылда эш булмагач, шәһәрдә калырга мәҗбүр булды.

80 яшемне узып китсәм дә, үлемҗирләү турында уйлыйсы килми.

Ярый, шәһәргә акча эшләргә китә дигәнгә кушылыйк та ди. Ә авылына кеше рухи байлыгын арттырырга, сәламәтлеген ныгытырга, шәһәр шау-шуыннан, ыгы-зыгысыннан качып, ял итәргә, узган гомер мизгелләрен хәтерендә яңартырга, әби-бабайларының, әти-әниләренең, мәрхүм туганнарының рухына дога кылырга дип кайта.

Мин үзем авылымнан 20 яшемдә аерылдым. Яшьрәк чакта елына бер булса да кайту мөмкинлеген таба идек. Олыгая килә, ял вакытларын җылы якларда үткәрү модасына иярдек. Җәүһәриям тәэсирендә. Сөйләмебезгә Кырым, Кавказ, курорт сүзләре катнаша башлады. Ә менә картлыкка кучкәч, бу сүзләр телдән төшеп, җылы яклар җылытмый башлый, җан җылысын туган яклардан эзлисең икән. Әти-әни үлгәч, ерак туганнар да якынаеп, күрше-күлән дә үз була. Хатлар алыша башлавыбыз кемгәдер нәрсәдер кирәклектән түгел, ә сагыштан, юксынудан булуын ике як та аңлый иде.

Авылдашларымның язмышларын беләсе килү теләге мине якташлар белән очрашу чарасын эзләргә этәрде. Эзләдем, таптым: ниһаять, 80 яшьлегемдә туган авылымда «Якташлар очрашуы» чарасында катнашырга кайтырга булдым. Җирле үзидарә рәисенә оештыру эшләренә керешүне, район хакимияте белән килешүне, газета-журнал редакцияләренә, Башкортстан язучылар берлегенә чакыру билетлары җибәрүне үтенеп хат салдым. Чыгымнары булса, барысын үз өстемә алам, саранланмаска тырышыгыз, дип тә өстәдем.

Билгеләнгән көн килеп җитте.

Очрашуыбыз абруйлы узсын өчен, минем белән скрипкада виртуоз уйнаучы композитор, хөрмәтле дүрт җырчыбыз, телевизион камерасын күтәргән оператор һәм аппаратуралар белән эш итүче инженер да кайтырга ризалашты.

> **«Әмма мин авылымда авылдашларымны да, туып-үскән элекке авылымны да тапмадым.**

Аларны, ял итеп кунсыннар өчен, район кунакханәсенә урнаштырып, үзем «обстановка»ны үзләштерә торырга авылдагы энекәшләрдә тукталдым. Әмма мин авылымда авылдашларымны да, туып-үскән элекке авылымны да тапмадым. Кемгәдер үпкәләвем дә, гаепләвем дә түгел. Яшьтәш һәм кордаш авылдашларымның күбесе мәрхүм, элекке агач өйле урамнарда хәзер икешәр-өчәр катлы ак кирпечтән салынган коттеджлар, аларны каплаган калай коймa аша берни күренми, керим дисәң, капкалар бикле. Һәр ихатадан эт өргән тавышлар ишетелә. Үскән йортым, сүтелеп, читкә өелгән. Аның урынында яңа йорт салу өчен китерелгән кирпеч өеме һәм эт оясы. Моны күргәч, җаным-тәнем аша узган кичерешләрне тасвирларлык сүзләр таба алмыйм. Исемә төшсә, хәзер дә тетрәнәм. Ярый әле янымда Җәүһәриям юк, югыйсә елаудан туктамас иде.

«Монда кем өй салырга җыена?» – дип сорарга кеше таба алмадым. Безгә күрше булганнардан «наследник» дигән яңа токым – өчтуган, ата-бабалары истәлеге булган йортларын әллә каян күчеп килгән нефтяникларга сатып, Төмән өлкәсе шәһәрчекләрендә төпләнгәннәр, имеш. Еларга күз яшьләрем юк, сораштырырга яңа авылдашларым өйләренә бикләнгәннәр.

«Ятып калганчы – атып кал» мәкале кушканча, коймa аша сикереп ишегалдыбызга кермәкче идем, кирпеч өеме артындагы бәйдәге эттән куркып калдым. Ихатаны да, үзем утырткан агачларны да күрмичә, кайттым дип әйтергә телем бармавын белеп, бездән соңгы йорт уры-

ныңдагы «коттедж»ның капкасын кагарга киттем. Кем дә булса чыкмый калмас, гозеремне әйткәч, бәлки әле, экскурсоводым булып, озатып та йөрер.

Капканы шакып торасы булмады, бу күрше мине үз капкабыз янына килеп туктаганнан бирле күзәтеп торган икән. «Мидхәт Әнвәрович», – дип таныштырды үзен.

– Нигә, машинаңнан төшүеңә, миңа кермәдең? – диде ул исәнлек-саулык та сорашып тормыйча, гаепләгән сыман.

– Мин Сезне белмим бит, энем.

– Зато мин сине беләм. Без – синең театрларыңны карап үскән буын. «Әфганчы» дип йөртәләр мине.

– «Фильм-спектакльләр»не дисәгез, дөресрәк булыр.

– Ни дисәң дә, театр инде алар. Иртәгә дә җыелыштан соң театр булачак, диделәр. Вахтага китмәгәннәр очрашуга әзерләнә. Ишетәсеңме, әнә бүгеннән үк җырлап утыралар.

– Аңа әзерләнәсе юк. Килүегез генә кирәк. Бер очрашу – үзе бер гомер.

– Очрашуның ахыры ни белән тәмамлануын үзең дә чамалыйсыңдыр, артист абый. Ну түлке кибеттә берни юк. Халык тетя Нинаны баетыргаябырыла. Ә син аңа ялынып барма, аның техничеський гына. Настоящий спирт Альбертның анасында. Ә Альберт үзе Верхоянскийда, вахтада. Минем сменщик. Анда 90 градустан киме булмый. Медицинский.

– Миңа үзем үскән ишегалдын, бакчаны күрү кирәк, энем. Вакытың булса, озат мине.

– Бер яртылык булырмы?

– Бөтене дә кызганыч булмас, тик бүген түгел.

– Артистларның сүзгә юмартлыгын беләм мин. Аванс кирәк бит.

– Анысы ни була?

– Коры кашык авыз ерта.

– Минем бөтен нәрсәм саквояжда калды, район кунакханәсендә, иптәшләр белән. Алар иртүк монда киләләр. Бәхилләтермен.

– Үзең монда кунгач, энекәшләрең сине көтәләрдер. Бакчаңны карап чыгуга, мин сине аларга озата барырмын да, шунда... бәхилләшербез. Ризамы?

– Бакчаларны карагач, мин әткәй һәм абый каберен зиярәт кылырга бармакчы идем, энем.

– Кабер беркая да китми ул, өлгерерсең.

– Юк инде, караңгы төшкәч, зиратта йөрү килешмәс. Аннан кайтышлый сиңа тукталырмын.

– Хәйләләмә, абзый. Өйдә булмасам?

– Кич белән өйдә булмый кайда булырсың икән?!

– Мәҗлестә! Ахшам намазында! Безнең буш вакыт юк, абзый. Һәр секунд санаулы... Пока!

Әткәм һәм абый каберен зиярәт кылырга ялгызым гына киттем.

...Безнең авылда өч зират булган. Беренче зират 1903 елда ябылгач, ике авыл уртасында икенчесе ачылган. Минем бабам, авылыбызча әйткәндә, картәтәм һәм картыем шул икенче зиратта җирләнгән. Әтиемнең һәм өлкән абыемның кабере авылдан ерак түгел – өченче зиратта. Икенче зират, мин авылдан киткәч, 50 нче елларда ябылып, аның өстенә ике авылга бер урта мәктәп бинасы салынган. 1903 елда ябылган беренче зират өстенә 1934 елда башлангыч мәктәп, авыл советы, почта һәм медпункт урнашачак ике катлы бина салынган. Башлангыч классларда укыганда, бу зираттагы мәрхүмнәргә куелган кабер ташлары арасында качышлы уйный идек. Ул кабер ташларының, җыелып, зират өстендәге башлангыч мәктәп бинасы артында өелүен хәтерлиләр. Соңрак аларны кая озатканнардыр – кемнән генә сорасам да, җавабы – «белмим». Яңа рәис эше, диләр. Зират өстендәге бәдрәфләр, авыл советының җирән алашасы, абзары һәм колхозның идарә атларына салынган конюшнясы турында авылдашларның горурланып сөйләүләрен хәтерлим.

Авылга нигез салучыларның каберләре белән аларга куелган ташларның да юкка чыгуына үкенүчене очратмадым. Гамьсезлек – безнең авыл халкының фамильный тамгасы, дияр идем. Башка сыйфатлары да мактанырлык түгел.

Өченче зиратыбызның капкасы (тимер капкасы) бикле иде. Киләсенә зур гына йозак эленгәнлеген күреп, китә башлагач, каравыл өеннән хатын-кыз тавышы ишетелде:

– Нидән курыктың, бабай? Ялган йозак кына ул, йөз аклыгы өчен генә эленгән.

– Мин йозактан курыкмадым. Зираттан хатын-кыз тавышы ишетү шомландырды.

– Курку гаеп түгел. Мин шуның өчен утырам бит.

– Син кем соң? Синнән куркып, үлемтөшем кимедеме авылда?

– Көлмә, бабай, кемлегемне беләсең килсә, кереп сөйләш.

– Бикле ич йозагың.

– 1903 номерын җый да, кергәч, ул саннарны җуйдырып, йозакны урынына эл… Әнә шулай.

– Булды, ачылды.

– Булса, монда килгән кире китми, кер.

– Авызыңнан җил алсын. Мин әле китмәскә килмәдем, әби.

– «Әби» дигәнеңне җил алсын, бабай. Якынрак кил, зиратта кычкырып сөйләшү ярамый. Кая, чәчәкләр китердеңме?

Шул соравы белән ул, каравыл өеннән чыгып, миңа, капкага таба килә башлады. Килеп җиткәч карасам – каршымда гүзәлләрдән-гүзәл хатын-кыз заты басып тора. Тулы күкрәкләренә карап катып калуымны күргәч һәм сәбәпләрен дә сизенгәч, кыен хәлдән үзен дә, мине дә коткарырга теләп булса кирәк:

– Зиратта гөнаһлы уйларга бирелергә ярамый, бабай. Нәфесеңне тыеп, бисмиллаңны әйт тә йомышыңны үтә.

– Син монда нишлисең, кызым?

– Җомга-шимбә, гает көннәрендә кайтучылар күп була. Ата-аналары, якыннары каберенә чәчәк куеп, дога кылырга киләләр. Күбесе таба алмый. Мин шундыйларга ярдәм итү йөзеннән… Монда комендант.

– Карчыклар эше ич бу, кызым. Кыз кешенең кайда кем җирләнүен белүеннән шикләнмиләрме?

– Әти-әнием, ирем белән улым да шушында җирләнгәнлектән, беләм инде. Кәсебем дә шул бит.

– Әтиең кем иде?

– Моряк Тәмимдар.

– Беләм. Ә «ирем» дигәнең мин белгән кешеме? Шаяртып кына сөйләнүеңме?

– Ир белән шаярмыйлар бездә, бабай. Син бит шушы авылныкы, беләсең, бездә аерылышу модада түгел.

– Соравыма җавап бирмәдең бит. Кыяфәтеңә, үз-үзеңне тотышыңа караганда, шаяртуың да гаеп түгел. Чибәрлегең чиксез, димме, чутсызмы?

– Азынма, бабай. Минем ирем безнең авылга колхозыбыз Татлысу елгасы буенда дуңгыз абзарлары төзегәндә килгән прораб – төзелеш остасы иде. Әрмән егете. Ул мине, мин аны яраткач, әнкәй ризалыгы белән, Шәмсекәй бабайга өч сум биреп, никах укыттык та иске ферма йортында бергә яши башладык. Миңа ымсынып йөргән авыл егетләре, тәвәккәллек итмичә, авыз ачып калдылар. Әрмәнем кызу кеше иде. Көнләшү сәбәпле, сугышлар да булгалады. Кыскасы, малае туганны да көтмәде, үзенә-үзе газраил булды. Бигрәкләр дә кызу канлы, гарьчел кеше иде шул әрмәнем.

– Әрмәнем, дисең… Тагын кемең бар иде? Молдаван, урысмы?

– Улым, дидем ич. Сорама, елатасың.

– Улыңның атасын Әрмәнстанга алып китеп җирләделәрме?

– Хәбәр иттем. Килүче булмады. Детдомда үскән бала иде ул. Шушында җирләдек. Улымны да. Монда андыйлар бер алар гына түгел. Зиратның артты-

рылган ягында дүрт аллеяда шундыйлар күмелә.

– Дүрт аллеяда да әрмәннәрме?

– Ул ялгызы. Беренче аллеяда – эчеп үлгәннәр, өченчедә – башка дин тотканнар.

– Әрмәнем улын да күрә алмады, дидең. Көнләшүе сәбәпме?

– Син миңа шундый сораулар бирәсең, бабай, әйтерсең лә, миңа тәкъдим ясарга җыенасың... Ясап торма, мин риза!

– Сиңа тәкъдим ясаучылар булуына шигем юк, кызым. Язучы буларак, миңа өчегезнең дә язмышы гыйбрәтле. Улыңны эчеп үлгәннәр аллеясында, дидең.

– Андыйлар бер минем улым гына түгел, дидем. Йомышыңны әйт тә... Сәдакаң булса... тартынма, мин биргәннең битенә бакмыйм.

– Авырткан җиреңә тиярмен дип, сорамаган идем, кичер, кызым... Елама, зинһар, мине дә елатасың.

– Улым ялгызы ятса, елар идем. Ярты авыл шулай киткәч, хәсрәткә дә күнәсең, күздән яшь тә чыкмый икән. Эчтән көясең, тыштан көләсең, бабай. Хәер, үзеңнең дә бердәнбер малаеңны югалтканыңны ишетеп беләбез. Зинһар, кайгы-хәсрәт турында сөйләшмик.

– Ризамын. Синең улыңның язмышын бик тә беләсем килгән иде. Бигрәк тә яшьли үлгән...

– Ятим үскән баланың язмышы билгеле инде. Бик авырлык белән үстердем. Әрмиягә китте. Кайткач, тракторда эшләде. Өйләнгәнче йорт салырга тотынды. Кызы башкага чыкты. Әрмән калдыгы, дип мыскылладылар. Эчә башлады. Йоклаган килеш... Сөйләштермә, зинһар...

Төзи башлаган йорты ярты юлда калды. Әни үлгәч, төп йортыбызны үзбәктән кайтканнарга саттым да улым башлаганны төзеп бетердем. Ул планлаштырганча. Әнә, чишмә урамындагы иң биек йорт – улымныкы.

Ярый, бабай, җитәр, бер китап язарлык кына сөйләгәнмендер инде. Бар, Акбабай белән Шәкерт абзый рәнҗеп ятмасыннар... Күрсәтергә кирәкме?

– Ташларын үзем куйдым. Постыңны ташлама.

– Тәһарәтсез керү гөнаһ бит, комган чыгарыйммы?

– Мин сәфәрдәге кеше, намаз укырга ниятем юк, рәхмәт.

– Юл кешесенә дә зиратка тәһарәтсез керү ярамый. Коръәндә коры балчык белән булса да «юынып» тәһарәт алырга кирәк, дигән.

– Анысын белгән булсам да, ихластан кисәтүеңә рәхмәт, кызым. Исемеңне белмим, кем син?

– Газдә, диләр. Моряк Тәмимдар кызы.

– «Акчарлаклар»дан кирәкми. Газизә була инде бу, Газизә. Бәхетле бул.

– Кемнеңдер газизе булырга язсын, бабай. Җылы сүзеңә рәхмәт. Без шул көтеп, өметләнеп яшәү белән генә бәхетледер инде.

– Син әле яшь җан, дәртле, киләчәгең өметле.

– Карале, бабай, куаклыклар басып киткән булса, табалмавың ихтимал. Тапмасаң, Акбабай миңа рәнҗеп ятыр... Иң курыкканым – рәнҗеш.

– Мәрхүмнәрнең рәнҗешен белмим. Тереләрнең сиңа рәнҗү ихтималы булмас. Ягымлылыгың йөзеңдә дә, телеңдә дә. Бәхетле киләчәгеңне сорап, догаңны ташлама.

– Амин, ташламам. Син дә ташлама яхшы карашыңны.

«

Төзи башлаган йорты ярты юлда калды. Әни үлгәч, төп йортыбызны үзбәктән кайтканнарга саттым да улым башлаганны төзеп бетердем. Ул планлаштырганча.

– Акбабай, дидең. Минем әткәйне хәтерлисеңмени? Бик яшь күренәсең бит…

– Яшәртүең өчен дә рәхмәт. Әрмиядән кайткач бер генә ел яшәп үлгән улым яшенә аны 18 яшьтә табуымны кушып санаганда, мин әби инде, бабай. Акбабайның бүләк итеп биргән көянтәсен истәлек буларак саклыйм.

– Газизә, синең очравың минем өчен бик тансык күрешү бүләге булды. Янымда сәдакалык та акчам юк. Иртәгә очрашуга килгәч, бәхилләтермен, үпкәләп калма.

– Миңа очрашуларга йөрү ярамый шул. Исем кушу, ясин чыгуларга йөргән остазбикә булгач, килешмәс тә. Үзең, миңа кереп, дога кылып чыксаң, абруем бермә-бер артыр иде. Сине бит авыл гына түгел, республика да белә. Киноларың буенча гына түгел, үзең турындагы фильм буенча да.

– «Белә дә, киптереп элә дә», диләр. Синең мине белүең кötелмәгән кадерле бүләккә тиң. Очрашуыбыз очраклы гына булып калмасын иде, Газизә.

– Казанга Диния нәзарәтенә, йомышыбыз булганда, хәзрәтебез мине генә җибәрә. ИншәАллаһ, дөньялар тынычимин булса… очрашырбыз.

– Улым үлгәннән соң, Җәүһәрия әбиең гел авылда яши. Мин ялгызым диярлек. Вакыты булганда, оныгым гына килгәли.

– Авыл халкына барысы да билгеле. Сезнең гаиләгә тынычлык, тигезлек теләп, картлар җомга намазыннан соң дога кылалар, карчыклар да калышмый.

– Син дә кушыласыңмы?

– Безнеке аерым бит. Гает көннәрендә кылына…

– Әнә, япун машинасында кемнәрдер килә. Чыгышлый адресым белән телефон номерымны язып калдырырмын. Китмәссеңдер бит әле?

– Адресыңны белсәм дә, телефон номерың зыян итмәс. Акбабай белән Шәкерт абзыйга Коръән чыгу кирәк булса, читтән эзләмә, авылда андый кәсепчеләр күп, үзем чыгармын. Мин кыйммәт алмыйм, кеше үзе белеп биргәнгә ризамын.

– Коръәнне яттан беләсеңмени?

– Яттан белү мәҗбүри түгел, ди хәзрәтебез. Укырга өйрәндем.

– Кайчан? Кайда?

– Коттеджымның өске катын мәдрәсәгә арендага бирдем.

– Авылда мәдрәсә дә бармыни?

– Атнасына өч кенә көн эшли. Хәзрәтебезнең вакытына карап.

– Кем йөри анда?

– Кемгә дә ирек. Бик теләп йөриләр. Хәзрәтебез кайчандыр Ленинградтагы партакадемиядә укыган, бик грамотный кеше. Партия таралгач, Уфага йөреп, указлы мулла булды.

– Дипломлы?

– Ул аны «диплом» дими, «сертификат», ди. Миңа да эшләтеп бирде. Кызыксынсаң, күрсәтәм.

– Болай да ышанам. Эзләнмә. Япун машинасы кая китте? Монда тукталмадылар.

– Алар зиратның арттырылган капкасыз ягына киткәннәрдер. Мөселманнар түгелдер. Бар, бабай, мөселманлыгыңны онытма.

– Оныттыра яздың шул, Газизә. Тәүбә әстәгъфирулла, онытылу да бәхет икән… Рәхмәт сиңа!

…Абыйның кабере каралып, чүпләре уталган кебек, әткәйнең чардуганы бер якка авышкан, һәйкәле «аягында» тора. Чәчәк түтәлен чүп үләннәреннән арындырып, әткәй өйрәткән «Колхуаллаһы»ны укыгач, башка әрвахлар рухына дога кылу нияте белән яр буена табарак киттем. Анда әфган, Чернобыль һәм Чечня корбаннары җирләнүен беләидем. Колхозның беренче рәисе дә шунда җирләнгән. Аныкыннан битәр, аның улы авиация полковнигы Ривнер Хафизовка куелган һәйкәлне күрәсем килә иде. Ләкин һәйкәле юк, тигезләгән урыны гына калган иде.

Дәвамы бар ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Корея. XX гасыр башы



«Галәм-е Ислам» («Ислам дөньясы») китабының икенче томының тышлыгы

Милләтебезнең олы шәхесе Габдерәшит Ибраһимовның (1857-1944) «Галәм-е Ислам» («Ислам дөньясы») исемле зур күләмле сәяхәтнамәсе беренче тапкыр госманлы-төрек телендә Истанбулда ике китап булып басылып чыккан. Аннан соң ике тапкыр хәзерге төрек теленә күчереп бастырылган. Беренчесен 1987 елда Мехмет Паксу, икенчесен 2012 елда Әртугрул Өзалп әзерләп бастырган. Бу хакта «Безнең мирас»ның 2017 елгы 1 нче санындагы кереш сүздә шактый тулы мәгълүмат бирелде, кабатлау кирәкмәс дип уйлыйм.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

«Галәм-е Ислам»ның асыл нөсхәсе китаплары күләмнәре буенча бертөрле түгел: беренчесе күпкә зуррак. Габдерәшит Ибраһимов, китабының беренче томында Япониядән соң әле Корея һәм Кытайдагы сәяхәте турында да язып, аны Сингапурга килүе белән тәмамлый. Борынгы китапларның форматы зур, бүгенге журнал форматында басылганнары да бик күп, шуңа да гарәп хәрефләре белән басылган зур форматлы китап өчен бу проблема тудырмаган, күрәсең. Хәзерге төрек теленә күчереп бастырганда, тәрҗемә авторлары китапны үзләренчә бүлгәннәр һәм, нәтиҗәдә, якынча бертигез күләмле ике китап барлыкка килгән. Мәсәлән, Әртугрул Өзалп әзерләгән басманың беренче китабы – 656 бит, икенче китабы 631 бит тәшкил итә. Бу бүленештәге беренче китап Япония сәяхәте белән тәмамлана. Корея, Кытай, Сингапур, Һиндстан, Гарәбстан сәяхәте һәм Госманлы дәүләтенә килеше исә икенче китапка кертелгән.

Менә шул яңа бүленештәге беренче китапның татар теленә тәрҗемәсе инде тәмам. Тәрҗемәнең күп өлеше «Безнең мирас»та басылып барды. Хәзер аның китап варианты әзерләнәчәк, эшләр уңышлы барса, озак көттермичә, ул укучыларның кулына барып ирешер дип өмет итәбез.

«Безнең мирас» редколлегиясе яңа 2021 елның беренче саныннан башлап «Галәм-е Ислам» сәяхәтнамәсенең яңа бүленештәге икенче китабын шулай ук өлешләп бастыра башларга дигән карар кабул итте. Шулай итеп, Габдерәшит Ибраһимовның «Галәм-е Ислам» («Ислам дөньясы») сәяхәтнамәсен, госманлы-төрек телендә басылган төп нөсхәсен дә файдаланып, төрек теленнән тәрҗемә итеп, «Безнең мирас»ның хөрмәтле укучылары игътибарына җиткерүебезне дәвам итәбез.

Бөек Габдерәшит бабабызның уй-фикерләре җәмгыятебезнең уйлана һәм борчыла белгән фикерле катламы тарафыннан гасырлар аша килеп җиткән җан эндәшүе итеп кабул ителсен иде. Сүзебез рухына дога булсын!

Асия Рәхимова

Корея

Япония пароходы белән Симоносекидән Пусанга юлга чыгарга җыенам. Симоносеки һәм Можо тирәсен берәр көн карап йөрдем. Шуннан соң, Кореяга китәр өчен, пароходка утырырга дип килдем. Пароходның сәгать ничәдә китәчәген сорагач, капитаннан шундый җавап алдым: «Китәрбезме, юкмы – мин әле менә шул турыда уйлыйм. Зур давыл кубарга тора. Үтеп чыга алырбызмы икән? Идарәгә телеграмма суктым, катгый әмер килсә, китәрбез. Тик менә Сезгә иртәгә китәсе пароходка калырга киңәш итәм. Давыл бик куркыныч булачак».

Бер сәгать тә үтмәгәндер, капитан, кабат килеп, болай диде:

– Мин китәм, әмер килде. Сез нишләргә уйлыйсыз?

– Әлбәттә, мин дә Сезнең белән китәм. Юлны ничә сәгатьтә үтәрбез икән?

– И-и, бу һава торышында пароходның араны ничә сәгатьтә үтәсен әйтеп буламы?! 12 сәгатьтә үтә алсак, начар булмас иде. Карарбыз. Бик көчле давыл булачак. Шул сәбәпле, бәлки, 12-13 сәгатьтә үтә алырбыздыр дип уйлыйм.

Инде китәргә дигән карарга килгәч, китәргә! Пароход бик кечкенә. Аллаһы Тәгалә исән-сау барып җитәргә язсын!..

Урыным пароходның беренче дәрәҗәдәге катында. Идәнгә нәкъ япон өйләрендәге кебек камыштан үрелгән чыпта түшәлгән. Шул чыпта өстенә һәр юлчы үзенең урынҗирен җәя дә ята. Бу катның икенче дәрәҗәдәге каттан һич аермасы юк. Бары тик аурупа ысулы белән җиһазланган бер залы гына бар. Ул да бик гади, бар булган

җиһазы – бер өстәл белән берничә урындык. Каюталарның барысы да япон ысулы белән түшәлгән, шулай булса да, каюта дип атала.

Пароход кузгалып китте. Кичке сәгать 7 иде. Әле ачык диңгезгә кергәнче үк, юлчыларны «диңгез чире» тотты. Пароход дулкыннар өстенә бер менә, бер төшә. Давыл алды хәлләре башланды. Бик нык күңелем болганып, косасым килә, шуңа түзәргә тырышам. Шулай бер сәгатькә якын азапландым, аннан соң инде түзәрлек хәл калмады. Юлчылар, җансыз нәрсәләр кебек, тәгәрәшеп яталар. Пароход хезмәткәрләре юлчыларның косыкларын җыештыру белән мәшгуль. Ярдәм итәргә дә телиләр, ләкин алар да көчкә түзә, түзә алмаганнары да бар. Ниһаять, бар да үзен Кодрәт иясенең кулына тапшырды. Ярты үле, ярты тере хәлдә яту. Капитан һәм ярдәмчеләре, ара-тирә килеп, юлчыларны юатырга-тынычландырырга телиләр. Тик колакларга берни керми. Йокладыммы мин, һуштан яздыммы – белмим. Аннан соңгысын инде бөтенләй хәтерләмим.

Иртән иртүк күземне ачтым, ни күрим: өс-баш та калмаган, урын-җир дә калмаган. Бөтен юлчылар да шулай үз быкырдыклары эчендә яталар.

Пароход Фузан (Пусан) портына якынлаша иде. Һава искиткеч матур, ләкин диңгез генә әле һаман да тынычлык тапмаган. Шулай итеп, үзебезне көч-хәл белән җыеп, киемнәребезне рәтләдек. Бераз күзләрем ачылды, тик баш кына үземнеке түгел. Шундый авырлык ки, кыйнап ташлаганнар, диярсең, сөйләп-аңлатып бетерерлек түгел.

Иртәнге нәкъ 8дә пароход Пусан портына кереп ләңгәр[1] ташлады. Шунда ук пароходка каекчылар кереп тулды. Бар да японча сөйләшә.

Корея хатын-кызлары. XX гасыр башы

Корея кешеләрен күргәч, Урал башкортларын күргән кебек булдым. Боларның бар яктан да Урал башкортлары белән охшашлыклары бар. Киемнәре нәкъ башкорт киеме, йөзләрендә дә искиткеч охшашлык. Мин әле пароходта ук, бу каекчыларны күрүгә, бераз икеләнеп калган идем, башыма: «Уралдан эшчеләр килгән булуы мөмкинме, гаҗәп?!.» – дигән уй килгән иде.

Каекларга утырып, ярга чыктык. Йөкләрегезне тикшерәбез, дигәннәр иде дә, бик игътибар биреп тикшермәделәр. Минем биредә бары тик шуны әйтеп үтәсем килә: каекчы мине пароходтан Корея җиренә, ярга китерде. Вак акчам юк иде, ярты (0.5) йен бирдем. Каекчы акчаны алып китеп барды. Мин моны игътибарга алмадым, 6 тиен акча инде. Таможнядан үтеп, йөгемне алдым, рикша тотып, Тишаба поезд станциясенә киттем. Поезд кузгалырга әле вакыт бар икән. Мин, бераз капкалап алыйм, дип, шундагы япон кунакханәсенә кердем. Кунакханәдән кире чыгып килгәндә, юксыл гына бер кеше миңа 4 тиен кыйммәтендәге акча суза.

– Бу нинди акча? – дип сорыйм.

– Каекчыга 50 син (0.5 йен) биргәнсез, шуның артыгы.

Менә бу табигый тәрбия. Аурупа халыклары кыргый һәм варвар дип атап йөрткән Шәрыкта менә ниләр бар! Бердән, әллә ни зур акча түгел, аннары ул

[1] Фарсы телендә «якорь» мәгънәсендә кулланыла торган бу сүз иске татар теленә дә ят булмаган, хәзерге вакытта әйтемнәрдә генә очрый ***(тәрж. иск.)***.

таможня торган ярдан поезд станциясенә кадәр бер 20 минутлык юл. Кем эзләсен дә кем тапсын?! Тик Шәрык тәрбиясе Тәңре колларының хакына бөтенләй башка күз белән карый шул. Бичара каекчы күргән инде: мин, бер бичара юлаучы, каекчы бәяләрен дә белмим. Шуңадыр, вөҗданы кушуы буенча, мине эзләп табуны, бу акчаларны тапшыруны дөресрәк дип санаган, күрәсең. Акчаны китереп биргән кешедән сорыйм:

– Каекчы синме?

– Әйе, мин.

– Ник шунда ук әйтмәдең соң? Артыгын хәзер бирәм, дисәң, көтеп торган булыр идем.

– Мин тиз генә акчаны ваклатырмын да килермен, дигән идем, килеп җитешә алмадым. Кибетләргә үк барырга туры килде. Килдем, Сезне таба алмыйча, бик борчылдым. Гафу итүегезне сорыйм.

Инде бу вөҗдан каршысында мин дә үземне үлчәп карадым, дөресрәге, бик оялдым, чөнки корея кешесе карашында мин дә бер аурупа кешесе идем шул. Каекчы гүя миңа болай диде: «Сез безне кыргыйлар дип саныйсыз, тик без үз намусыбызны яхшы беләбез. Төп һәм чын мәдәнилек ул барыбер бездә!»

Пусан – сәүдә порты

Пусан – Корея яр буендагы бик матур порт. Бу порт ясалма түгел, аны табигать үзе барлыкка китергән. Шәһәре исә, кечерәк кенә бер бистә кадәр. Биредә яшәүче халык тулысынча корея милләте кешеләре, әмма түрәләр һәм гаскәриләрнең барысы да – японнар. Пусан шәһәрчегендә, яңа гына төзелгән хөкүмәт биналарыннан башка, күзгә ташланырлык берни дә юк. Җирле корея кешеләренең өйләре искиткеч пычрак һәм җимерек алачыклардан гыйбарәт. Камыштан ясалган күләгәлекләр күренә. Шәһәрчекнең тирә-ягы таулар белән әйләндереп алынган. Тауларда сибелеп яши торган фәкыйрь корея халкы турында «дөнья белән бәйләнеше юк кешеләр» дип әйтүдән башка сүз табып булмый. Бу Пусанның әйләнә-тирәсендә ике сәгатькә якын йөрдем, карадым. Монда бар да дүрт-биш өйле яки сигез-ун өйле авыллар. Өйләрен «улус» дип йөртәләр икән.

Японнар белән чагыштырганда, биредә шактый нәрсә башкача. Иң беренче, кайсы гына өйгә керсәң дә, ирләр генә күренә, хатын-кыз очрамый. Ул тауларда берничә өйгә кердем, гел шулай. Бер өйдә: «Сезнең хатыннарыгыз кайда соң?» – дип сорадым.

Шул вакыт сөйләделәр: боларда да, безнең ислам гореф-гадәтендәгечә, хатын-кызлар бүлеме аерым икән. Чит кешенең ул якка керүе катгый тыела, һич рөхсәт итмиләр икән. Ишеге дә аерым. Хатыннарда хиҗап ише нәрсә дә бар икән. Болар хакында яхшылап сорашып белгәннән соң, җентекләп язармын.

Ул көнне өйлә вакытында Пусаннан поездга утырып, Кореяның башкаласы Сеул шәһәренә киттем. Пусан тимер юл станциясе әле төзеләчәк кенә икән. Вагоннар, рельслар Япониядәге тимер юлларга да, Русиянекенә дә охшамаган, хәрбиләр тарафыннан полк-полк солдат җибәрү өчен салынган, диярсең. Вагоннар 100-120 кеше сыярлык, бик зур. Мин бер генә илдә дә мондый вагоннар күрмәдем. Бар да өченче дәрәҗәле вагоннар. Беренче, икенче дәрәҗәле вагоннар әлегә юк, бары тик атнага ике тапкыр экспресс өчен ике вагоннары бар икән.

Сәгать өченче ярты иде, Гизан шәһәренә килеп җиттек. Карыйм, халык җыелган, байраклар элгәннәр. Бу кечкенә генә шәһәрчектәге халыкның күплеге игътибарымнан читтә калмады.

Биредәге станция хезмәткәреннән сорадым:

– Бер көнгә биредә кала алырмынмы икән? Билетым Сеулга кадәр алынган иде.

– Кала алырсыз, – диде. – Билетыгызга тукталу тамгасы сугарбыз. Ләкин биредә кунарлык урын таба алырсызмы икән?

– Ник, табып булмасмы икәнни?..

– Табылуын табылыр да, ләкин кунакханә-фәлән юк. Берәр корея кешесенең өендә тукталсагыз, урын бирерләр, тик бик пычрак булыр.

– Зыян юк, бер кичкә калырмын. Тик, зинһар, йөгемне станциядә сакларга калдырыймчы, мөмкин булыр микән?

– Булыр, кыен эш түгел, болай үзегез белән йөртә алмаячаксыз, билгеле.

Шулай итеп бер кичкә монда калырга карар бирдем, йөгемне вагоннан төшердем.

Әйберләремне станциядәге саклау бүлегенә тапшырдым, аның хезмәткәре миңа болай диде:

– Акчагызны да калдырсагыз, начар булмас, саграк булу кирәк. Берни дә булмас, бәлки. Тик авыл кешеләре бүген бар да исерек. Корея кешеләре, гомумән, көн саен исерек! Тик бүген һәрвакыттагыдан да исерегрәк, чөнки бәйрәм көннәре. Шуңа төркем-төркем җыелалар.

Янымдагы акчамны да калдырдым. Авылга таба китеп барырга җыенган гына идем, станция хезмәткәре миңа болай диде:

– Төн кунарга, теләсәгез, японнарга барыгыз. Әнә теге япон ысулы белән салынган өйләр бар да безнекеләрнеке. Анда тынычлап йокларсыз. Корея кешеләрендә куна калсагыз, бик тыныч булмас. Кызыксынып, күрергә теләсәгез, әлбәттә, аларда да калырга мөмкин, мәсьәлә юк. Тик хатын-кызлар өчен аерым билгеләнгән бүлекләренә керә күрмәгез, алар хатыннар ягына аяк баскан ир-аттан, намус дәгъвасы, дип, үч алалар.

– Йә, ул нәрсә инде тагын? Мин телләрен дә белмим, ялгышып барып кереп, берәр хәл килеп чыга күрмәсен.

– Күбесе японча белә. Корея кешеләре хатыннарын чит кешеләрдән яшерәләр. Яшь хатыннар ирләргә йөзләрен дә күрсәтмиләр. Бүген күбесе исерек тә, шунда ук кызарлар.

Бераздан мин Гизан шәһәрчегенә барып җиттем. Шәһәр читендә зур гына халык төркеме җыелган. Бер якка – Япония байрагы, икенче якка Корея байрагы эленгән. Халык дүртпочмак рәвешендә җыелып тора, уртада ике егет көрәшә. Менә шулай итеп, корея халкының көрәшен дә күрдем. Нәкъ тә безнең Урал башкортларының көрәше кебек. Бер-берсен биленнән киң билбау кебек нәрсә белән тотканнар. Көчлерәге көндәшен югары күтәреп ала да җиргә егып сала, тегесе кайда ятса да ята. Җиңүчегә берничә аршын тукыма бирәләр икән.

Мин дә килеп бастым, кырыйдан карап торам. Бер-ике сәгать шунда көрәш карап тордым. Бик ошаттым, нәкъ менә безнең мәмләкәт көрәше. Корея кешеләре без татарлар җилән дип йөртә торган ап-ак кием кияләр. Бары башларында гына аурупа кешеләренең эшләпәсенә охшаган башлыклар. Башларында безнең татар кәләпүше дә булса, бөтенләй Татар иле булып чыгар иде. Нигездә, корея кешеләренең элеккеге баш киемнәре татар кәләпүшенә охшаган булган, соңрак бу эшләпә кебек нәрсәне үзләре саламнан үрә башлаганнар.

Шәһәр аксакалларыннан берничә кеше алдым һәм шәһәр карарга чыктым. Шәһәр эчендә күбрәк хатын-кыз иде. Өйләрен карадым, бер генә чиста өй дә таба алмадым. Кичкә япон өенә барырга мәҗбүр буласымны уйладым.

Корея кешеләренең бик күп нәрсәсе безнең татарларныкына охшаган. Бигрәк тә хатын-кыз киеме. Өй эчендә «сәки»[2] дип йөртелә торган бүлмә һәм башка бик күп

нәрсәләр бар, гел менә татар әхлагына охшап тора. Сөттән «дарасун»[3] әзерләүләре һәм башка тагын бик күп яклары да охшаш. Әмма тел буенча бернинди якынлык юк, бу – катгый.

Мин анда тирә-юньдәге авылларга да бардым. Бөтен авылларда да бәйрәм итәләр иде. Гел шул көрәш мәйданы, бар җирдә дә үз милли йолаларын башкаралар, кешеләр арасында да нindидер ярышлар үткәрәләр икән. Барган бөтен җиремдә корея кешеләре арасында бик күп исерек күрдем. (Япониянe айлар буе гиздем, ләкин бер генә исерек кеше дә очратмаган идем.)

Авыллардагы ындыр табаклары да безнең татарларныкына охшаган. Бәйләнгән көлтәләрне җыеп, ике кеше, дүрт кеше, алты кеше, кара-каршы басып, таяк башына бәйләнгән уклау белән ул көлтәләрнең башына бәргәлиләр, нәкъ бездәге кебек.

Ул көнне кич Гизанга якын гына урнашкан җиде-сигез өйле бер авылда калырга мәҗбүр булдым. Йөри торгач, бик кичкә калганымны аңладым. Шулай итеп, бер төнне корея кешеләре авылында үткәрергә туры килде. Тик үзең теләп риза була торган нәрсә түгел иде бу. Бар җир пычрак, төнлә дә учак ягалар, төтеннән сулыш алырлык түгел. Шуның өстенә әле тагын, өй хуҗалары ирле-хатынлы икесе дә исерек, таң атканчы кычкырыштылар. Шулай итеп ул төнге йокым әрәм булды, иртән таң атуга ук чыгып киттем.

> «Тик хатын-кызлар өчен аерым билгеләнгән бүлекләренә керә күрмәгез, алар хатыннар ягына аяк баскан ир-аттан, намус дәгъвасы, дип, үч алалар.

Ул көнне дә өйләгә кадәр йөрдем һәм соңыннан, поездга утырып, Сеулга киттем.

Тимер юл буйлап барганда, ике якта да иген басулары, болыннар, кырлар кала, бик күп җирдә дөге чәчелгән, кая карама – утлап йөргән хайван көтүләре. (Япония болынлыкларында исә хайваннар бер дә күренмәгән иде.) Көтүләре шактый зур, егерме-утыз хайванлы көтүләр сирәк кенә очрый. Ат, сыер, сарык – бар да бар. Ерактан урманнар да күренеп тора. Кореяда җирләр чагыштырмача киң һәм уңдырышлы булса да, милләт үле милләт булганга, тормыш гөрли дип әйтеп булмый. Бары тик японнар яшәгән җирләрдә генә тормыш җанлылыгы сизелә. Японнар үзләре өчен тырышып хезмәт иткәннәр һәм хәзер дә тырышалар. Корея кешеләренең өйләре арасында бер япон йорты булса, ул әллә кайлардан күренеп тора. Чирәп түбәле бер өй күренсә, ул, һичшиксез, япон кешесенең өе булып чыга. Корея кешеләренең өй түбәләре салам белән ябылган. Сирәк булса да такта түбәле өйләр дә бар, ди, ләкин минем күземә чалынмады. Кайда арулык – шунда, һичшиксез, берничә генә булса да япон өе була.

Вагоннардагы юлчыларның күпчелеге – корея кешеләре. Ләкин станция хезмәткәрләре яки кондукторлар арасында бер генә корея кешесе дә күренми.

Җөмәдиәл-ахыр[4] якшәмбе көнне – 20 июнь – айны күрдем: югарыда иде. Сәгать тугызларга кадәр йөрдем. Айның өченче төне иде, ахры.

Сәгать ун тулганда Сеулга килеп җиттем. Станциянең бөтен җире электр утлары белән яктыртылган иде.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

[2,3] Сәяхәтнамәнең госманлы-төрек телендә басылган төп нөсхәсендә куштырнаклар эчендә бирелгән бу сүзләрнең, беренчесенең искәртелүеннән чыгып, икенчесенең, ягъни «дарасун» сүзенең дә корея телендә бирелүен фараз кылабыз. Бурят телендә бу сүзнең «әче» мәгънәсе бар ***(тәрҗ. иск.)***.

[4] Җөмәдиәл-ахыр – ай календаренең алтынчы ае ***(тәрҗ. иск.)***.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Мәңгелеккә юнәлеш

Индус Таһиров

Чыңгыз хан

Мизарымнан мин сорармын:
«Татар бармы?!»
Ала алмасам яхшы җавап,
Аһ, җылармын!
Мәхмүт Ниязи

Мәңгелек сүзен кулландым да, шунда ук аңа төзәтмә кертүне кирәк таптым. Чөнки мәңгелек ул – тик Аллаһы Тәгалә үзе генә. Калганнарның барысы да вакытлы. Безнең өчен мәңгелек чикле рәвештә, Җир шарының Кояш тирәсендә әйләнү вакыты белән генә билгеләнә. Милләтебезнең мәңгелеге дә шуның белән чикләнә.

Без, татарлар өчен, мәңгелек – Кояш сүнгәнчегә кадәр яшәү.

Мине һәрвакыт диярлек шул мәңгелекнең үткән кадәресе, бүгенгесе һәм иртәгесе турындагы уйлар, хатирәләр били.

Уй исә – адәм баласына бирелгән искиткеч бер халәт. Ул яктыдан да, тавыштан да тизрәк йөри. Уй гасырлар төпкеленә төшәргә дә, яшен тизлеге белән бүгенге көнгә кайтырга да, киләчәккә үрелеп карарга да мөмкинлек бирә.

Ул кешенең күз алдына үткән заман шәхесләрен дә, кичәге һәм бүгенге замандашларын да китереп бастыра ала. Аның мөмкинлекләре иксез-чиксез кебек...

Ләкин кебек кенә, чөнки ул боларны бары тик хыялый рәвештә генә эшли. Аның бернинди гамәли мөмкинлекләре дә юк. Ул үткәннәрне кайтара алмый, соңга калган уйлар рәвешендә генә яши.

Тик менә ничек кенә булмасын, алардан котылып булмый. Алар – адәм баласының мәңгелек юлдашы.

Уйларның төрлесе була. Кайберләре шатлыклы, кешегә дәрт һәм дәрман биреп тора. Икенчеләре исә үкенү-уфтануларга, өметсезлеккә юл ача. Боларның кайсысы өстенлек итүе кешенең кәефе нинди булуыннан тора. Шул ук вакытта уйланулар үзләре кәеф чыганагы булып торалар. Кыскасы, болар бер-берсенең йогынтысы астында яши. Һәм күпвакыт язмыш чыганагы булып торалар.

Сүз, әлбәттә, шәхси язмышлар турында гына түгел, ә ил, милләт язмышы турында да бара. Әгәр мине уйлар үткән гасырларга алып кереп китә икән, мин инде, һичшиксез, борынгы дәүләтләребезне, аларның күренекле шәхесләрен барлыйм. Аларга үз бәямне бирергә тырышам. Һәм үз-үземә: «Татар кебек заманында дөньяны дер селкетеп торган кавем нилектән коллык чоңгылында калды икән?» – дигән сорау куям.

Атилла, Чыңгыз бабабыз, Батый хан кебек олуг шәхесләр дәүләтләребез барлыкка килүгә юл ачканнар, ә Шаһгали кебек мөртәтләр аларның дәрәҗәсен түбәнәйтүгә сукмак салганнар. Аннан соң бөтенләй юк итү өчен киң юл ачканнар. Боларның барысы да тарихыбыз битләренә ныклап уелган.

Рус патшаларының рус булмаган халыкларга карата кылган явызлыклары да халкыбызның тарихи хәтерендә саклана. Явыз Иванның, аның иярченнәренең дәүләтебезне юк итүе, Петр Iнең татарларга карата кылган явыз һәм мәкерле гамәлләре, Александр IIIнең «Россия для русских» идеясен калкытуы һәм болардан башка күп этлекләре һич кенә дә халкыбыз хәтереннән җуелырлык түгел.

Халык хәтерендә, җылы хис тудыра алырдай бердәнбер патша буларак, динебезгә ниндидер рәвештә юл ачкан Екатерина II образы саклана. Ләкин аңа да Кырымны яулау, татарларны дәүләтсез калдыруның кара күләгәсе төшә.

Шушыларны барлап чыгам да бер фикергә киләм: бөеклегебезнең дә, коллык чорыбызның да сәбәпчеләре – ниндидер аерым шәхесләр генә түгел, ә милләт үзе. Уңай сыйфатлары өстенлек иткәндә, ул бөек һәм данлыклы кавем булган, ә тискәреләре беренче урынга чыккач, коллык упкынына дучар ителгән.

Татар фаҗигасенең иң югары ноктасы – биек кыядан төпсез коега мәтәлүне хәтерләтүче коллык упкынында яши башлаган 1552 ел. Бу – татарның Казаныннан, гомер буе яшәп килгән авыл җирләреннән сөрелеп, аны ата-бабадан калган диненнән коточкыч ерткычлыклар белән яздыра башлау елы.

Бәлки, башка милләтләр шундый язмышка дучар булсалар, күптән юкка чыгарлар иде. Әмма татар үзгә халык. Аның канына буыннан-буынга күчеп килә торган яшәү көче сеңгән. Аңа шушы елларда ата-бабаларыннан васыяти рәвештә калган ислам дине юлдаш булган. Ул аны бетмәс-төкәнмәс афәтләрдән коткара килгән.

Татар, ят камалышта калса да, аңа чукындыру һәм руслаштыру сәясәте янаса да, боларның берсенә дә бирешмәгән. Чөнки дини тәрбия милли яшәешнең төп сыйфатына әверелгән. Заманында күренекле тарихчы **Н.А.Фирсов** болай дип язган: *«Ни убеждения миссионеров, ни льготы, даруемые правительством за переход к христианству, ни обстоятельства, что им приходилось разоряться от платежа за новокрещеных податей, ни уничтожение их мечетей не действовали на них; огромнейшее их большинство оставалось твердыми в вере отцов и дедов, между тем, как живущие рядом с ними язычники почти поголовно крещены».*

1870 елны Сембер шәһәрендә чыккан бер китапта, татарлар русларга рухи яктан түгел, тик сәяси рәвештә генә буйсындылар, алар Россиянең иң ныклы, башкаларга да йогынты ясаучы халкы, дип язылган. Һәм бу, чыннан да, шулай.

> «Мәгълүм сәяхәтче Иоанн де Плано Карпини, татарлар яхшы сугышчылар, чыдамлылар, 1-2 көн ач торсалар да, бернинди түземсезлек күрсәтмиләр, киресенчә, ныклап ашагандай уйныйлар, җырлыйлар, дип язган.

Галим-миссионер **Евфимий Малов**ның 1904 елның 30 сентябрь-14 октябрь аралыгындагы көндәлек язмалары арасында уфтанып язылган мондый юллар бар: *«Без, руслар, ун гына түгел, йөзләгән еллар дәверендә татарлар өстеннән хаким сыйныф рәвешендә яшибез. Инде Казан алынганнан соң да өч йөз елдан артык вакыт үтте, тик менә без аларны күпме дәрәҗәдә генә руслаштыра алдык икән соң? Тагын да өч-дүрт йөз ел көтәрбезме икәнни?»*

Бу очракта динебезнең милләтебезне яңа шартларга ияләштереп, аңа яшәү көче иңдергән икәнлеген ассызыклап китү урынлы булыр. Бу – кадимчелек чоры. Шушы чорда татар үзенең мәгариф һәм милли тәрбия системасын барлыкка китергән. Инде ниһаять, ныгып, үзендә ышанычлы яшәү көче барлыкка килгәч, ул, ныклы адымнар белән, дөньяви фәннәр үзләштерү юлына баскан. Шуның белән кадимилек чорының тарихка китү вакыты җиткән, җәдитчелек чоры башланган.

Тик бу процесс үзеннән-үзе түгел, ә адәми затларның үзара мөнәсәбәтләре рәвешендә барган икәнлеген онытырга ярамый. Монда бер-берсенә каршы гамәлләр дә, гаепләүләр дә, низаглар да булмаган түгел. Бу – искелек һәм яңалык мөнәсәбәтләре, аларның үзара каршылык-бәрелешләре.

Ләкин безгә шул чорлардан соң яшәгән татарларга, бигрәк тә бу гамәлләрне өйрәнүчеләргә шушы каршылыклардан өстен булу таләп ителә. Җәдитчеләрне яклап, кадимчеләрне хурлау һич кенә дә гаделлек принцибына туры килми. Аларның икесе дә бер җепкә тезелгән, җәдитчеләр кадимилек кабыгында барлыкка килгәннәр. Бу хәл аталар белән балалар арасындагы каршылыкларны хәтерләтә.

Ул вакыттагы каршылык-бәрелешләр татарны чыныктырган, аңа яшәү көче иңдергән. Нәтиҗәдә, татарлар Россиянең иң укымышлы халкына әверелгән, XIX һәм XX гасыр чикләрендә могҗизаи рәвештә яңарыш кичергән. Башкорт галиме Билал Юлдашбаев язганча, мисали ислам милләте булып өлгергәннәр.

Монда, һичшиксез, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, аларның дәвамчылары һәм аларга каршы фикерле шәхесләр дә булганлыгын онытырга ярамый.

Шәхесләргә карата төрле мөнәсәбәттә булу, аларның кайсыларын сагыну, кайсыларын каһәрләү һәрвакыт булган, бар һәм булачак та. Ләкин тарихның теге яки бу борылышларына сәбәп – халык үзе, дөресрәге, аның холык-табигате, төп сыйфатлары. Ил язмышын да шулар хәл итә.

Милли холык гасырлар дәвамында формалаша һәм бертуктаусыз чарлана тора. Аның тик шушы халыкка гына хас булган сыйфатлары барлыкка килә. Тик ул бер халыктан икенчесенә күчми, бары төп сыйфатлары гына буыннан-буынга күчә бара.

Шул ук вакытта тугандаш халыкларның күп кенә уртак, берләштерүче сыйфатлары да була. Алар тел, гореф-гадәтләр белән бергә барлыкка килә һәм,

Иоанн де Плано Карпини

таркалганнан соң да, үзләрен сиздереп тора. Славяннарның – үзләренә, төркиләрнең дә үзләренә генә хас, канга сеңгән, аларның якынлыгын тәэмин итүче сыйфатлары бар. Кан тартмаса, җан тарта, җан тартмаса, кан тарта, дип юкка гына әйтмиләрдер.

Мәгълүм сәяхәтче **Иоанн де Плано Карпини,** татарлар яхшы сугышчылар, чыдамлылар, 1-2 көн ач торсалар да, бернинди түземсезлек күрсәтмиләр, киресенчә, ныклап ашагандай уйныйлар, җырлыйлар, дип язган. Аңардан ничәмә-ничә гасыр соңрак яшәгән **Абай Кунанбаев** та татарларга шундый ук бәя биргән. Алар яхшы яугирләр, авырлыкларны батырларча кичерәләр, үлем сәгатен сабыр кабул итә беләләр, дигән ул.

Татарларның башка уңай сыйфатлары да аз түгел. Түгел, дим, чөнки алар бүгенге татарларга да хас. Татарның юмартлыгы, кунакчыллыгы, ачу сакламавы һәм башка уңай сыйфатлары күпләр тарафыннан таныла килгән.

Уйлануларым мине шул сыйфатларның берсенә ныклап тукталырга мәҗбүр итә. Ул да булса – татарларның башкаларга ышанучанлыгы, аларга юл ачучанлыгы. Татар берәүне дә кимсетмәгән, берәүне дә җәберләмәгән, диннәреннән яздырмаган, көчләп үз диненә күчермәгән. Киресенчә, ул башка диннәргә, бигрәк тә православиегә юл ачкан, аларга хәтта тел тидерүне дә тыйган. Шушылар турында уйланулар бу ышанучанлык кирәгеннән артык булмадымы икән, дигән сорау тудыра.

Бәлки, аларга буйсындырган халыкларны ислам диненә күчерергә кирәк булгандыр? Хатамы бу, әллә татарга хас мәрхәмәти сыйфатмы? Әйтүе кыен. Ләкин ничек кенә булмасын, аның бу сыйфаты үзе өчен явыз кайтавазга әверелә, аны аягыннан ега яза. Ега алмаса да, бик нык зәгыйфьләндерә.

Сүз башкаларның, татарны җиңү белән үк, аңа карата көчләп чукындыру, нәтиҗәдә, диненнән яздырып, бүгенге көнгәчә дәвам иткән руслаштыру сәясәте үткәрүе турында бара. Аның максаты 1870 елны кабул ителгән документта ачыктан-ачык күрсәтелгән. Столыпинның илдәге татар йогынтысына багышланган 1910 елгы киңәшмәсендә дә бу акка кара белән язылган.

Уйлар мине үткән бөеклек чорына алып кайта һәм мин үз-үземә, татарлар киләчәкләрен күзаллый алган булсалар, шундый ук юлга баскан булырлар идеме икән, дигән сорау куям. Һәм аңа каршы үземнең «юк» дигән җавабымны ишеткән сыман булам. Дөрес җаваптыр дип уйлыйм, чөнки бу татар холкына туры килми. Анда бүгенгәчә көчле рухлыларга гына хас булган башкаларга ышану, аларга юл ачу сыйфаты өстенлек итә. Шулай булмаса, татар башкаларга, хәтта дин кардәшләре булмаганнарга да бетмәс-төкәнмәс игелек кылып яшәгән булыр идеме икән?! Урта Азия халыкларына гасырлар буе мәгърифәт өләшеп, күрше чуаш, мукшы, мари һәм удмуртларны үз канаты астына алган булыр идеме? Гасырлар дәвамында аларның Польша җирлегендә яшәгән төркемнәре шушы илнең бәйсезлеген яклау өчен батырларча сугышырлар идеме? Польшаның Гданьск шәһәрендә батыр татар

сугышчысына һәйкәл ачылыр һәм шушы ил Президенты Бронислав Коморовский моңа багышланган чыгышында татар сугышчысына дан җырлаган булыр идеме?!.

Әлбәттә, ул уйланырга мәҗбүр итә торган махсус тема. Бу очракта татарларның шушы сыйфатына рус илендә беркайчан да мактау сүзе әйтелмәгәнлеген ассызыклау да җитәдер.

Кыл игелек, көт яманлык, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Ләкин ни кылмак кирәк, Аллаһы Тәгалә берәүләргә бер төрле, икенчеләренә исә икенче төрле сыйфатлар иңдергән.

Шулай да татарның кайбер тискәре сыйфатларына да тукталмый булдыра алмыйм. Аларның беренчесе – бердәм булмау. Бердәмлек аны бөеклеккә китергән булса, аның юкка чыгуы татарны коллык упкынына ташлаган.

Башкалар татарның шушы кимчелегеннән бик оста файдаланганнар, аны бер-берсенә каршы куярга өйрәнгәннәр. Мәсәлән, Казан ханнарын кырымныкыларга каршы куялар, Нугай Урдасын исә аларның икесенә дә каршы юнәлтәләр. Һәм ахыр чиктә барысын да үз кулларына төшерәләр.

Байлык бәрабәренә башкаларга сатылу өске катламга – тәхет тирәсендәге түрәләргә хас сыйфат. Башкалар исә, шуннан файдаланып, аларны, төрле рәвештәге бүләкләр, өстенлекләр биреп, үз якларына күчерә килгәннәр. Нәтиҗәдә, йөзләгән морза, урынлашып, сеңә, югала. Алай гына да түгел, шактыйлары үзләрен барлыкка китергән милләтнең кан дошманына әверелә. Шаһгали, Камай морза кебекләр, Казанны яулауга да өлешләрен кертеп, милләт тарихында кара эз калдырдылар.

Татарның янә бер тискәре сыйфатын әйтеп үтми мөмкин түгел. Ул да булса – бер-берсеннән көнләшү. Бу көнчелек күпләрне хәтта дошманга сатылуга, үз туганнарын кан дошманына әвереләдерүгә кадәр китереп җиткерде.

Дөресе, моннан башка да җитешсезлекләре шактый татарның. Ләкин, ни кызганыч, аның әле дә булса шушы тискәре сыйфатларыннан арына алганы юк. Ул, элеккегечә, башкаларга кирәгеннән артык ышана, аларга юл бирә, ә үз милләттәшеннән көнләшеп, аның юлын кисә. Татар һаман, Тукай сүзләре белән әйткәндә, бер-беренә ук ата.

Шушы уйлар тискәре сыйфатларыбыздан арынып, милләтебезнең бөтенлеген беренче урынга чыгару иң зур бурычыбыз икәнлеге турындагы фикергә китерә.

Егылдык, инде биш гасырга якын коллык базында яшибез. Ләкин моңа без үзебез генә сәбәпче. Ә үзе егылган еламас, ди халкыбыз. Елап, уфтанып, мескенләнеп утыру беркемне дә бизәми. Мескенне кызганмыйлар, аны үтергәнче кыйныйлар гына. Кыйнадылар-тукмадылар, әле һаман да кыйныйлар-тукмыйлар.

Шуңа күрә без бүген үткән тарихыбызга мактану яки уфтану рәвешендә түгел, ә объектив бәя бирергә өйрәнергә тиешбез. Шул исәптән, һичшиксез, коллык чорыбызга да. Чөнки анысы да безгә зур сабак укытты, кем дошман, кем дус икәнлеген ныклап аңлатты. Бөек чорларыбызда дуслар күп булган булса, коллыкка күчкәч, милләт берүзе – япа-ялгыз калды. Бердәнбер таянычы, аңа яшәү көче биреп торучы зат Аллаһы Тәгалә генә икәнлеге ачыкланды.

Тарих гыйбрәт-сабак алып, үзеннән өйрәнүчеләрне зурлый, ә өйрәнергә теләмәгәннәрен хурлый. Моны һич кенә дә онытырга ярамый.

Уйланулар мине, сизмәстән, үзебезгә билгеле заманнарга кайтара. Тарих куяшының безгә мәрхәмәтле йөзен күрсәтеп, дәүләтчелегебезне кайтаруга юл ачкан XX гасырның 90 нчы елларына махсус һәм озак тукталырга мәҗбүр итә.

1990 елда республикабызның суверенлык декларациясен кабул иттек. 1992 елның 21 мартында аны халык фикере белән ныгыттык. Ул көннәрдә Татарстанга

Референдум. 21 март, 1992 ел

ясалган янаулар, телевидение, радио, газеталар аша таратылган коткылар – барысы да бүгенгедәй күз алдында. Россия Югары Советының махсус машиналары Татарстан шәһәрләренә төрле рәвештәге куркыту, янау белән сугарылган листовка һәм прокламацияләр таратып йөрделәр. Кешеләрнең почта әрҗәләре шундый чүп-чар кәгазьләр белән шыгрым тула торган иде. Ләкин халкыбыз курыкмады, артка чигенмәде. Республикабызда яшәүчеләрнең 61,4 проценты бәйсезлегебезне яклап тавыш бирде.

Күз алдымда шушы онытылмас елларның иң җаваплы мизгелләре: Мәскәүнең Ак йортында, Кремлендә үзебез өчен үтә файдалы сөйләшүләр, Россиянең иң җаваплы кешеләре белән бәхәсләр. Аларга максатыбызның гадел һәм хаклы икәнлекләрен исбат итә алуыбыз. Нәтиҗәдә, аларның шуны танырга мәҗбүр булулары. Болар барысы да, әле кичә генә булган кебек, янә хәтердә яңара.

Без ул вакытта чын бәйсезлек янәшәсендә, аны бөтен тулылыгы белән күзаллау дәрәҗәсендә идек. Аһ, әнә шул ГКЧП фетнәсе чыгып, СССР таркалмаган булса, без дә, башка союздаш республикалар кебек, бәйсез дәүләткә әверелгән булыр идек. Безгә моның өчен нибары өч көн җитмәде.

Ләкин ничек кенә булмасын, бу еллар татарны уятты, аның, сибелеп яшәвенә дә карамастан, үзен бербөтен милләт итеп тоеп яшәвенә юл ачты.

Әйе, кыска гына вакыт эчендә искиткеч үзгәрешләр булып үтте. Әле кайчан гына бер-беребезне бер күрергә тилмереп, Сак белән Сок сыман сагынып яши торган заманнар иде. Ә хәзер дөньяның теләсә кайсы почмагына барып, милләттәшләребез белән аралашу мөмкинлекләре барлыкка килде. Совет чорында безне аерып торган тимер пәрдә юкка чыкты.

Шул чорда татар мәктәпләре аякка баса башлады. Казанда гына түгел, Оренбургта, Самарада, Саратовта, Ижауда, Уфада, хәтта Мәскәүдә дә татар мәктәпләре ачылды. Өр-яңадан татар теле гамәлгә керә башлады. Дистәләгән, йөзләгән милли оешмалар үсеп чыкты. Алар милли агарту эшен ныклап башлап җибәрделәр һәм бүген дә аны уңышлы дәвам итәләр. Ләкин тынычланырга ярамый.

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Ислам хакында хакыйкать

Азиз Али

Азиз Али. Кобе, Япония. 1957 ел



FACTS ABOUT ISLAM.

By AZIZ ALI,
Hon. Secretary of the Idel-Oural Turko-Tatar Muslim Cultural Society of Kobe, Nippon.

THE knowledge and enlightenment which was born together with Islam, in a very short time have given to its surroundings new spirit and new life. The backward Arab people after embracing Islam became ready in every requirement for new life and advancement and compelled all Arabia to look upon them with respect. The very truth of this reality of Islam became known to the outside world. At that time the Romans and Persians being the most powerful nations of the world were alarmed by the rapid spread of Islam, which they at first challenged, but to the light of which they were subsequently compelled to bow their heads. This new nation was so united, ambitious and truthful, that these qualities have compelled the big powers to respect them and they have been living as if they were ruling all over the rest. What was it that brought this new nation (Arabia) to this outstanding position in the world? Doubtless it was the Holy Quran and the untiring efforts made by the Holy Prophet and the spiri the has given to the people of Arabia. It was these qualities of Islam which made it possible to spread it in such a short time, possessing as it does, all the requirements such as civilization, common sense, outlook on life, reasoning etc.

The enlightenment, knowledge and other outstanding factors in the Holy Quran which was delivered to the Holy Prophet, astonished the learned of that time and these factors have compelled others to recognize and respect Islam. The coaching, Islamic training and the lectures given to the Arabs by the Holy Prophet compelled the Sahabas to be ready to sacrifice all and everything for Islam. Although it is over 1300 years since the death of the Holy Prophet, his teachings and examples have been faithfully followed and his creed *La ilaha il-Allah Muhammad ur Rasul-Allah*—(There is no object worthy of worship but God, and Muhammad is His Apostle)—has been in every Muslim's heart all over the world. This very creed *La ilaha il-Allah Muhammad ur Rasul-Allah* being the very foundation of Islam all the world over irrespective of nationalties, colour and race, has been the perfect guide that has gathered everybody within its fold.

In conclusion, I should like to say that this first Muslim Mosque in this great Empire Nippon is the result of the Holy Prophet's teaching of Holy Quran and the real Islamic spirit which he has injected in our blood and very soul, and is the result of teaching of unity.

La ilaha il-Allah Muhammad ur Rasul-Allah.

«Ислам хакында хакыйкать» мәкаләсенең инглизчәсе

Дин ислам белән туган гыйлем вә мәгърифәт кояшы бик тиз бер заман эчендә бөтен әтрафка яңа рух, яңа хәят бирде. Һәрнәрсәдән гафил, эшлексез, гыйлем вә мәгърифәтсез яткан гарәпләр, ислам динен кабул итү белән, эшлекле, җанлы, дин вә хәят өчен иҗтиһадлы булып, бөтен Гарәбстанны үзләренә караттылар.

Гаять саф булган ошбу хакыйкать кояшының нуры бик тиз заманда Гарәбстаннан чит җирләргә дә заһир булды. Ул вакытта дөньяның ике олуг дәүләтләреннән булган фарсы, рум хөкүмәтләре анарга каршы килмәктән гаҗиз булып, фәукаль-гадә дәһшәтле, шәүкәтле сурәттә заһир булган ислам нурына күзләре чагылып, анларга итагать итәргә мәҗбүр булдылар.

Яңа заһир булган ошбу милләт шулкадәр иттифаклы, шулкадәр эшлекле, интизамлы иде ки, әтрафларында булган барча олуг дәүләтләр аны ихтирам итәләр, анлардан һәммәсеннән өстен, һәммәсенә хаким рәвешендә яши иде. Гарәп милләтен бөтен дөньяны яңгыратырлык ошбу хәлгә китергән нәрсә – шөбһәсез, фәкать Коръән һәм дә рәсүлуллаһ тарафыннан бирелгән ислам рухы иде.

Ислам диненең рухны тәрбияләү өчен лязем булган нәрсәләрне бергә җыюы, чын тәрәккый вә хәят рухы бирүе, дин вә дөньяга икесенә дә тигез гаять мөгтәдил

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021



اسلام حقنده حقیقت.

دینی اسلام بلهن توغان علم و معرفت قویاشی، بیك تیز بر زمان اچنده
بتون اطرافغه یاکتوروح ، یاکتا حیات بیردی . هر نرسه‌ده‌ن غافل، اشلکسز،
علم و معرفتسز یاتقان عربلر اسلام دینی قبول ایتکه‌ن‌ده‌ن اشلکلی، جانلی، دین
وحیات اوچون اجتهادلی بولوب بتون عربستاننی اوزلرینه قاراتدیلار
غایت صاف بولغان او شبو حقیقت قویاشینڭ نوری، بیك تیز
زمانده عربستاندن چیت بیرلرگه‌ده ظاهر بولدی . اول وقتده دنیانڭ
ایڭ الوغ دولتلرنده‌ن بولغان فارسی، روم حکومتلری آنارغه قارشی
کیلگه‌ن‌ده‌ن عاجز بولوب فوق العاده دهشتلی، شوکتلی صورتده ظاهر بولغان
اسلام نورینا کوزلری چاغلوب آنلارغه اطاعت ایتارگه مجبور بولدیلار.
یاکتا ظاهر بولغان او شبو ملت، شول قدر اتفاقلی، شول قدر
اشلکلی، انتظاملی ایدی که اطرافلارنده بولغان بارچه الوغ دولتلر
آنگه احترام ایتالر، آنلاردان همه سنده‌ن اوستون، همه سینه
حاکم روشنده یاشی ایدی . عرب ملتی بتون دنیانی یاکتوروتولق
او شبو حالگه کیترگان نرسه . شبهه سز . فقط قرآن همده رسول الله
طرافندان بیرلگه‌ن اسلام روحی ایدی .
اسلام دینینڭ، روحی تربیه‌لری و اوچون لازم بولغان نه‌رسه‌لری

برگه جیبوی چن ترقی وحیات روحی بیردی . دین و...
تیگز غایت معتدل روشده قاراب دینلر آراسنده عقل...
حکمتکه ایڭ موافق دین بولوی بو دیننڭ بیك تیز وقتده...
تارالووینه سبب بولدی .
رسول اکرم حضرتلرینه ایندرلگه‌ن قرآننڭ فص...
عربلرنڭ ایڭ زور عالملری آنڭ قارشنده عاجز...
اینه رگه مجبور ایتدی . حضرت رسول طرافندان عربلر...
اسلام تربیه‌سی، آنڭ سویله‌گان خطبه‌لری، وعظ...
لرنڭ مال‌لارینی، جانلارینی قربان ایدرگه حاضر...
رسول الله صلی الله علیه و سلم نڭ وفاتینه...
آرتق اوتسه‌ده، آنڭ بتون سوزلری عبار...
صاقلاندی و بتون یر یوزینه تارالغان هر مسلمان ر...
اوگروتوب قالدرلغان «لا اله الا الله محمد رسول الله...
ایڭ اورتاسنده صاقلاب کیلدیلر . دینی اسلامنڭ نیگزی بو...
بتون یر یوزنده بولغان اهل اسلامنی اورن، تل، ملت باش...
عصرلر بوییه اوز تیره‌سینه توپلاب کیلدی . اتفاق اسلام...
اهل اسلام نی حبل الله غه تزوب کیلدی . یاپون مملکتنده برنچی...
بو مقدس مسجد بزده قرآن کریم ایله بیورلغان و رسول اکرم...
وتنه نیزگه سکدرلگه‌ن اتفاق اسلام تربیه‌سینڭ نتیجه‌سیدر...
لا اله الا الله محمد رسول الله

Азиз Алиның Кобе мәчетенең ачылу хөрмәтенә чыгарылган китапта басылган «Ислам хакында хакыйкать» мәкаләсенең татарчасы

рәвештә карап, диннәр арасында гакылга иң якын, хикмәткә иң муафыйк дин булуы бу диннең бик тиз вакытта бөтен дөньяга таралуына сәбәп булды.

Рәсүл әкрам хәзрәтләренә иңдерелгән Коръәннең фәсахәт вә бәләгате гарәпләрнең иң зур галимнәрен аның каршында гаҗизлекләрен икърар итәргә мәҗбүр итте. Хәзрәте рәсүл тарафыннан гарәпләргә бирелгән ислам тәрбиясе, аның сөйләгән хөтбәләре, вәгазьләре сәхабәләрнең малларын, җаннарын корбан итәргә хәзерлеккә тотты.

Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вәсәлламнең вафатына 1300 еллар артык үтсә дә, аның бөтен сүзләре гыйбарәләре белән сакланды вә бөтен җир йөзенә таралган һәрбер мөселман рәсүл әкрам тарафыннан өйрәтеп калдырган «Лә иләһә илләАллаһ Мухәммәдүр рәсүлуллаһ» кәлимәсен калебләренең иң уртасында саклап киләләр. Дин исламның нигезе булган әһле исламны, урын, тел, милләт башкалыгын оныттырып, гасырлар буенча үз тирәсенә туплап килде. Япон мәмләкәтендә беренче буларак бина кылынган бу мөкатдәс мәсҗидебез дә Коръән Кәрим белән боерылган вә рәсүл әкрам хәзрәтләре тарафыннан кан вә тәнебезгә сеңдерелгән иттифак ислам тәрбиясенең нәтиҗәседер.

Лә иләһә илләАллаһ Мухәммәдүр рәсүлуллаһ.

Кобе. Ниппун (Япония) ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Әтием Азиз Али турында

Җәүдәт Али

Азиз Али хатыны Сара һәм улы Җәүдәт белән. Кобе, Япония. 1957 ел

Әтием Азиз Али (Абдулгазиз Алеев) 1896 елның 14 маенда Рәсәйнең Сембер шәһәрендә Хәсән улы Гаязетдин белән Исхак кызы Фәхрибану гаиләсендә туган. Аның ике ир туганы (энеләре) – Абдул-Хәмит (1898), Әхмәт-Заһит (1904), бер кыз туганы Фатыйма-Зөһрә (1894) була.

Әтием 1920 елның сентябренә кадәр Сембердә яши. Гаилә хәлләре яхшы иде, дип сөйли иде. 4 ел татар мәктәбендә укый, аннары 7 ел урыс тиҗәрәт лицеенда, тагын 2 ел тиҗәрәт институтында белем ала. Шулай ук ул 8 ай субайлар (офицерлар) мәктәбендә укый.

1917 елда кабынып киткән революция һәм Гражданнар сугышы бик күп татар улларының чит җирләргә барып урнашуына сәбәп була. Шул татарлар арасына минем әтием дә эләгә. Әтием 1920 елның декабрендә Кытайның Харбин шәһәренә барып җитә. Анда ул 1923 елның августына кадәр яши. Большевиклардан курыккан әтием исемен Азиз Алига алыштыра. Харбинда яшәгәндә Казанга күченгән әтисеннән соңгы хат ала.

Хатта нәрсә язылганын ул безгә беркайчан да сөйләмәде. Конверты әлегә кадәр саклана. Әби-бабам, бөтен байлыкларын Сембердәге хезмәтче хатынга тапшырып, Казанга качалар. Алар, мул тормышлы булгач, большевиклардан куркалар. Күп тә үтми, бабам Хәсән улы Гаязетдин 1922 елда вафат була. Озак та үтми, әбием Исхак кызы Фәхрибану да дөньядан китә.

1923 елның августында әтием Япониянең Токио шәһәренә барып урнаша. 1934 елның октябрендә Япониянең Кобе шәһәренә күченә. Шунда гаилә кора. Әнием Садеттин кызы Сара Әхтәм – Рәсәйнең Николаевски шәһәреннән качып киткән татарлардан. Әниемнең гаиләсе дә бик мул тормышлы була. Әтисен Николаевскида большевиклар алып китәләр, әнисе, 7 баласын алып, Кытайга кача. Аннары Япониянең Кобе шәһәренә күченәләр. Әтием әниемне шунда очрата. Мин һәм апам Фавия Кобеда тудык. Әтием бик татар хисле кеше иде. Һәрвакыт әтиәнисен, туганнарын, туган җирен сагынып яшәде. Шигырьләре шуңа дәлилдер. Кобеда татарларның мәчете бар иде. Ул шунда мәчет идарәсендә бик актив катнашты. Үзенең «Ислам турында хакыйкать» дигән мәкаләсе мәчетнең ачылу хөрмәтенә чыгарылган истәлек китабында басылды. Шушы ук китапта атаклы татар язучысы Гаяз Исхакыйның «Ниппунда* беренче мәчет» дигән мәкаләсе дә басылган. Татарлар бер-берсе белән бик тату яшәделәр. Бөтен татар балалары өчен татар мәктәбе бар иде. Без татарча өйрәнеп үстек. Өйдә һәрвакыт татарча сөйләштек.

Азиз Алиның кызы Фавия һәм улы Җәүдәт. Кобе, Япония. 1957 ел

Гаяз Исхакый Кобега килә торган була. Ул, Алманиянең Берлин шәһәрендә яшәгәндә, «Яңа милли юл» дигән журнал бастыра. Бу журналның 1934 елда чыккан санында минем әтинең «Искә төшә...» дигән шигыре дә басылып чыккан иде. Әтинең йөрәге гомер буе «мин татармын» дип типте. Япониядә яшәгәндә татарларның япон ватандашлары юк иде. Төркия дәүләте 1953 елда Кобе татарларына төрек ватандашлыгы бирә. Туган җирен сагынып яшәгән әтием, кардәшләренә, туган җиренә якынрак булырмын дип, төрек ватандашлыгын һәм Төркиягә күченүне шатланып кабул итә. 1959 елның гыйнварында без гаиләбез белән Төркиянең Истанбул шәһәренә күчендек.

Апам Фавия 1966 елда Америка Кушма Штатларына китте. Мин анда 1971 елда барып кушылдым. 1974 елда әти белән әнием дә Америкага яшәргә килделәр. Әтием Нью-Мексико штатының Альбукерке шәһәрендә вафат булды һәм шунда күмелде. Кызганыч ки, ул туган җиренә, күпме якын булганда да, кире кайта алмады. Үзе кайта алмаса да, рухы булып шигырьләре кайтканына күңелем шатлана. Урыны җәннәттә булып, шигырьләре аркылы әйтәсе килгән сүзләре сезгә дә барып җитсен, кадерле укучы.

Язмалар һәм фотосурәтләр Җәлил хәзрәт Фазлыев архивыннан алынды. ■

* Ниппун – Япония.

Азиз Али шигырьләре

Азиз Али йортлары янындагы бакчада. 1957 ел

Милли тел

Бөтен телләрдән дә өстен мин күрәм сине, телем,
Сине өйрәндем анамнан, и минем милли телем.

Синдә ишеттем беренче дөньяга инсан телен,
Синдә өйрәндем беренче дөньяда милли телем.

Синдә ишеттем беренче дөньяда рәхмәт сүзен,
Синнән беренче чыланды яшь белән минем күзем.

Синдә әйттем мин беренче калтырап ачык сүзем,
Синдә ишеттем анардан чарасыз «сау бул» сүзен.

Синдә көйләп моңланамын чын күңелнең моңнарын,
Синдә генә сөйлимен мин саф калебнең уйларын.

Синдә сөйлим шатлыгым, хәсрәтем һәм серләрем,
Синдә генә мин юамын күңелемнең керләрен.

Син телемдә әйтсә идем соңгы сүзем Тәңремә,
Синдә язылса иде һәм бер кечек таш каберемә.



Кобе мәчетенең ачылу хөрмәтенә чыгарылган истәлек китабы

Искә төшә...

Язгы җилләр акрын – акрын искән чакта,
Язгы тамчы хәтфә җиргә төшкән чакта,
Бакчаларда чәчкә йөзен ачкан чакта,
Искә төшә минем ямьле туган илем.

Моңлы сандугач онытылып сайраганда,
Энҗе тешен өзелеп-өзелеп кайраганда,
Сүнгән йөрәктә хисләрем уянганда,
Искә төшә минем матур туган илем.

Арып, абынып, аксап адым атлаганда,
Башларымны кара уйлар каплаганда,
Көткән өмет чәчкәләрем атмаганда,
Искә төшә ерак калган туган илем.

Авыр тормыш дәрьясында буйлаганда,
Үткән рәхәт көннәремне уйлаганда,
Киләчәккә өметләрем югалганда,
Искә төшә минем сөйгән туган илем.

Сагынам синең карларыңны, суларыңны;
Сагынам синең шаулап торган урманыңны;
Чын күңелдән чыккан синең моңнарыңны;
Һич исемнән чыкмыйсың син, туган илем.

Көн сагынам, төн сагынам сине, илкәем!
Шулай ук соң, күрә алмаммы сине, илкәем?
Шатлансам да, кайгырсам да, син исемдә!
Нигә читкә кактың мине, сөйгән илем?!.

Киото, Япония

Башка төрле уйлар килә

Башка төрле уйлар килә –
Кара уйлар, авыр уйлар.
Языйм, дисәң, язып булмый,
Куркудан калтырый куллар.

Үткән гомер искә төшә –
Күбесе күңелсез үткән.
Өметләр тәмам изелеп,
Күңелләр күгәреп беткән.

«Нигә тордым, ни эшләдем»
Дигән уйлар башка килә.
Мәгънәсез үткән гомерем
Күз алдыма килә.

Үткән гомер кайтмас, дип,
Үземне юатып карыйм.
Күрсәтми кешегә яшемне
Эчемнән зарланып елыйм.

Киләчәкне уйлыйм, дисәм,
Башларым әйләнә минем.
Тәңремә ялварам, дисәм,
Телләрем бәйләнә минем.

Язам шуңа үз-үземә
Нигә кирәк бу тормыш, дип.
Үткәне кайтмас инде,
Киләчәге өметсез, дип.

Күп вакыт шул хыялларым
Көнне төнгә әйләндерә.
Тормышның мәгънәсен алып,
Кызыксызга әйләндерә.

Үз-үземә җавап бирәм,
Тәкъдире илаһи бу, дип,
Шулай ук һәр яратканга
Аның тәкъдиредер, дип.

Ни күрсәм дә, сабыр итәм –
Ходайның язмышы шул, дип.
Көтәм шатлык көннәремне,
Анда һәм кодрәте зур, дип. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Башкортстан татарлары

Нарыш аксакалы

Сиринә Сәлимшина-Шаһимәрданова

Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин хуҗалык эшләре белән мәшгуль



Исмәгыйль Сәлимшин совет чорында авыл халкын ислам рухында тәрбияли

Гыйлем тарату, халыкка ярдәм итү өчен тырышу – иң гүзәл гайрәттер.
Ризаэддин Фәхреддин

*Сүзем авылдашларының һәм безнең күңелләргә бик мөлаем, юмарт, «ак бабай», «мулла бабай», «матур бабай», «балта остасы», «тегермәнче карт» булып кереп калган әтием **Исмәгыйль Сәлимшах улы Сәлимшин** (1893-1975) хакында. Ул, дин тыелган бик авыр шартларда да шәригатьне бозмыйча, исламга тугры калган, ахирәт белән дөньялык гамәлләрен тигез алып барган мөхтәрәм шәхес иде. Бөтен күңелен, белемен, сәләтен, вакытын дин гыйлемен өйрәтүгә салган, шәригать буенча китаплар, дини-әхлакый шигырьләр язган, ислам динен өйрәнергә килүчеләргә ярдәм иткән, күпләрне намазга бастырган игелекле, зыялы кеше булды әтиебез. Әлеге язмам тулы булсын өчен, апам Фәния Сәлимшина-Мансурованың (1932-2005) истәлекләрен дә файдаланырга булдым.*

Бәхет эзләп чит җирләрдә

Исмәгыйль Сәлимшин 1893 елда хәзерге Башкортстанның Туймазы районындагы Нарыш авылында дөньяга килә. 1921 елгы ачлык вакытында Татарстанның Ютазы районындагы Кәрәкәшле авылына күченә. Шул елларда булачак әнием Гайнелҗинан белән гаилә корып җибәрә.

Мәкаләнең авторы **Сиринә Исмәгыйль кызы Сәлимшина-Шаһимәрданова** – РФ Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгының хезмәт күрсәтү отличнигы, Татарстанның атказанган көнкүреш хезмәте күрсәтү эшлеклесе, хезмәт ветераны.

Ул, әтисе Исмәгыйль Сәлимшинның тормыш юлын, нәсел-шәҗәрәсен, кульязмаларын өйрәнеп, 2017 елда **«Дөнья – ахирәтнең игене яки Нарыш җәүһәрләре»** исемле дини, әдәби, тарихи-документаль китап бастырып чыгарды.

Аларның кавышу тарихлары шактый кызыклы. Гайнелҗинан Сөләйман кызы Урыссу авылыннан. Исмәгыйльнең әти-әниләре, безнең булачак әбекәй белән бабакай, кызның әти-әнисенә килгәннәр. Ул чактагы гадәт буенча, кыз белән егетне очраштырып сөйләштерү түгел, кара-каршы бер күрештерү дә юк. Гайнелҗинанны чаршау артына яшергәннәр. «Булачак ирем сукыр, саңгырау, аксак йә бик ямьсез булмаса ярар иде», – дип бик тә хафаланып, чаршау эчендә утырган ул. Егеткә күз ташларга теләсә дә, йоланы бозып, ата-анага каршы килә алмаган. Шулай да, эзләнә торгач, чаршауның бер тишек җирен тапкан. Тишек аша карап, бүлмәдә утыручы әтине бик ачык күргән. Кара кашлы, кара мыеклы, кара чәчле, янып торган чибәр егет булган ул. Ул да борчылгандыр, кәләшен бик аз гына булса да күрергә теләгәндер. Өлкәннәргә сиздермәскә тырышып, як-ягына карангалап та ала икән. Гайнелҗинан, булачак хәләлен күреп, искиткеч шатланган. Шунысын да искәртик: әниебез гаиләсендә җиде бала була. 1921 елгы ачлыкта алты туганы үлеп, ул берүзе исән кала.

Яшь гаилә никахтан соң, бәхет эзләп, Казакъстанга чыгып китә – Чимкент шәһәренә урнаша. Берничә ел шунда яшәп, Исмәгыйль кургаш заводында эшли. Аннан соң Кыргызстанның Бишкәк шәһәренә күченә. Анда ул мич ягучы булып көн күрә. 1930 нчы елларда Сәлимшиннар гаиләсе яңадан Кәрәкәшле авылына әйләнеп кайта. Гаилә башлыгы тегермәнче булып эшли башлый.

Исмәгыйль Сәлимшин – фронтовик

Ютазы Хәрби комиссариаты 1941 елның 15 ноябрендә 48 яшьлек Исмәгыйльне сугышка озата. 1942 елның август аена кадәр ул сапер батальонында хезмәт итә. Аннары хәрби төзүче була, күперләр һәм һөҗүмнән саклану, ял итү өчен каралган блиндажлар төзүдә катнаша. Ул төзегән блиндажлар формасы белән җир астында корылган йортларны хәтерләтә. Сугыштан соңгы елларда Исмәгыйль Сәлимшин бу күперләрнең һәм блиндажларның маршал Родион Малиновский армиясе өчен салынуын сөйли иде. Аның архивында Малиновскийның Рәхмәт хаты да саклана.

Исмәгыйль Сәлимшин фронтта

Сугышның башыннан алып ахырына кадәр алгы сызыкта – ут эчендә була ул. Дошманның күз алдында күпер-басмалар сала. Күпернең бер ягында – без, икенче ягында фашистлар иде, дип искә ала иде әтиебез. Ике мәртәбә яралана, контузия ала. Бер мәртәбә, бомба шартлап, үзбәк егете белән җир астында кала.Аллаһының рәхмәте белән, аннан котылалар. Әтиебез Украина, Польша, Венгрия, Чехословакия, Австрия илләрен азат итүдә катнаша, Дунай елгасын кичеп чыга. И.В.Сталин Белгород шәһәрен фашистлардан азат итүдә күрсәткән батырлыклары өчен Исмәгыйль Сәлимшинга 1943 елның 15 августында Рәхмәт белдерә. 1944 елның 17 июлендә Ленинградка 63462 нче частьның 20 кешелек командасын озатып бара. Әтиебез 1945 елның 3 августында демобилизацияләнә. «Будапешт шәһәрен азат иткән өчен», «Германияне җиңгән өчен», «Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 20 ел» (1965 ел) медальләре белән бүләкләнә.

Исмәгыйль Сәлимшин 1941-1945 нче елларда фронт көндәлеге алып бара. Фронтовик шушы кесә дәфтәренә гарәби язу белән сугышта күргән шәһәр, авыл, станция исемнәрен, анда булган вакыйгаларны, кемнәр белән сугышта йөргүен, госпитальдә ятуларын – гомумән, фактлар тезмәсе рәвешендә һәрнәрсәне язып барган. Аның 1943 елның 16 июлендә сугыштан язган хатын да кадерләп саклыйбыз: *«Ходайдан киләчәктә дә сезгә көч-куәт, түземлек сорап, догалар кылам. Әлхәмдүлилләһ, мин дә якты дөньяда йөрүемне дәвам итәм. Аллаһының шушы бәхетләрдән аермавына мин бик ризамын. Алдагы өметләрдә дә шулай ук аякларымда үзем йөреп торсам иде, дип ялынып-ялварып сорыйм. Күрәсез, мин бикябык, тәндә ит әсәре юк. Аптырагансыздыр, бу ни хәлгә төшкән дип. Төшәрсең, ашарыңа бер телем икмәк, эчәреңә бер чеметем чәй булмаса. Ифрат кыен хәлләргә юлыктык бит без. Бөлгенлекнең соңгы чигенә җиттек. Атарга патроннарыбыз бетте. Ничек котыла алуыбызга әле дә булса ышанып җитмибез. Аллага көн дә дога кылам. Якты дөньяда яшәүләр бетмәгән әле»*, – дип яза ул анда.

Тегермәнче һәм балта остасы

Сагышлы-хәсрәтле, авыр, зар тулы сугыш елларыннан соң бәхетле, тыныч көннәр башланды. Гаиләбез тулы, шатлыгыбыз бихисап – бәхетле булу өчен тагын ни кирәк?! 1946-1950 нче елларда Исмәгыйль Сәлимшин, Кәрәкәшле авылында яшәп, тегермәнче булып эшли.

«Аның тегермәндә ничек эшләве бүгенгедәй күз алдымда тора минем. Колхоздан йөге-йөге белән икмәк китерәләр. Әти аларны башта лапаска ташый.

Балта остасы Исмәгыйль хәзрәт фабрика эшчеләре белән

Зур иләкләр белән иләп, чүп-чарыннан чистартканнан соң, тегермәнгә кертә. Биек баскычтан авыр капчыклар күтәреп, көненә ничә мәртәбәләр урый иде икән ул?! Тарттырылган онны капчыкларга тутыра, аларны лапаска ташып, әйбәтләп өеп куя. Бу көн саен шулай кабатлана. Тегермән ялсыз-нисез эшли. Саруы кайнап, төннәр буе газапланганы да исемдә. Хәлен җиңеләйтү өчен, чәй содасы эчә, көнбагыш ашый иде. Җәй көне җиңелрәк әле. Ә менә кышкы салкыннарда зур куласа еш кына бозга ката. Әти, шул куласа астына кереп, балта белән ул бозларны вата, кисәкләрне читкә чыгара. Ә без котларыбыз очып күзәтәбез: әти куласа астында кала күрмәсен дип куркабыз. Тик ул үзе өчен түгел, безнең өчен борчыла: «Балалар, өйгә керегез, суык тия күрмәсен», – дип, безне өйгә куа. Үзе манма су булып бетә. Әни тиз генә киемнәрен алыштыра, кайнар чәй ясап бирә».

Фәния Сәлимшина-Мансурова истәлекләреннән

1950 елда Исмәгыйль Сәлимшин туган авылы Нарышка әйләнеп кайта һәм, лаеклы ялга чыкканчы, йорт җиһазлары фабрикасында балта остасы булып эшли. 1958 елда аны зурлап лаеклы ялга озаталар.

«Сугыштан соңгы авырлыкларны сөйләп бетерерлек түгел. Шул ачлык елларында Исмәгыйль абзый миңа бик ярдәм итә иде. Тегермәнгә кергән саен, яхшылап ашата, юлда кайтканда ашарсың, дип, тагын ризык биреп җибәрә. Исмәгыйль абзыйның кешене якын итеп, игътибар белән тыңлап, яратып сөйләшүе истә калган. Ул бик гыйлемле, акыллы кеше иде. Мин тегермәнгә килгән саен: «Мирфатыйх, укуыңны ташлый күрмә, тырышып укы!» – дия иде. Аның киңәшен тоттым, укуны ташламадым».

Мирфатыйх Зәкиев, академик

Бәхетле гаилә

Күрешмичә өйләнешсәләр дә, Исмәгыйль һәм Гайнелҗинан бер-берсен бер күрүдә ошатышканнар, яратышып кавышканнар. Бик матур, тату яшәде алар. Мин аннан бер генә дә яман сүз ишетмәдем. Кемгәдер яки нәрсәгәдер ачуы килеп, юньсез сүз әйткәне булмагандыр аның. Бик матур, сөйкемле сөякле кеше иде. Хәтта олыгайгач та: «Матур бабай», – дип йөрттеләр үзен.

«Кечкенә чакта бик игътибар да ителеп бетмәгәндер, ә менә үзем гаилә коргач, балалар үстергәндә, әтиемнең искиткеч яхшы, сабыр холкына сокланып туя алмый идем. Аның балаларга тавыш күтәреп эндәшкәнен, караңгы чырай белән караганын хәтерләмим. Әниебезгә дә хөрмәте зур иде, гомер буе ярдәм итеп яшәде. Ирләр эше, хатыннар эше дигәнне белмәде. Кул кушырып тик утырган чагы булмады аның. Әти-әниебез бер-берсенә, «син», дип дәшә иде. Шушы кыска сүзгә аңлау да, олылау да, хөрмәт тә, ярату да сыя. Холыклары белән дә бер-берсенә бик тә охшаганнар иде алар. Әниебез дә искиткеч яхшы, бик тә оялчан, бик тә тыйнак, сабыр холыклы кеше иде. Әтиебез кебек ул да балаларына ялгышып та кырын карамады, ачуланып эндәшмәде. Әдәпле, инсафлы гомер кичерде. Җәй көннәрендә хатын-кыз, җыелышып, капка төбендә утыручан була бит. Әни бер дә кушылмый иде мондый әңгәмәләргә. «Нигә син дә чыкмыйсың?» – дип сораганым да булды. «Бер дә яхшы эш түгел озаклап болай утыру, – диде ул миңа. – Гайбәт тыңларга да, сөйләргә дә яратмыйм. Гөнаһ ул, Алла сакласын, ялгыш берәр сүз әйтеп куярмын. Сүз ишеткән кеше рәнҗер, мин гөнаһка батармын». Үзе дә илтифатлы гомер кичерде, безне дә шуңа өйрәтте. «Ачу килде дип, кешегә начарлык эшләмәгез, таш белән атканга да аш белән җавап бирегез. Гайбәт сөйләмәгез. Кулыгыздан килгән кадәр изгелек эшләргә тырышыгыз», – дип кат-кат кабатлый иде».

Фәния Сәлимшина-Мансурова истәлекләреннән

Исмәгыйль Сәлимшин хатыны Гайнелҗинан белән биш бала тәрбияләп үстерәләр. Наҗия (1926-1997), Фәния (1932-2005), Наил (1937-2013), Сиринә (1942) һәм Нәсим (1946-2015). Алар барысы да урта һәм югары белем алып, җаваплы урыннарда эшлиләр, халык арасында зур ихтирам казаналар. Исмәгыйль Сәлимшинның дүрт баласы – Закуан (1923), Наиб (1925), Хаҗия (1928), Фәвадис (1940) сабый вакытларында вафат була.

Әниебез Гайнелҗинан иртә вафат булганга, ул безгә әни дә, әти дә булды. Әле дә хәтеремдә: эссе җәй көнендә әти, бәләкәй арбасын өстерәп, урманнан печән алып кайтып килә. Өстендәге күлмәге юпь-юеш, башында кәләпүш, ә үзе мыек астыннан гына елмаеп тора. Әти менә шулай нурлы булып истә калган.

Мулла бабай мирасы

Исмәгыйль Сәлимшин 1950 елдан дини тормышта актив катнаша башлый. Нарышта мәчет булмаганга, күрше Төрекмән авылы мәчетенә йөри. Бу авылның хәзрәте аны Нарышка җаваплы имам итеп билгели. Шулай итеп, Исмәгыйль

хәзрәт Нарыш һәм күрше авыллар мәхәлләсендә яшәүчеләргә никах уку, исем кушу, Коръән мәҗлесләре үткәрү, мәрхүмнәрне соңгы юлга озату эшләрен алып бара. Нарыштан Төрекмән мәчетенә һәр атна авыл картларын җыеп җомга намазына бару җаен да табарга тырыша иде ул. Хәзерге кебек автобус-машиналар выжылдап йөреп торган чаклар булса икән! Арып-талып, ачыгып, кичкә таба көчкә кайтып керә иде өйгә.

Бик күп укый иде әтиебез. Дөньяви фәннәр һәм заман вакыйгалары белән һәрчак кызыксынып торды. Өстәлендә һәрвакыт китаплар, газета-журналлар, календарьлар иде. Аның архивында 1950-1975 нче елларда язган 160 кульязма китап саклана. Ул вәгазь, шәригать буенча китаплар гына түгел, дини, үгет-нәсыйхәт белән тулы шигырь һәм поэмалар да иҗат иткән. Гади халыкка дини-әхлакый мәсьәләләрне шигъри калыпка салып, үтемлерәк итеп җиткерергә тырышкан. Гомумән алганда, аның кульязмалары – совет чорындагы татар-мөселман дини мирасының бер үрнәге. Аларда язылган нәсыйхәт һәм вәгазьләрне хәзерге вакытта да бик теләп файдаланабыз.

Гомумән, шәригатькә нык ябышып, ислам динен гаять олуг күреп, туры-мөстәкыйм юлдан гына баруны үзенең төп максаты итеп куя Исмәгыйль хәзрәт. Әтиебез һичкайчан биш вакыт намазын калдырмады, гыйбадәтне бик моңлы итеп азан әйтеп башлый иде. Гасырлар буена җил-давылларга бирешмичә, бүгенге көнгә кадәр сакланып килгән динебездә әтием Исмәгыйль һәм әнием Гайнелҗинанның да зур өлеше бар. Качып-посып булса да, алар башка авылларга Коръән укырга йөргән, уразалар тоткан, авыр елларда да динебез исламга тугры калган, киләсе буыннарга яшәүгә өмет, көч-куәт биргәннәр.

«И балалар, и туганнар! Берегезнең дә исемен әйтмәем. Барчагызга шуны әйтәм: үзегездән кечеләрнең килешмәгән эшләренә нык күзәтчелек итегез. Шулай, балалар, Аллаһы риза булмаган эшләрдән бөтен көчегез белән сакланыгыз. Коръән кушканча яшәгез, чөнки безнең мәңгелек бәхетебез Коръән бит. Ягъни Коръән юлы гына – безнең тугры юлыбыз. Коръәнгә ышанмаучыларга бик нык куркыныч».

Исмәгыйль Сәлимшин васыятеннән

* * *

Исмәгыйль Сәлимшин 1975 елның 18 февралендә вафат булып, туган авылы Нарышта җирләнде. Әти дөньяда вакытта чәчкән иман орлыклары бик бәрәкәтле, мул җимешләр бирде. Без үсеп җиттек, гаилә кордык, балалар үстердек, инде хәзер онықларны ислам дине нигезендә тәрбиялибез. Боларның төп сәбәпчесе әтиебез булды, аның дога һәм нәсыйхәтләре безне гомер буе туры юлдан алып барды. Аңа ияреп без, аның балалары, оныклары да, намазга бастык, динебезне үстерүгә көчебездән килгән кадәр өлеш кертәбез, әлһәмдүлилләһ! ■

2021 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1442-1443 ҺИҖРИ ЕЛЛАР

13 февраль – мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим (г.с.) пәйгамбәрнең, Гайсә (г.с.) пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ – Гомрә хаҗы кылына.

18 февраль – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

10 март – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете (көрсие) янына кылган могҗизалы сәяхәте булган кичә. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

27 март – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган төн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышларын билгели.

13 апрель – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә – Кадер кичәсе.

13, 14, 15 май – Гайдел-фитыр, Ураза бәйрәме.

21 май – Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

18 июль – Гарәфә кичәсе.
Мөбарәк вә фазыйләтле 10 кичәнең ахыргы кичәсе.

19 июль – Гарәфә көне.

Гарәфә кыяме яки хаҗиларның Гарәфә тавы тирә-юнендә торып, гамәл-гыйбадәт башкару көне. Һәр фарыз намаздан соң Тәшрикъ тәкъбирләре әйтеләчәк, иншәАллаһ.

20 июль – Мөбарәк Гыйд әл-Әдъхә яки Корбан гаете. Мөселманнарның иң зур бәйрәмнәрнең берсе. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Республикасындагы барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

21, 22 июль – Тәшрикъ көннәре. Әлеге көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап, тәкъбир әйтәләр.

9 август – Һиҗри Яңа ел. 1443 һиҗри елның вә Мөхәррәм әл-Хәрам аеның беренче көне.

Яңа елыбызда дөнья вә ахыйрәт бәхет-сәгадәтенә алып бара, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кылырга насыйп булсын! Бу көнне Аллаһының ризалыгы өчен догалар, изге эш-гамәлләр кылып, хәер-сәдака биреп үткәрергә кирәк.

17 август – мөбарәк Гашура кичәсе.

18 август – мөбарәк Гашура көне. Мөхәррәм әл-Хәрам аеның 10 нчы көнендә Гашура бәйрәме билгеләп үтелә. Бу көннең фазыйләтләре һәм хикмәтләре бихисап. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) болай дигән: «Ибраһим галәйһиссәлам Гашура көнендә тугандыр. Аллаһы Тәгалә аны Нәмрудның утыннан Гашура көнне коткаргандыр, юлның тугрысын да Гашура көнендә күрсәткәндер».

17 октябрь – Мәүлед-шәриф кичәсе.

18 октябрь – Мәүлед бәйрәме – пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган көн. Ул мөселман дөньясында зурлап билгеләп үтелә.

Төзүче-мөхәррир – хаҗи ***Абдулла Дубин*** ■

Мөһаҗирлектәге татар китабы

Суомида татарлыкны дәвам иттерүче

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Садрый Хәмид Халидә һәм Гомәр Таһирлар туенда котлау шигыре укый. Хельсинки. 23 сентябрь, 1945 ел

Халкыбызның Финляндия (Суоми) белән яңа замандагы бәйләнешләр тарихы, нигездә, XIX гасыр урталарыннан гына башлана. Аның башында һәм үзәгендә, иң беренче чиратта, Нижгар төбәгендәге Яңапар (Актук) кешеләре тора. Хәзер дә бу мәмләкәттәге күпчелек татарлар үзләренең асыл, тарихи ватаннары итеп шушы авылны саный. Мәгълүм ки, Суомидагы милләттәшләребез сан ягыннан күп түгел – бер меңгә дә җитми. Әмма уңган-булганлык, һөнәр-укымышлылык белән, ягъни сыйфат ягыннан алар татар дөньясында мөһим урынны били. Төрле кыенлыкларга да карамастан, Актук кавеме чит-ят җирләрдә дә югалып калмый, тырыша-тырмаша үз тормышын корып җибәрә: бер-берсе белән ярыша-ярыша сәүдә итә, төрле кала-бистәләрдә кибетләрен булдыра, укый, телләрне өйрәнә, үзенең динен, миллилеген, телен-моңын, гореф-гадәтләрен саклый, мәктәпләр ача, гәҗит-журналлар чыгара, китаплар бастыра. Шунысы гаҗәп: биредәге «милләттәшләребез»нең шактые (мөгаен, уннан берeдер) төп эшләре (сатып алу) белән бергә, каләм дә тибрәтә. Болар арасында **Садрый Хәмид** (1905-1987) шактый мөһим урынны алып тора.

Энциклопедик эшчәнлеккә ия булган, Фин илендә татарча гәҗит-журналлар чыгарган, илледән артык китап бастырган **Хәсән Хәмидулла** (1900-1988) үзенең мәшһүр «Яңапар тарихы»ның (Хельсинки, 1954) [автор үзе дә шушы авыл кешесе] «Яңапардан чыккан каләм әһелләре» бүлегендә беренчеләрдән булып Бәдреддин углы Садреддинне (Садрый Хәмидне атый), аның рәсемен дә урнаштыра, матур шигырьләр язуын искәртә дә, алга таба мондый фикерләр әйтә: «Үз тормышын яхшы гына сәүдәгәрлегә аркасында алга алып барган бу Яңапар шагыйренең башка бөек тойгылары булган рәссамчылык, филадисчылык *(филателия белән шөгыльләнү. – **Х.М.**)* вә музачылык *(музыкачылык. – **Х.М.**)* дәрдләре дә бик көчле булганга, Яңапарның йөзенә бу мөхтәрәм зат аркылы кызыллык килмәве мөхәкъкак *(дөрес. – **Х.М.**)* вә шөбһәсездер».

Садрый Хәмид тә, Финляндиядәге Хәсән Хәмидулла, Хөсәен Садыйк, Зиннәтулла Әхсән Бүре һәм кайбер башка каләмдәшләре һәм якташлары кебек, әүвәл Яңапардагы атаклы мәдрәсәдә белем ала, аннан үсмер яшендә Суомига күчеп килә, бу илнең төрле шәһәр-авылларына йөреп сәүдә итә, бераздан үзенең кибетләрен дә ачып җибәрә. Озак еллар буе төп яшәү урыны – Финляндиянең төньягындарак урнашкан Оулу шәһәре. Ахырга таба ул Хельсинкига күчеп килә (шунда ук җирләнә дә), мәмләкәттәге милли-рухани тормышның үзәгендә кайный. «Төрекчелек» хәрәкәтендә татарчылыкка тугры кала. М.Рясянен, Гомәр Таһир белән берлектә, Тукай җәмгыятен нигезли, аның эшендә актив катнаша. Татарның бу ике заты гел аралашып, сөхбәтләшеп тора. Садрый Хәмиднең 1945 елның 23 сентябрендә Гомәр Таһир белән Халидә Гыймад кызының Хельсинкида узган туенда катнашуы, шигырь сөйләве дә билгеле[1]. Без фәкыйрегезгә һәрчак хәерхаһлы булган Окан әфәнде Таһирның әйтүенчә, Садрый Хәмид, Эстониядә яшәгән Хәят исемле татар кызына өйләнеп, матур гына гаилә тормышы кора, милли рухта ике угыл (Илхан, Балкыр) тәрбияләп үстерә. Оныклары да бар.

Бу зат язу-сызу, иҗади эш белән, мөгаен, яшьтән үк шөгыльләнә башлагандыр. Читят җирләрдә яшәү, туган ягын сагыну, җирсү хисләре аның күңелендәге уй-кичерешләрне тагын да көчәйткәндер. Якташы Хәсән Хәмидулла белән бер төбәктәрәк яшәү, аларның үзара аралашып торулары да яшь кешенең иҗади эшчәнлегенә сизелерлек йогынты ясый. Аның язмалары вакытлы матбугат битләрендә күренгәләп тора. Ә инде узган гасыр урталарында Садрый Хәмиднең аерым-аерым шигъри китаплары да дөнья күрә. Хәсән Хәмидулла үзенең югарыда телгә алынган, 1954 елда нәшер ителгән хезмәтендә якташының дистәдән артык «шигъри әсәре» басылып чыгуын искәртә, үрнәк итеп «Гөнаһлар күп...» парчасын да китерә. Ә бит әле Садрый Хәмид «Яңапар тарихы» дөнья күргәнннән соң да каләм тибрәтүен, иҗади эшчәнлеген дәвам итә.

Шунысы да гыйбрәтле: бу мөхтәрәм зат дистә елдан артык вакыт аралыгында башта Оулуда (1967-1974), Хельсинкида (1974-1977) гарәп хәрефләре белән «Ак юл» исемле мәгърифәти-әдәби эчтәлектәге журнал да чыгарып килә (барлыгы 64 сан). Материалларга шактый бай бу мәҗмугадагы язмаларның күпчелеге татар тематикасына багышланган.

Каләм әһелләре элек-электән әдәби иҗат, сүз сәнгатенең асылы турында уйланганнар. Садрый Хәмид әнә шул традицияне үзенең «Шигырьләр язу» парчасында билгеле бер дәрәҗәдә дәвам итә.

Инде укучылар Садрый Хәмид иҗатының шактый күләмле, бай булуын үзләре дә абайлагандыр. Әмма, ни кызганыч, безнең кулыбызда әдип язганнарның тик бер өлеше генә бар. Алар, нигездә, өч китаптан гыйбарәт. «Закир» (Оулу, 1946. –12 б.), «Хаким» (Оулу, 1947. – 124 б.), «Үткән елның хәбәрләре» (Оулу, 1950. – 32 б.). Боларның барысы да гарәп язуында, шигъри шәкелдә. Тәүге икесе – басма, соңгысы, кулдан язылып, күбәйтелгән. «Закир» һәм «Хаким» китапларында авторның үзе ясаган рәсем-иллюстрацияләре дә бар. Алар шактый күркәм, эчтәлеккә муафикъ чыккан.

Инде хәзер, теләсәк тә-теләмәсәк тә, Садрый Хәмиднең гомуми иҗаты турында түгел, ә шушы өч китабы хакында гына фикер йөртергә мәҗбүр булабыз. Шунысын да искәртик: гәрчә бу әсәрләр турында иркенәебрәк язарга кул кычытып торса да, мәкаләбезнең журнал кысалары белән шактый чикләнгән булуы кыска гына язуны таләп итә. Шуңа күрә биредә, мөгаен, аерым фикер-күзәтүләр белән генә чикләнербез.

[1] Үзенең котлау парчасында С.Хәмид туй мәҗлесенең күңелле, табыннарның муллыгы хакында да яза. Аерым катнашучыларны да телгә ала. Болар арасында Оулудан килгән Хисам бабай да, Кими шәһәрендә яшәүче «Хәсән Кулик» (Хәмидулла да) бар. Гарәп хәрефләре белән язылган бу шигырь мондый юллар белән тәгалләнә:

...Әй җәнабе Хак! Бир бәхетләр Халидә белән Гомәргә,
Әле күргән бу кызыклар калсын мәңге сөйләргә.

«Башлыйк әле сүзне Карәхмәт илә» дигән кебек, күзәтүебезне китапларның соңгысыннан башлыйк әле.

Үткән елга хисап ясау, аның вакыйга-хәлләре хакында фикер йөртү тормышта киң таралган. Әлеге рухта язылган аерым әсәрләр дә бар (шул исәптән Тукайда да). «Үткән елның хәбәрләре» китабында Садрый Хәмид тә шушы шәкел-ысулны куллана. Язмада сүз күбрәк 1949 ел турында бара. Әмма автор күрсәтелгән вакыт кысаларыннан чыгып та киткәли. Элегрәк үткәннәрне дә чит итми. Шигъри форма аңа, гомумән, вакыт агышы, яшәеш хакындагы уй-кичерешләрен бәян итәргә дә мөмкинлек бирә. Әсәр үзенең төзелеше белән Финляндия буйлап хыялый (заочно; читтән торып) сәяхәт кылуны хәтерләтә. Ул аны илнең төньягындагы Кәми, Оулу тирәләреннән башлый. Алга таба юл-сәфәр Тампере, Турку, Котка, Ярвинпә, Лахти һәм кайбер башка шәһәр-бистәләр аркылы үтеп, ил башкаласына – Хельсинкига килә. Автор бу төбәкләр, аларның табигате, тарихы хакында теге яки бу күләмдә күзәтүләр дә ясый. Әмма бу гадәти сәфәр түгел, ә татар йөрәге типкән иҗади затның газиз милләттәшләре янына сәяхәте. Ел ахырында, яңа ел башында үзеңә якын кешеләрнең хәлен белү киң таралган. Автор да үз кавемдәшләрен барлап чыга, аларның хәл-әхвәлләрен ачыклап, уңышларына куана, үлем-китемгә кайгыра, җитешсезлекләрне тәнкыйтьли, киңәш-теләкләрен дә җиткерә. Шунысы мөһим: әдип – Суоми иленең күпчелек авыл-калаларын (иң беренче чиратта, сәүдә эшләренә мөнәсәбәттә) иңләп-буйлап чыккан зат. Күпчелек милләттәшләрен (аларның шактые – аның якташлары) яхшы белә. Хәзерге «онлайн» рәвешендәге кебек, ул алар белән читтән торып сөхбәт тә кыла. Шуңа күрә авторның язганнары, фикер-күзәтүләре чынбарлык, реаль вазгыять белән тыгыз бәйләнешле.

Садрый Хәмид үз язмасында күп кенә танылган һәм бик билгеле булмаган затлар, шул исәптән каләм әһелләре хакында да фикер-күзәтүләрен бәян итә, аларга характеристика-тасвирламалар да бирә.

«Үткән елның хәбәрләре» китабы авторның язма мирасын өйрәнүдә генә түгел, ә гомумән, Финляндиядәге милләттәшләребезнең яшәешен, эш-гамәлләрен, рухи дөньяларын ачыклауда да мөһим бер чыганак булып тора. Ул үзенең стиль-корылышы, формасы белән дә игътибарга лаек. Андый әдәби ысулны куллануга хәзер дә ихтыяҗ зур. Тормышыбызга шигъри тел белән «хисап»ка кертерлек, бәя-мөнәсәбәтне белдерерлек вакыйга-хәлләр тулып ята.

Инде хәзер төп игътибарыбызны Садрый Хәмиднең «Хаким» дип исемләнгән икенче китабына юнәлтик. 1947 елда Оулу каласында дөнья күргән бу әсәр, нигездә, җидегә-җиде иҗекле ике юллык строфалар белән язылган. Шактый күләмле: 124 бит. Үзенең эчтәлеге, төзелеш хосусиятләре белән ул поэма кысаларыннан ары чыгып, шигъри роман жанрына якыная. Анда күптөрле вакыйга-хәлләр тасвирлана, берничә дистә образ-персонажлар катнаша. Вакыт-урын төшенчәләре дә шактый киң: төрле-төрле авыл-шәһәрләр, дистәдән артык еллар.

Әсәрнең кыскача эчтәлеге моннан гыйбарәт: табигатьнең шактый кырыс төбәгендәге «ерак кына авылда» ир белән хатын гомер кичерә. Тормышлары шактый авыр. Кызлары яшьли үлә барган. Җиткән дүрт уллары бар. Кечесе – Хаким. Ул «озын буйлы», «таза»... Аңа инде 18 яшь. Әмма бу егет «иренчәк», «эшен дә эшли», «уку-язуын да белми». Аннан «мәҗнүн, тиле, шашкан» дип көләләр, егетне төрлечә мыскыллыйлар. Көннәрнең берендә этисе, «файдаң тими беркемгә», «ашап кына ятасың», «үз көнеңне үзең күр», дип, аңа өйдән чыгып китәргә куша. Нишләсен? Гәрчә әнисе яклаca да, ата сүзенә каршы килә алмый, аз-маз ризык, кием алып, елый-елый туган йортыннан китеп бара. Алга таба егетнең катлаулы тормышы, сәфәрләре тасвирлана.

Хаким, әүвәл бик карышса да, бер каракның үгет-йогынтысы аркасында бурлыкка керешә, төрле ситуацияләргә эләгә, кыйнала да. Әйбер урлауның азартына тәмам бирелеп китә. Йөри торгач, ул үзенең «карак» дусты белән ил башкаласына килә. Шәһәрне тамаша кылалар. Автор биредәге йорт-корылмаларны, урамнарны шактый оста, җентекле тасвирлый. Менә алар Галишаһ («бөек хөкемдар») сарае янында. Бераз хозурланып торгач, Хаким, тәвәккәлләп, бау белән шаһ сараеның югары катларының берсенә күтәрелә, бер тәрәзәне ачып бүлмәгә керә. Андагы зиннәт, байлык – һушыңны алырлык! Өстәвенә, урында «гүзәл, матур», «бөтен өйне нурлатып» бер кыз йоклап ята. Хаким шыпырт кына капчыгына биредәге затлы әйберләрне тутыра башлый. Чыгып китәргә җыенганда ул, нәрсәгәдер ялгыш бәрелеп, тавыш чыгара. Кыз уяна, сикереп тора. Ике арада каты гына сөйләшү. Эш ахыр чиктә кылычларга барып җитә. Шау-шуга сакчылар, хезмәтчеләр җыела. Хакимне кулга алалар. Галишаһ аны җиде елга хибескә утыртырга әмер бирә. Шактый озакка сузылган төрмә тормышы, аның «рәхәтләззәтләре» Хакимне, әйтерсең, кабат тудыра. Мөддәтен тутырып иреккә чыккач, ул төрле кешеләр белән очраша, белем-һөнәр туплый, игелекле юлга баса, дини йолаларны үти башлый. Шәриф исемле бер карт гыйлем иясе аны «доктор»лыкка, дарулар ясарга өйрәтә. Хаким тиз арада бу һөнәрне ныклап үзләштерә. Сырхауларга, авыр хәлдә калучыларга ярдәм итеп йөри. Аның даны еракларга тарала.

> «
> **Табигатьнең шактый кырыс төбәгендәге «ерак кына авылда» ир белән хатын гомер кичерә. Тормышлары шактый авыр. Кызлары яшьли үлә барган. Җиткән дүрт уллары бар.**

Мәгълүм ки, чир-авыру бөек хөкемдарларны, патшаларны да урап үтми. Галишаһ та каты авырып китә. Кызы бик борчыла. Әтисен терелткән кешегә кияүгә чыгачагын да хәбәр итә. Патша сараена бер-бер артлы шаһ кияве булырга теләгән «доктор»лар агыла башлый. Әмма файдасыз. Хаким дә сарайга килә. Дәвалый. Галишаһ элеккечә сау-сәламәт. Әмма булачак киявенең элеккеге карак икәнен белеп ала. Әрләү, куркыту, үлем белән янау. Ахыр чиктә Хаким патша сараеннан көчкә чыгып котыла. Алга таба аның сырхауларны дәвалавы, кешеләргә ярдәм итүе күп кенә конкрет мисал-сюжетлар аркылы шактый тулы сурәтләнә.

Күпмедер вакыттан соң, Галишаһ янә авырый башлый. Хәле өметсез. Килгән «доктор»ларның дәвасыннан да файда юк. Әтисе белән кызы Хакимне эзләтә башлыйлар. Доктор сарайга килә. Галишаһ үкенә, кичерү сорый. Хаким хөкемдарны дәвалый. Галишаһ терелә. Шатлык-куаныч. Тиңе булмаган туй. Күпмедер вакыттан соң, патша бакыйлыкка күчә. Халык аның урынына Хакимне шаһ итеп сайлый. Тәхеткә утырту искитәрлек тантаналы шартларда башкарыла. Кунакларның исәбе-хисабы юк, сый-хөрмәтнең муллыгын сөйләп тә бетерерлек түгел. Хакимнең бер абыйсы да бу чараларда катнаша. Ахырда Хаким әти-әнисен, туганнарын үз сараена китертә. Очрашу-куанычлар тасвирлана.

Күрәсез: «Хаким» китабы үзенең эчтәлеге, рухы белән әкиятләргә, маҗаралы-детектив әсәрләргә шактый тартым. Анда маҗаралык та, вакыйга-хәлләрнең киеренкелеге, сюжет борылышларының кискенлеге дә бар. Иң мөһиме – әсәр укыла, укучының күңелен җәлеп итә. Ул гасырлар буе тупланган инсанлылык, әхлаклылык рухы белән сугарылган. Адәм баласы игелекле эш-гамәлләр генә кылырга бурычлы. Үзгәләргә кылган зыяның, начарлыгың ахыр чиктә барыбер үзеңә кайта. Һәр кеше теләгән вакытта тәүбә кылып, үз хата-кимчелекләреннән котылып, үзен камилләштерә

ала. Әсәрнең төп каһарманы да әнә шундый юлны үтә, шундый эволюция кичерә. Аның исеме дә билгеле бер символик мәгънәгә ия. «Хаким» дип патша-түрәләрне генә түгел, гыйлем-һөнәр ияләрен дә атыйлар. Күренекле табибларны да бу исем белән атау тарихтан билгеле. Әсәр герое еш кына кыен хәлдә калган адәм балаларының тәннәрен генә түгел, рух-җаннарын да дәвалый, аларга киңәш-теләкләрен дә җиткерә, саранлык, эчкечелек, алдауның начарлыгын күрсәтә. Автор геройның мөселманлыгына да даими басым ясый. Ул, хибестән котылгач, ислам динен үзенең күңел юлдашы итә, андагы рухи кыйммәтләргә даими таяна, аларны үзгәләргә дә җиткерә. Шунысы үзенчәлекле: автор инде шактый гомерен читтә, башка дин вә кавем даирәсендә үткәрә. Әмма аның әсәре тулысы белән төрки мөселман дине рухында, образ-персонажлары да, вакыйга-хәлләр барган урыннар да – бар да үзебезчә, мөселманча. Аеруча мөһиме шул: бу шигъри роман да, авторның башка әсәрләре кебек, чын үзебезнең телдә – татарча язылган. Алынма сүзләр белән мавыгу юк. Садрый Хәмид «мишәр» шивәсенә (диалектына) хас булган аерым сүз-элементларны да әсәр тукымасына уңышлы гына кертеп җибәрә: кабак – капка, түндәк – бүкән (утыргыч), тирес – киресе, азбар – абзар, пает – ихата. Андый сүзләр хәтта рифмалар рәвешендә дә кулланыла.

Садрый Хәмиднең «Хаким» белән бервакытта 1946 елда дөнья күргән «Закир» исемле басмасы да укучыларның игътибарын җәлеп итәрлек. Аның кыскача эчтәлеге моннан гыйбарәт:

Караңгы гына, фәкыйрь тормышлы бер авылда аның үзе кебек үк фәкыйрьлеккә чумган 40 яшьләрендәге Закир исемле кеше яши.

Кием ертык, ыштан ямау, тузып беткән чабата,
Булсын яңгыр яки пычрак, йөрер шулай бата-бата.

Ул үксез үскән, укый-яза да, эш рәтен дә белми. Теләнчелек белән көн күрә. Хәер сорашып төрле төбәкләрдә йөри. Бервакыт юлда барганда йокларга ята. Озак йоклагач, башын, борынын нәрсәдер ялауга уянып китә. Караса: «зур аю»! Куркудан Закирның коты чыга яза. Аю аны мәҗбүриләп, «сөрәп» алып китә. «Көне буе» барып, арган хәлдә бер урман кырына җитәләр. Анда «арт аягы» агачка кысылган аю баласы. Каны да аккан, җәрәхәтле. Шунда Закир, хәл-вазгыятьне аңлап, аю баласын коткара. Әнисе куанычшатлыктан сикерә, бии. Янә китәләр. Күрәләр: алтын-көмеш, кыйммәтле хәзинәләр тулы баз. Хайван-җәнлекләр дә рәхмәтле. Аю бу байлыкны, баласын коткарган өчен, Закирга бүләк рәвешендә бирә, үзләре ары китә. Әсәр герое «күзләр камашырлык» бу хәзинәдән «тәмам шашарлык» хәлгә килә. Ул, алтын-көмешнең шактыен капчыгына тутырып, базны ябып, билге өчен таяк кагып, авылына юнәлә. Тиз арада искитәрлек йорт-куралар төзетә, бакчалар булдыра. Күпләгән «куйлар», сыер-атлар асрый башлый. Халык боларны күреп шакката. Бераздан Закир өйләнеп җибәрә. Күрелмәгән, исең китәрлек туй! Төрледәнтөрле ризык белән тулган табыннар, җыр, музыка, биюләр [«Чакыра һәр авыл халкын», «Дөньяда юк ашлар бар», «Җырлар, биюләр, уен»…]. Мәҗлеснең ахырына таба Закир анда катнашкан «тугыз меңнәргә якын» кешегә алтын-көмеш өләшә. «Элек миннән көлсәгез, мине түбәнсетсәгез дә, – ди ул, – мин сезне гафу итәм. Моңа тикле фәкыйрьлектә, ачлытуклы яшәдегез. Хәзер исә «Салып өйләр корыгыз Рәхәт яшәп торыгыз». Тиз арада авыл халкы йортлар сала, муллыкта яши башлый, «мәктәп-мәдрәсәләр төзелә», кирәкми. Әсәр шушындый юллар белән төгәлләнә:

…Корылды шунда зур кала,
Күреп кешеләр хәйран кала *(игътибар итегез: омонимик рифма,ягъни тәҗнис: кала – кала. – **Х.М.**)*.
Шундый эш кылды Закир,
Булса да элек фәкыйрь.

«Закир» китабында, гәрчә романтик-әкияти башлангыч өстенлек итсә дә, реалистик күренешләр дә чагылыш тапкан. Бу аеруча әсәрнең тәүге өлешендә бик көчле. Мәгълүм ки, бәйсезлеген югалткан, колониаль изелүгә дучар ителгән күп кенә татарлар, элек яшәгән урыннарыннан күчеп, таулы-ташлы, уңдырышсыз, кыскасы, яшәү өчен кыен булган җирләрдә гомер кичерергә мәҗбүр ителәләр. Закир яшәгән авыл да, мөгаен, шундыйларның берседер. Аның «йирләре тар… кыска, ташлык»; Аларда «чәчеп» үсми ашлык та; шуңа күрә кешеләрнең кышка ашарларына да җитми. Мондый авыллар бит берәү генә түгел, меңләп. Тагын шунысын да хәтергә төшерик: Финляндиягә күчеп килгән милләттәшләребез дә туган җирләрен, нигездә, кысынкылык, фәкыйрьлек аркасында ташлап киткән кешеләр. Алар, үзләренең тырышлыклары аркасында, чит-ят җирләрдә дә югалып калмыйлар: хәрәкәт итәләр, эшлиләр, шактый гына мул тормышка да ирешәләр, байлыкларын милләт өчен дә кызганмыйлар. Садрый Хәмид тә байлык-мал туплауны үзмаксат итмичә, аны игелекле эшләргә, халык мәнфәгатьләренә тотуны чын күңелдән яклый.

«Закир» әсәрен эчтәлек-төзелеше ягыннан әкияти-романтик рухлы поэма дип атарга мөмкин. Ул да, «Хаким» китабы кебек, нигездә, татар шигъриятендә шактый киң таралган җидегә-җиде үлчәмле, ике юллык строфалар белән язылган. Вәзен-кафия, ритмик яңгыраш, рифмалашу җәһәтеннән дә гомумән артык тел-теш тидерерлек түгел.

* * *

Әйткәнебезчә (ни үкенеч), безнең кулыбызда Садрый Хәмид әсәрләренең тик бер өлеше генә бар. Әмма бар булганы да бу каләм әһеленең шактый мул иҗат мирасы калдыруын, үзенчәлекле әдип булуын күзалларга ярдәм итә. Ул, элеккеге традицияләргә таянып, яңа заман, үзгә җир ихтыяҗларын күздә тотып, кызыклы гына әсәрләр тудыра. Алар төрле жанрда. Хәтта шигъри роман дип атарлыклары да бар. Садрый Хәмид иҗатында бүгенге укучыны кызыксындырган, борчыган аерым мәсьәләләргә дә җаваплар табарга була. Шуңа күрә бу авторның әсәрләрен хәзерге татар укучысына җиткерү, аларны рухи-гыйльми әйләнешкә кертү дә зарури.

Садрый Хәмид – мөһаҗирлектәге татар сүз сәнгатенең билгеле бер вәкиле. Бу уңай белән бер хакыйкатьне дә искә төшерү гөнаһ булмастыр. Чит-ят җирләргә күчеп киткән, тарихи ватаннарыннан еракта яшәгән милләттәшләребезнең шактые, үз туган телләреннән тыш, берничә чит телне дә белә. Бу аларга башка кавемнәрнең рухи кыйммәтләрен, әдәбиятларын үзләштерергә дә мөмкинлек бирә. Гаяз Исхакый, Хөсәен Габдүш, Сания Гыйффәт, Әхмәд Гәрәй, Хәсән Хәмидулла һәм кайбер башка каләм әһелләренең иҗатларында без моны теге яки бу дәрәҗәдә күрәбез. Мөгаен, «Хаким», «Закир» китапларының авторы да фин, швед, төрек, Европа рухи казанышларыннан азмы-күпме хәбәрдар булгандыр.

Садрый Хәмид үзенең бер әсәрендә: «Яңапарда туган кешеләр, гаҗәп, бар да укымышлы», – дип яза. Бу – һич тә хыял җимеше, әдәби уйланма түгел, ә чынбарлыкка туры килгән хакыйкать. Мәгълүм ки, әлеге авыл – Финляндиядәге (Суомидагы) күпчелек милләттәшләребезнең кече ватаны. Алар арасында никадәр каләм әһелләре, һөнәр ияләре, күренекле затлар бар! Янә шунысын да искә төшерик: танылган Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Рифат Фәттахов, шулай ук Мәскәү һәм Питер калаларында гомер кичерүче күпләгән шәхесләребезнең дә килеп чыгышы Яңапар белән бәйле.

Садрый Хәмиднең әле башка китапларына да тукталырга насыйп булсын дигән теләк белән, журнал өчен язылган мәкаләмә нокта куям. ■

Такташ һәм Сирин

Әнвәр Шәрипов, филология фәннәре докторы



Һади Такташ

Сирин апасы Мәрхабә белән. 1930 нчы еллар

Шагыйрь Сирин Такташ белән кайчан таныша?

1923 елның көзендә Сирин Казанда Татар рабфагына укырга керә. Иҗади яшьләр белән аралаша, әдәби иҗатына җитдирәк карый башлый. Афзал Шамовның кызы Әлфия Шамова хәбәр иткәнчә, Сирин рабфакта Муса Җәлил белән бергә, бер төркемдә укыган. Нәкъ менә шушы 1923-1924 нче елларда Сирин Такташ белән беренче тапкыр очрашып танышкан булса кирәк.

1926 елда рабфакны тәмамлагач, Сирин бер ел Бөгелмәдә «Сабанчы» газетасында эшләп ала. Әмма аның күңеле Казанга тарта һәм ул, 1927 елның көзендә тагын Казанга килеп, Көнчыгыш дәүләт педагогия институтында укый башлый. Монда инде ул нәкъ үзе теләгән иҗади атмосферага эләгә: Һ.Такташ, Г.Кутуй, Х.Туфан, Ә.Исхак һәм башка иҗади яшьләр орбитасына кереп китә. Ул бөтен тырышлыгы белән белем алуга, иҗат эшенә бирелә. Студент елларын (1926-1930) Сириннең тормышында да, иҗатында да яңа бер этап итеп карарга, аның тормышта да, поэзиядә дә үз-үзен эзләве, эзләнү чоры дип атарга мөмкин.

Студент буларак, Сирин бик тырышып укый. Үзенең истәлекләрендә ул: «Мин, утырган тавык кебек, һәр кичне дәресләр өстендә утырам. Атнага бер мәртәбә әдәбият түгәрәге була, анда катнашам. Анда Такташ, Кутуй, Нур Баян, Демьян Фәтхи һәрвакыт булалар иде... Язарга бер дә вакыт булмаса да, аратирә мин дә язгалап куя идем», – дип искә ала (Тормыш хатирәләре. – «Казан утлары». – 1916. – №12. – 150 б.).

1920 нче елларда Казанда, билгеле булганча, иҗади яшьләрнең төрле әдәби кумәк һәм оешмалары барлыкка килә. «Егерменче елларның беренче яртысында әдәби түгәрәкләр активлашып китә, – дип язылган «Татар әдә-

бияты тарихы»ның дүртенче томында. – Болар арасында бигрәк тә «Октябрь» күмәгенең роле зур булды... «Октябрь» күмәге татар совет язучыларын бер оешмага туплауда шактый эш башкара. 1924 елда «Октябрь» күмәге членнарының бер өлеше Г.Кутуй һәм Г.Толымбай җитәкчелегендә «Сулф» («Сул фронт») исемле яңа күмәк төзиләр һәм «Октябрь»дән аерылып чыгалар» (Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 4 том. – Казан, 1989. – 95-96 б.).

Сирин дә «Сулф» күмәгенә керә. Шагыйрь Әхмәт Исхак үзенең истәлегендә («Чаян» журналы. – 1987. – №3.) Сирин белән 1923 елда ук танышканлыгын әйтә. «Тора-бара дуслашып киттек, – дип яза ул. – Бер-беребезгә шигырьләребезне укыштык, киңәшләштек, бәхәсләштек, театр-киноларга бергә йөрдек. Ул вакытларда иҗат яшьләре арасында киң таралган яңалык эзләү җилләренә бирелеп, «футуризм» дигән чирне йоктырып, «Сулф» («Сул фронт») дигән төркемгә иярдек».

Драматург Риза Ишморат та үзенең истәлекләрендә, Казандагы 1920-1930 нчы еллардагы иҗади яшьләр турында язганда, Сиринне дә искә алып китә: «Кутуй, Такташ, Илгизәр (Хуҗа Рафиков), Сирин, Вил Уразай (Габдулла Вилданов), Әсгать Мәҗит кебек күп кенә әдәбият һәм театр эшлеклеләренең безнең белән якын бәйләнештә булуы яшьлегебезгә аерым бер күркәм тулылык бирә иде» (Дусларым, остазларым. Истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 148 б.).

Бу елларда барлык татар шагыйрьләре, шул исәптән Сирин аралашып яшәгән Такташ, Кутуй, К.Нәҗми һ.б.лар да поэзиядә үз урыннарын табарга омтылып, төрле экспериментлар үткәрәләр. Мәсәлән, Такташның «Тиләләр», «Янар таулар», Кутуйның «Көн – кадак», «Карт пычкычы», К.Нәҗминең «Еллар гына юып бетермәс», «Кабыргасы белән тора» һ.б. әсәрләре. 1926-1928 нче елларда Сирин дә шигырьләренең формасы белән мавыгып ала. «Беренче май» (1926), «Көнлиләр» (1927), «Безнең кайгылар» (1928) шигырьләрендә ул, катлаулы образлар, сүзләрнең охшаш яңгырашы белән мавыгып, аларны тезеп төшә һәм әсәрнең эчтәлеген күздән ычкындыра. Аның бу әсәрләре матбугатта шул ук елларда тәнкыйть ителде. Ярый әле шагыйрьнең мондый мавыгулары озакка бармады. «Октябрь» һәм «Сулф» күмәкләре озын гомерле булмаган кебек, бер-ике елдан Сирин дә үзенең бу экспериментларыннан арынды. Ләкин Маяковскийга иярүен ташламады, аның кебек трибун шагыйрь булырга омтылган иҗатын дәвам иттерде.

1928 елда Сиринне яңа гына оешкан ТАППка әгъза итеп алалар. Нәкъ менә студент еллары һәм шуннан соңгы биш-алты ел (1928-1935) – Сириннең иң актив иҗат иткән, көчле трибун шагыйрь булып танылган чоры.

Сириннең бу чордагы эзләнүләре башлыча поэзиядә үз язу стилен, үз шигъри формасын эзләүдә, эчтәлек белән форманың органик берлегенә ирешергә тырышуда күренә. Әсәрләренең сәнгатьлелегенә ирешүдә ул бер алымны – һәр сүзне аерып алып, аның тирән мәгънәсен ачып салып, аларны бер-бер артлы юлдан-юлга тезеп бару алымын куллана. Бу исә шигырьнең эчке ритмын нечкә тоемлап, ачык яңгырашлы рифмалар сайлап язуны таләп итә. Иҗатының башыннан ук Сирин шушы юнәлештә тәҗрибәләр ясый башлый: «Салкын энәләр» (1922), «Тегүче кыз» (1923) әсәрләре үк шушы алым белән язылган. Шушы алым белән Сирин 1927 елда иң атаклы әсәрләренең берсен – «Язгы тамчылар» шигырен яза. Бу әсәрдә ул, бер яктан, охшаш яңгырашлы сүзләрне сайлап, тамчылар тавышын чагылдырырга омтылса, икен-

че яктан, әсәрнең эчтәлегенә дә тирән мәгънә сала:

Там,
Там,
Тамчы, там,
Тамуыңны яратам.
Тамчы-тамчы,
Җырларыңны
Ак кәгазьгә таратам.

Ул язгы тамчыларның поэтик матурлыгын җырлап кына калмый, ә бу күренешне җәмгыять тормышы белән дә бәйли, шуның белән әсәрнең иҗтимагый ролен дә көчәйтүгә ирешә. «Там, там, тамчы, там!» сүзләрен ул рефрен итеп куллана һәм алар, һәр кулланган саен, әсәрнең иҗтимагый мәгънәсен көчәйтә, тирәнәйтә баралар, идеясен ачарга ярдәм итәләр:

Там,
Там,
Тамчы, там,
Бергә тамыйк ичмасам!
Мин дә тамчыланып тамыйм,
Көрәшләрдә аксын кан!

Басылып чыгу белән (1927) бу әсәр халык арасында бик тиз таралган һәм халык, аны яратып, аңа көй дә язган. Шул көй безнең көннәргә кадәр килеп җиткән – ул көй әле бүген дә кайбер балалар бакчаларында музыка дәресләрендә нәниләрне биеткәндә уйнала. Шулай итеп, 1930 нчы еллар татар поэзиясендә башка беркемнекенә дә охшамаган «Сирин стиле» дигән күренеш барлыкка килә. Бу Такташ стиле дә, Хәсән Туфан стиле дә түгел иде. Татар шагыйрьләреннән аеруча Такташны якын күрә Сирин. Алар икесе дә бунтарь җанлы, икесенең дә үзләренә генә хас язу стильләре бар. Бер-берсе белән алар якын дус булганнар, ярыша-ярыша иҗат иткәннәр. Ул елларда Казанның иң зур залларында уздырыла торган әдәби кичәләрдә икесе дә яңгыратып шигырь укыганнар, яшьләрнең, студент кызларның иң яраткан шагыйрьләренә әверелгәннәр. Рифгать Батыршин (Сириннең энесе Мәхәсимнең улы) үзенең истәлекләрендә инде 1951 нче елларда Казан авыл хуҗалыгы институтында немец теле укытучысы, өлкән яшьтәге Алмаева Фатыйманың Сирин турында әйткән сүзләрен китерә: «Без, студент кызлар, Сирин, Такташ, Кутуй нинди клубларда чыгыш ясыйлар, шунда чаба торган идек. Шигырьне бигрәк шәп сөйлиләр иде». Ә шагыйрь Ямаш Игәнәй исә үзенең «Эз сызып атылган йолдыз» дигән мәкаләсендә Сирин турында: «Заманында сәхнәләрдә Һади Такташ белән ялкынлы шигырьләрен укып йөргән шагыйрь бит ул. Татар шигъриятендә яңалык ачучы, – дип яза һәм Сириннең үз сүзләрен китерә: «Сәхнәнең бер ягыннан – Такташ, икенче ягыннан мин килеп чыга идем. Укып җибәрәбез шигырьне, зал нишләргә белми, сихерләнә, илаһи шаукымга тоташ уралып, тылсымлы-серле халәтнең иң югары ноктасында бөтерелә», – дип сөйләгән иде ул бер очрашу вакытында» («Аргамак» журналы. – 1996. – №12. – 96 б.).

Такташ иҗатында да, Сирин иҗатында да Гражданнар сугышы темасы чагылыш таба. Әмма аларның бу сугышка булган мөнәсәбәтләре бер-берсеннән аерыла. Сирин әлеге сугыш вакыйгаларында турыдан-туры катнаша. Билгеле булганча, 1918-1920 нче еллардагы Гражданнар сугышының давыллы вакыйгалары Сириннең туган авылы Кәрәкәшле аша да үтә. Бу турыда ул үзенең истәлекләрендә яза (Кара: «Казан утлары». – 2016. – №12. – 139-149 бб.). 1919 елда Бөгелмәдәге укытучылар әзерли торган семинариядә укыган чакта исә «Сәнәкчеләр» белән сугыш

вакыйгалары Сиринне үз эченә бөтереп алып кереп китә. Бу турыда, Сириннең вафатыннан соң, аның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнгән язучы Мәгъсүм Латифуллин болай дип яза: «1920 елның январь-март айларында акгвардияче Колчак бандасы калдыклары коткысы белән Чистай, Минзәлә, Бөгелмә өязләрендә кулаклар баш күтәрде. Халык теленә «сәнәкчеләр» дип кергән бу фетнәчеләр яшь совет республикасы өчен куркыныч тудыралар иде. Партия һәм комсомол өяз комитетлары аларны бастыру өчен ашыгыч чаралар күрергә мәҗбүр булды. Комсомол отрядлары төзеп, фетнәчеләрне бастыру өчен Акташ ягына җибәрделәр. Шундый ук отряд РКСМ өяз комитеты каршында да төзелә. Бу отряд күбесенчә Бөгелмә татар тәгълим-тәрбия курсларында укучы комсомоллардан тора иде. Комсомолларның Кожух җитәкчелегендәге корыч сафларында кулына мылтык тоткан Сирин дә бар.

Алдан киткән комсомол отрядларына ярдәмгә Кожух командасы кузгала. Кирәкле корал, патрон алып, атларга төяләләр һәм буранлы төндә кар ерып баралар. Кодаш авылына җиткәч, атларны фетнәчеләр урап ала. Атыш китә. Кожух утырган ат урам буйлап чапканда, фетнәчеләр чанага ябышып, өстерәлеп барган кешене күрәләр һәм: «Балта белән! Чалгы белән! Кулына чап!» – дип куалар. Бу Сирин була. Кожух аны күтәреп чанага сала, фетнәчеләр кулына бирми.

Шулай итеп Сирин, бер кулына корал, икенчесенә каләм тотып, зур көрәш мәйданына чыга».

«Сәнәкчеләр фетнәсе» темасы Сириннең 1964 елның май аенда язган «Бөгелмәдә туганнар кабере янында» дигән шигырендә күтәрелә.

Сирин иҗатында Гражданнар сугышы темасы тулырак чагыла. Бу темага ул «Кызыл гаскәргә» («Татарстан» газетасы. – 1922 ел. – 7 ноябрь саны) һәм «Сикерт атың! (Кавалерия маршы)» (1927) шигырьләрен яза. «Кызыл гаскәргә» шигырендә Сирин Гражданнар сугышын Такташ кебек үк революцион романтика яссылыгында сурәтли:

Туры атларга менеп, кылыч алып,
Гайрәтләнеп, ерак юл барып,
Күкрәкләргә кызыл тасма тагып,
Йөрәкләргә кызыл ут ягып,
Бармадыкмы залим дошманнарга,
Ерак-ерак әллә кайларга?!.
Ут яндырып, җирдә күк күкрәтеп,
Кылыч болгап, яшен уйнатып,
Бөтен дөньяларны дер тетрәтеп,
Шат көлешеп, рәхәт уйнашып,
Кумадыкмы залим дошманнарны,
Алмадыкмы иске үчләрне?!.

Сирин белән Такташның шулай үзара очрашып, фикерләшеп иҗат итүләре озакка бармый: Такташ 1931 елның 8 декабрендә вафат була. Бу югалтуны Сирин бик авыр кичерә. Үз күңелендә давыллаган хисләрне шагыйрь «Зәңгәр күзле егет юк инде» һәм «Такташ табуты янында» әсәрләрендә сурәтли; ул аларны 1931 елның 10 декабрендә язган. Беренче шигырендә (ул «Яңалиф» журналының 1931 елгы 12 нче санында басылып чыккан) Сирин үзенең якын дусты Такташның халкыбызның сөекле шагыйре булуын ассызыклый:

Яфракларга уен бәйләп йөргән
Көчле шагыйрь
бүген күмелде.
Тамбов урманы күк
Шаулап үскән
Бөек талант хәзер юк инде.
Сүзләр белән
Бомба, туплар ясап,
Буржуага утлар ташлаган,
Миллионнарның батыр бер җырчысы
Бүген китте безнең арадан. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Фәтхи Бурнаш һәм шәһри Казан

Нәкыйп Каштан

Драматург, шагыйрь һәм прозаик, публицист, тәрҗемәче, театр эшлеклесе Фәтхи Бурнаш Буа өязенә кергән Кыр Бикшиге авылында дөньяга килә. Әмма Казан да аның туган шәһәре саналырлык. Эш шунда ки, әтисе аны 9 яшеннән үк (7 яшьлек энесе Вафа белән бергә) татар мәркәзенең данлыклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бирә. Бүгенге заман күзлегеннән караганда, 1 һәм 3 сыйныфта укучы балалар яшендә генә булса да, алар әти-әниләреннән читтә мөстәкыйль көн итәргә, тамак хәстәрен кайгыртырга тиеш була. Фәтхи белән Вафа кулыннан бу елларда күп төрле эш үтә. Мәсәлән, Фәтхинең казакъ далаларында укытып йөрүе, Мәкәрҗә ярминкәсендә ашчы ярдәмчесе булып эшләве мәгълүм.

Фәтхи Бурнаш

Егет чагында Фәтхинең Салих Сәйдәшев белән бергә Кыр Бикшигенә кайтуы теркәлеп калган. Бер кайтуында ул йортлары каршына тупыл агачы да утыртып китә. Бу тере ядкяр бүгенге көнгә инде өч мәртәбә яңарды. Ә менә энесе Вафаның туган якларына кайтуын хәтерләмиләр. Күрәсең, үзенә белем биргән, егет итеп җитлектергән, шәхес буларак формалаштырган Казан каласы аңа якынрак булгандыр. Вафаның Ватандашлар сугышында ялкынлы комиссар сыйфатында катнашуы билгеле. Ул генерал Якуб Чанышев белән бергә Төркестан «яулары»нда алгы сызыкта көрәшә. Соңрак Казанда җитәкче урыннар били. Фәтхи Бурнашның энесе Вафага багышлап язылган «Кайт кызыл гөлләр белән» (1921) дигән шигыре дә бар:

Саклагансың алтатарыңны каһарманнар кебек,
Әй, туган, рәхмәт сиңа, рәхмәт, озын юллар тезеп,
Коммунар, кан дәрьяларыннан җиңеп чыктың йөзеп;
Кайт, китер шул сахралардан тергезеп, гөлләр өзеп;
Кайт, хәзер син шат көлеп, чүлләр йөреп җырлар белән;
Илгә кайт кулларда тулган ал, кызыл гөлләр белән!

Бер уңайдан шунысын да әйтик: Вафа Бөек Ватан сугышында да катнаша һәм аннан исән-имин әйләнеп кайта; 1959 елда абыйсы Фәтхи Бурнашның ике томлык сайланма әсәрләрен әзерләп чыгара, 1969 елда, пьесаларын, шигырьләрен, поэмаларын туплап, «Яшь йөрәкләр» исемле китап нәшер итә.

Фәтхи революция башланган елларда 18-19 яшьлек хыялый егет була, иҗатта кайный, сәясәттән шактый ерак тора. Ләкин тормыш үзенекен итә, илдә барган вакыйгалардан читтә калу мөмкин булмый. Революция, кинәт кабынып киткән Ватандашлар сугышы Фәтхине дә үз эченә бөтереп ала. Монда шунысы да бар: юклык, гаделсезлек чорында гади халык белән югары катлам арасында кискен каршылык туа. Гаделсезлек белән көрәшү теләге Фәтхи Бурнашның яшь йөрәген аеруча җилкендерә.

Архивларда сакланган документларга караганда, Фәтхи Бурнашның әнисе Гайнелхәят Мөхәммәтзакир кызы морзалар нәселеннән була. Имам Мөхәммәтзакир, аның әтисе – имам Сәйфелмөлек (1791-1837), аның әтисе – Габдессәлам, аның әтисе – Габделсәлим, аның әтисе – Мәхмүт Бихайкин морза (1709-1779), аның әтисе – Бигай, аның әтисе – Кудаберди (Ходайбирде) Шыгырдан авылыннан. Фәтхинең әтисе Мөхәммәтзакирның шәҗәрәсе, риваятьләр буенча, кенәз Борнашка барып тоташа. Авылда Борнашлар нәселе тоташ имам-мөдәррисләрдән гыйбарәт.

Инде шагыйрь-драматургның мәдрәсә чорына әйләнеп кайтсак, Фәтхи Бурнаш шул чорда ук әдәбият, музыка, сәхнә уеннары белән кызыксына, әсәрләр язарга хыялланып яши. Фәтхидә яшьтән үк музыкага тартылу була. Аның пионинода әйбәт уйнавы һәм моңлы итеп җырлавы мәгълүм. Ул соңрак Германиядә эшләнгән пианино да сатып ала һәм ял иткәндә аңарда уйный, моңлана торган була. Фәтхинең музыкаль осталыгы турында Дилбәр Вафа кызы Бурнашева да сөйләгән иде. Ул – Казан медицина институты доценты, үзе дә пианинода уйный һәм бик матур җырлый иде.

Фәтхи Бурнаш Казан каласында үсеп, ир-егет булып җитешкән, дидек. Алай гына да түгел, монда ул әдип буларак та формалаша. Казанга мөнәсәбәте аның иҗатында ярылып ята:

Киң Иделнең яр читендә, баксана,
Нинди өлкән, зур, мәһабәт таш кала!

Нинди матур җырлап аккан елгасы,
Күр: ничек күкрәк кийреп таш коймасы

Күңлеңә шатлык бирә, баккан саен,
Уйлатып Чыңгызларын, Алтай тавын.

Зур шәһәрнең иң түрендә, уртада
Изге мәсҗиднең манарасын кара.

Күр: илаһи нур белән чолганып,
Кырланып менгән саен бер сырланып –

Кичке йомшак җилдә уйнап чык кына,
Нинди моң көйләп тора, җырлап тора!

Кемнеке, дуслар, беләмсез ул кала?
«Безнеке!» дип кем аныңлә[1] *мактана,*

Әйтче, кем соң, шул рус халкымы?
Әллә герман йә француз халкымы?

Күп җәфа күргән Италия халкымы?
Дөнья кизгән Португалия халкымы?

Әллә ялкау Азия халкы, чин микән?
Әллә бер йәһүд микән, йә фин микән?

Юк, түгел, һичберсенең катышы юк,
Анда рус, фин, чин дә, герман халкы юк.

Йөрми анда һичберәүнең фәрманы –
Ул татарларның мөкаддәс гомраны[2]*!*

[1] Аныңлә – аның илә, аның белән.
[2] Гомран – төзек корылмалы, мәдәниятле җир.





Фәтхи Бурнаш. 1942 ел

Автор бу юллар аша үз милләтенә немец, инглиз, гарәп кебек үк алдынгы фикерле, тигез хокуклы халык итеп карый. Шигырьдә Фәтхи Бурнашның үз заманы кешеләренең рухын, халәтен күрсәтергә омтылышы сизелә. Шагыйрьнең гаҗәеп бай, нәфис тел белән язылган бу шигыре аның шәһри Казанга булган мәхәббәтен ачып сала. Казан каласы үзе дә, факел булып, аның матурлыгына мөкиббән булучы егеткә юл күрсәтә, иҗатына фатиха бирә кебек.

Шагыйрь 1916 елда гына да алты поэма иҗат итә. Язучы Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш шигърияте, поэмалары турында фикер йөрткәндә, аның күзаллавының хыялларга бай икәнлеген, табигый тел белән тасвирлавын, иркен фикерләр белән язуын искәртә. Әдәбият галиме Азат Әхмәдуллин Фәтхи Бурнашның иҗатын барлап, бөтен нечкәлекләре белән тирәнтен өйрәнә. Әдипнең тууына 120 ел тулу уңаеннан Татарстан китап нәшрияты әзерләп чыгарган китапта ул болай дип яза: «Фәтхи Бурнашның беренче поэмаларына трагизм характерлы. Аның беренче поэмалары 1916 елда язылган, 6 поэма, аңа бу вакытта нибары 18 яшь әле. Аларны шул чорда язылган башка автор әсәрләре белән чагыштырганда, Бурнашның «Авылда», «Дулкыннар арасында», «Коркыт» поэмалары үзләренең нәфислеге белән дә, укылышлы теле ягыннан да өстен торалар».

Фәтхи Бурнаш 1917 елда «Габделмән», «Айсылу» поэмаларын һәм аңа танылу алып килгән «Таһир һәм Зөһрә» классик драмасын иҗат итә. Әдип, беренчеләрдән булып, Александр Пушкинның «Евгений Онегин» поэмасын, Николай Островскийның «Как закалялась сталь», Максим Горькийның «Мать», Иван Тургеневның «Отцы и дети», Лев Толстойның «Хаджи Мурат» әсәрләрен һәм башка иҗат җимешләрен татарчага тәрҗемә итә. Егерменче еллардан соң да күп кенә сәхнә әсәрләре яза: «Хөсәен мирза» , «Камали карт», «Ташландыклар», «Адашкан кыз», «Тукучы Әсма», «Хәтирә апа», «Лачыннар», «Ялгыз Ярулла», «Яшь йөрәкләр»... Болар – чын-чынлап татар әдәбияты классикасы үрнәкләре.

Фәтхи Бурнашның гомер юлы көрәштән тора. Бала чагында ул яшәү, тормыш кору, белем алу өчен көрәшсә, соңрак, яшьлек елларын революциягә, бердәнбер хак юлны эзләүгә багышлый. Ул үзен бу юлда каләме аша таба, иҗат итә. Әмма аңардан кара көнләшүчеләр дә күп була...

Фәтхи Бурнаш, ялган әләкләр һәм шәхес культы корбаны булып, 1942 елда атып үтерелә. ■

Үткәннән шигырь

Белмим, үзең сизәсеңме...

Узган җәйдә (2 июнь, 2020 ел) без, «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре (Ленар Гобәйдуллин белән мин бахырыгыз), Мөслим якларыннан кайтышлый, Мамадыш районының Тулбай авылында булып, могтәбәр әдип Шәйхи Маннурның музеен караган идек. Андагы бихисап фотоларны күздән кичергән вакытта, Х.Туфанның бер сурәтенә һәм аның артындагы шигырьгә игътибар иттек. Әлеге шигырьнең авторы – Хәсән Туфан. Ул аны 1961 елның 15 гыйнварында каләмдәш дустының туган көне уңаеннан язган булган икән. Әлеге фото белән шигырьне сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез:



«Белмим, үзең сизәсеңме,
Безгә үрнәк бирәсең:
Киләчәккә Тукай кебек,
Туры юлдан киләсең.

Трибунага чыкканыңда,
Колак салып сүзеңә,
Сокланып мин, уйга калып,
Карап торам йөзеңә:

Нигә Маннур кискен сүзле,
Тугры телле икән, дип;
Туган елың
Кискен елга
Туры килгән икән бит!

Синең йөздә гадел караш,
Туган әнкәң карашы.
Шундый булмый – нинди булсын
Бишенче ел баласы.

Туган көнең белән котлап, Х.Туфан. 15.1.61»

Тулбай авылы (Мамадыш) китапханәсендә.
Сулдан уңга: Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Шәйхи Маннур һәм Хәмит Ярми. 1973 ел

Шигырьне һәм фотосурәтне журналга ***Ләбиб Лерон*** *тәкъдим итте.* ■

Бер бәйләм беркетмә

«Ялкын»лы ялкынлы еллар хатирәсе

«Ялкын» журналының гыйнвар, февраль һәм март саннары (1961)



«Ялкын» журналының баш мөхәррире Газиз Мөхәммәтшин (1932-1972)

«Ялкын» журналының редколегия утырышы беркетмәләрен карап, укып утырам. Аларда – шул заман рухы. Мине аеруча җәлеп иткән нәрсә – утырышта күренекле шәхесләребезнең, әйтик, Газиз Мөхәммәтшин (баш мөхәррир), композитор Әнвәр Бакиров, галим Гыйлем Камай, язучы Барлас Камалов, шагыйрьләр Илдар Юзеев (ул журналның җаваплы сәркатибе дә) һәм Шәукәт Галиевләрнең даими катнашуы, уй-фикерләрен җиткереп, «Ялкын»ны ничек тә сыйфатлы, эчтәлекле, укучыларның яраткан журналы итәселәре килүе. Кечкенә генә беркетмә, әмма анда – тарих, шәхесләребезнең уй-гамьнәре...

Ләбиб Лерон

Гыйлем Камай

Барлас Камалов

Шәүкәт Галиев



Әнвәр Бакиров

Гыйнвар беркетмәсе

1961 ел, 12 гыйнвар.

«Ялкын» журналы редколлегиясенең утырышы.

Көн тәртибендә:

Редколлегия членнарын журналның киләчәк планы белән таныштыру.

Көн тәртибе буенча журналның баш редакторы Газиз Мөхәммәтшин редколлегия членнарын февраль һәм март номерлары (саннары) белән таныштырып үтә.

Башта сорауларга җавап бирелә.

Чыгып сөйләделәр:

Әнвәр Бакиров:

– Мәктәпләрдә иң артта калган мәсьәлә – художество тәрбиясе. Журналда һәр номерга сәнгать календаре (рәсем, театр, музыка) биреп барырга кирәк. 12 номерга 12 теманы алдан билгеләргә һәм иҗади союзлар белән тикшерергә кирәк. Нота бирү генә җитми.

Гыйлем Камай:

– Балаларга политиканы аңлатырга кирәк. 81 ил партияләренең декларациясен читләтеп үтәргә ярамас.

8 мартка аналарга мәхәббәт турында бик җылы итеп бирәсе иде.

Төрле милләт әкиятләрен кертү бик кирәк.

Барлас Камалов:

– Пленум карарларын күбрәк бирергә. Чөнки анда XX съездга чакыру турында да документ бар.

Мәхмүт Әхмәтҗанов:

– Актуаль политик яңалыкларны бирү өчен запас битләр калдырырга кирәктер. Туган илебездәге шәһәрләр белән таныштыру әһәмиятле (экскурсияләр белән бәйләү).

Редколлегия утырышын айга бер тапкыр билгеле бер көндә үткәрергә.

Ләлә Зарипова:

– Укытучыларга мәхәббәт уята торган материал яки диспут бирүне уйлагыз. Пионер галстугы турында материал бирү бик әйбәт.

Гыйлем Камай:

– Олыларга мәхәббәт темасын, гомумән, еш бирергә кирәк.

Идея Гумерова:

– Укытучыга мөнәсәбәтне, чынлап та, кузгатырга кирәк.

Пленум материалларын фактически, пионерларга конкрет аңларга ярдәм итәрлек бирергә кирәк. Анда катнашкан кеше чыгыш ясаса, бигрәк әйбәт.

Шәүкәт Галиев:

– 6 айлык планны, бәлки, актив язучыларга аңлатыргадыр. Язучы үзенә ошаган теманы сайлап алсын.

Язучыларга заказ да бирергә кирәк. Актив туплансын.

Газиз Мөхәммәтшин:

– Утырыш файдалы булды. Тагын бер айдан җыелырбыз. Материалларны тизрәк җибәрсәгез иде. Фикерләрегез өчен зур рәхмәт!

Җыелыш рәисе *(Г.Мөхәммәтшин)*
Сәркатип *(И.Юзеев)* ■

безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Илдар Юзеев вафаты
(1933-2004)

Ләбиб Лерон

Без сүнәрбез, янган йөрәкләрне
Аңлаучылар табылыр әле.
«Йөрәклеләр Җирдә бар иде!» – дип,
Тормыш безне сагыныр әле.

Илдар Юзеев

Илдар абый гомеренең соңгы елларында берара «Сабантуй» (элекке «Яшь ленинчы») газетасы редакциясендә эшләп алды. Бик дәртләнеп, яратып, балалар әдәбиятына һәм әдипләребезгә нисбәтле сәхифәләр алып бара башлады. Заманында (1960 нчы еллар башында) «Ялкын» журналында сәркатип буларак та журналист каләмен чарлаган шагыйрь иҗатында бу күркәм чагылыш тапты: балаларга нисбәтле язмалары, яңа шигырьләре матбугат битләрендә ешайды. Әмма әлеге иҗади активлык, ни кызганыч, озакка бармады. Кайчандыр Венера Ихсанова, Роза Туфитуллова һәм Роберт Миңнуллиннар – баш мөхәррир; Ренат Харис, Саимә Ибраһимова һәм Вакыйф Нуриевлар – җаваплы сәркатип; Зөлфәт, Хәкимҗан Халиков, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Госман Садә, Нияз Акмал, Сәйдә Зыялы, Илгизәр Сәмигуллина, Рәйсә Яхина, Камил Кәримов, Хәйдәр Гайнетдинов, Рифкать Закиров, Мөхәррәм Каюмов, Нургали Булатов, Фирая Бәдретдинова, Фоат Хәмидуллин, Юрий Денисов, Йосыф Вәлиәхмәтов һәм Николай Седовлар журналист, рәссам, фотограф булып эшләгән бу редакциядә берзаман язучыларны өнәп бетермәгән кешеләр пәйда булды. Һәм шулар көннәрдән беркөнне Илдар Юзеевны эшеннән кысрыклап чыгардылар. Илдар абый моны бик авыр кичерде. Шул ук көнне ул безнең «Салават күпере» һәм «Сәхнә» редакцияләренә килеп, безгә, баш мөхәррир Зиннур Хөснияр, җаваплы сәркатип Вакыйф Нуриев һәм мин бахырыгызга бу хакта әрнеп сөйләде. Шул чагында Зиннур Хөснияр егетлек эшләде:

– Илдар абый, иртәгә үк безгә эшкә кил! – диде.

Шулай итеп олпат шагыйребез «Сәхнә» журналы редакциясендә эшли башлады. Монда фикердәшләрен, яңа дусларын тапкан әдипнең икенче сулышы ачылып киткәндәй булды – сәнгать темасына кагылышлы мәкаләләре, шигырьләре, җырлары (әйтик, «Сәхнә» җыры, көй авторы – Илфат Дәүләтшин) бер-бер артлы журнал битләрендә дөнья күрде. Мин эшләгән «Салават күпере»ндә дә ул бәйләм-бәйләм яңа шигырьләр бастырды. Әмма аңа безнең редакциядә дә озак эшләү насыйп булмады – соңгы еллардагы төрле кагылу-сугылулар, олы улы Илгиз белән бәйле тынгысызлыклар Илдар абыйны безнең арадан алып китте...

Көн дә күреп ияләшкән Илдар абыйны бер-ике көн эштә күрмәгәч,

хезмәттәшебез Вакыйф Нуриевтан сорыйсы иттем:

– Нишләптер, Илдар абый эштә күренми, бер-бер хәл булмагандыр бит? – дидем.

– Хастаханәгә кергән ул, – дип әйтеп куйды Вакыйф. – Бер ай чамасы элек кенә олы улын җирләгән иде…

Аның улы Илгиз үлгәнен мин белми калган идем. Илдар абый бу хакта Вакыйфка гына әйткән булган икән. Гомумән, шагыйрь гаилә мәсьәләсендә бик ачылып китми торган иде – үзе генә белгән сәбәпләре булгандыр инде…

Мин Вакыйфка:

– Әйдә, алайса бүген Илдар абыйның хәлен белеп кайтабыз! – дип әйтеп кенә өлгердем, шул минутта кемдер, телефоннан шылтыратып, шагыйрьнең әле генә вафат булганын җиткерде.

Бу хәбәр безгә аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте…

Шул көнне искә төшереп: *«Сәхнә» журналына эшкә барырга дип, ишек тоткасын кулына алган җиреннән Юзеевны «Ашыгыч ярдәм» машинасы алып киткән. Илдар дәрәҗәсендәге шәхесләр, эшкә йөрмичә, гонорарга яшиләр. Ул соңгы көненә кадәр эшләде. Һәм эшкә барышлый гына фани дөнья белән саубуллашты»*, – дип язды соңыннан (18 февраль, 2007 ел) Миргазиян ага Юныс «Моңсу шагыйрь» дигән истәлегендә…

Көндәлектән:

«21 декабрь, 2004 ел.

Илдар абый (Юзеев) вафат. Улы Салават әйтүенчә, өч көн элек кенә инфаркт булган. Бүген төнлә хәле кисәк үзгәргән…

Илдар абыйның үлеме турында Ркаил Зәйдуллага, Батуллага, Ризван Хәмидкә һәм Рөстәм Мингалимгә шылтыратып әйттем. Мәгъсум абый Хуҗин өйдә булмады, ахры, трубканы алмады. Әхсән Баяновка да хәбәр итә алмадым.

Вакыйф Нуриев, Фәрит Муллахмәт һәм мин Бутлеров-Мөштәри урамнары чатындагы моргка бардык. Анда Илдар абыйның улы Салават һәм тагы бер егет (ул егет Илдар абыйның абыйсы, тәнкыйтьче-галим Нил Юзеевнең улы Айдар булмадымы икән? – ***Л.Л.***) *бар иде инде. Күпмедер вакытлар үткәч, егетләр Илдар абыйның гәүдәсен, «ПАЗ» автобусына салып, фатирына – Заря урамындагы 6 нчы йортка алып киттеләр. Илдар абый ул йортка күптән түгел генә күчкән булган икән...*

Мин дә илтешкән булыр идем, ләкин миңа Бәхтиярне мәктәптән барып аласы булды. Мин киткәндә, Язучылар йортына Ризван Хәмид белән Ркаил Зәйдулла килеп калды.

Вакыйф «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан» һәм «Мәдәни җомга» газеталарында бастыру өчен некролог язды.

Кичен Марсель Галиев шылтыратты – Илдар абый хакында сорашты...»

«22 декабрь, 2004 ел.

Сәгать 10:30да Илдар абый гәүдәсен Г.Камал театры бинасының фойесына куйдык. Вакыйф белән Ркаил шагыйрьне фатирыннан алып килеште. Без, Шамил Бәдретдинов (Язучылар берлеге хезмәткәре) белән икәү, театр янында каршы алдык.

Сәгать 11:00. Мәтам митингын Римма Ратникова ачты һәм алып барды. Президент Минтимер Шәймиев, Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин, башкорт шагыйре Марсель Сәлимов, Янаул хакимияте башлыгы урынбасары һ.б. сөйләде.

Илдар абыйның гәүдәсен күтәрешеп чыктык.

Зиратка ике автобус (берсе бик зур, икенчесе – «ПАЗ») барды. Мәрхүмнең җәсәден зиратка хәтле озата баручылар (исемдә калганча): Зәки Зәйнуллин, Фәрит Муллахмәт, Вакыйф Нуриев, Ркаил Зәйдулла, Зиннур Мансуров, Шәүкәт Галиев, Альберт Яхин, Галимҗан Гыйльманов, Шаһинур Мостафин, Шамил Закиров, Данил Салихов, Мөдәррис Әгъләм, Риф Тойгынов (башкорт шагыйре), Марат

Фәнис Фәтхи (уртада) һәм Ләбиб Лерон олпат шагыйребез Илдар Юзеев белән «Татарстан» кунакханәсендә. 2003 ел.
Фотога төшерүче – Мөнир Вафин

Закир, Рәдиф Сәгъди, «Сәхнә» журналы редакциясе кызлары – Зимфира Гыйльметдинова, Лилия Галәвиева, Нәкыя апа Гыйләҗева, Диләрә апа Даутова (Рәис Даутовның хатыны), студент-шагыйрь Ленар Шәехов, Нәҗибә Сафина һ.б.

Сәгать бердә ике яшь мулла алмаш-тилмәш Коръән укыды. Кабер янында сүз алып сөйләделәр: З.Мансуров, Р.Тойгынов, Ш.Галиев...

Урының җәннәттә булыр, иншәАллаһ, Илдар абый!

Зираттан кайткач, Рабит Батулла, Мөнир Якупов, Рафаэль Сәхәбиев һәм мин, Илдар абыйны искә алып, шактый вакыт сөйләшеп утырдык...»

...Илдар абыйның бакыйлыкка күчкәненә дә байтак еллар узган икән инде. Күңелемдә остазлар турында, могтәбәр шагыйрь Илдар Юзеев хакында яңа шигырь бөреләнә:

...Истә калган соңгы кыяфәте –
Талчыкканы уйчан йөзенең:
Байтак еллар үткән икән ләса
Киткәненә Илдар Юзинең!
Дөньялыктан бераз онытылып,
Гәп куертып алган чакларда,
Шигырь язып, култамгасын куйды –
Ул әле дә миндә саклана:
«Син сорама, шагыйрь кайчан китә,
Нигә китә, яше ничәдә?
Һәммәсен дә, бәлки, аңларсыңдыр
Без утырган шушы кичәдә...»
Без утырган ул кичәләр инде
Хәтерләрдә генә калдылар –
Остаз абыйларым бер-бер артлы
Бакыйлыкка китеп бардылар...

Шагыйрь вафатына тиклем язды, соңгы көннәренәчә иҗат итте. Шигырь язу, иҗат итү аның өчен яшәүгә стимул иде. Әмма ул бу фани дөньядан кайчан да булса бер китәсен белеп-сизеп яшәде, ару-талуны белмичә, язды да язды:

Гадәт-холкым белән кыр казы мин:
Очмаучылар
Сәер, ят алар...
Бәлки,
Мине
Аңлый алмаучылар
Беркөн йөрәгемә атарлар...
Гадәт-холкым белән кыр казы мин:
Егылып
Төшәрмен дә
Сызланып,
Җан бирермен
Соңгы сулышымда,
Очалмаганнарны кызганып...

5 декабрь, 2020 ел ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Гомәр Бәшировның фотомирасы

Зөфәр Бәширов

Әтинең иҗатына бәя биргәндә беркайчан да минем әнине – Кәримә ханымны истән чыгарырга ярамый. 1929 елдан, алар өйләнешкәннән бирле, әни аны карады, тәрбияләде. Язучыга нәрсә кирәк булса, әни барысын да тәэмин итеп торды. Тынычлыкны, язарга, эшләргә бар мөмкинлекне тудырды. Апам Лилия[1] белән шаярганбыздыр, уйнаганбыздыр, тавышланганбыздыр да, шунда әни безне гел: «Балалар, шауламагыз, әтиегез эшли!» – дип кисәтсә, без шып итеп тына идек. «Намус» романы бик авыр шартларда, озак язылды. Әтиәни көне буе эштә, ач булмасак та, өй салкын, тәрәзәләр бозланып ката. Бу вакытта әнием әтигә төп ярдәмче булды. Сугыштан соң, тормышлар җайлангач, әни белән әти гел бергә булдылар. Әти, язып утырган вакытта эшеннән туктап, бүлмәдән чыга иде дә: «Кәримә, тукта әле, сезнең якта мендә бу сүзне ничек әйтәләр?» – дип сорый иде. Әни, бер дә югалып калмыйча, сүзләрнең үз ягында ничек аталганын әйтә иде. Әтинең әдәби иҗатында әнинең дә берникадәр хезмәте бар дип уйлыйм мин.

[1] Лилия – язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең булачак хатыны.

Гомәр Бәширов хатыны Кәримә, улы Зөфәр һәм кызы Лилия белән. Казан. Февраль, 1940 ел

Гомәр Бәширов Сәйфи Кудаш белән. Аккош күле. 16 июнь, 1966 ел

Гомәр Бәширов укучылар белән очрашуда. Арча. 3 гыйнвар, 1981 ел

1967 елда Мәскәү Кремлендә СССР язучыларының IV съезды барган көннәрдә төшереп алынган. Сулдан уңга: Хәй Вахит, Ләбибә Ихсанова, Әхмәт Саттаров, Михаил Львов, Зәйнәп Биишева, Мирсәй Әмир, Җәмил Мостафин, Леонид Соболев, Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким

Гомәр Бәширов каләмдәш дуслары фольклорчы Хәмит Ярми, әдипләр Шәйхи Маннур һәм Хәсән Туфан белән. 7 гыйнвар, 1979 ел

Нәшрият редакторлары. Сулдан уңга: Гази Кашшаф, Афзал Шамов, Асман, Гомәр Бәширов, Рахман Ильяс. Татгосиздат. 11 июль, 1940 ел. *Ибраһим Гази фотосы*

Кичке бер мизгел: Гомәр Бәширов газета укый, хатыны Кәримә апа оекбаш бәйли. 21 гыйнвар, 1968 ел

Әтинең балаларны тәрбияләүдә үзенчәлекле ысуллары бар иде. Ул безне беркайчан да ачуланмады, сукмәде, җайлап кына барысын да өйрәтә иде. Бер мисал китерәсем килә. Урта мәктәптә укыганда сочинение язарга бирделәр. Бар укучы кебек, китаплар алып, аннан-моннан күчереп язасың инде. Берзаман шул сочинениене әти укып карарга булды. «Аңлашылды... Бу синең фикерләрең түгел бит! Күчереп язгансың!» – диде ул. Дәфтәремне читкә алып куйды да: «Менә хәзер үзең нәрсә уйлыйсың, шуны яз!» – диде. Шактый азапланып утыргач, нәрсәдер килеп чыкты һәм борчылып кына дәфтәрне укытучыга тапшырдым. Икенче көнне укытучы: «Менә бу иң дөрес инша, моңа бишле куям», – дип мактады. Әти төгәл, бар эшне җиренә җиткереп эшли торган кеше иде. Безне дә шуңа өйрәтте.

Фольклор экспедициясендә: Гомәр Бәширов, институт хезмәткәре Халидә Гатина һәм әкиятче бабай Галиулла. Июль, 1946 ел.



Гомәр Бәширов эш бүлмәсендә. Казан. 1958 ел

Гомәр Бәшировның шәхси сыйфатларын беләсегез килсә, иң яхшы юл – аның әсәрләрен уку. Ул үзе дә гомере буе тәрбияләнде. Коммунистик идеология таркалгач, олы яшендә аңа дөньяга карашларын үзгәртеп корырга туры килде. Бу бик авыр процесс иде. Моның бер чагылышы «Гыйбрәт» дигән роман булды. Әлеге әсәрне укысаң, әти буыны кичергән фаҗига тулысы белән аңлашыла дип уйлыйм. ■

Фотолар язучының улы Зөфәр Бәширов архивыннан. Зөфәр Бәширов сөйләгәннәрнең аудиоязмасы «Казан арты» тарих этнография музее фондыннан алынды.

«Казан мәгарәсе»ндә очрашу

Фоат Закиров



«Мин диссертацияләр язып вакытны әрәм итеп маташмадым. Чөнки минем фәндәге һәр минутым татар халкы өчен бик кыйммәтле».

Альберт Фәтхи

Альберт Фәтхи... Ходай бирмеш гомеремә кадәр яшәп, аның кебек фидакяр кешене очратканым булмады. Миңа бу галим белән озак аралашырга туры килмәде – нибары өч мәртәбә күрештек. *«Башка килеп йөрмә, эшләргә комачаулама, минем вакытым бик кадерле. Дөньяда минем кебек кешеләр дә бар икәнен белеп яшәсәң, сиңа шул бик җиткән!»* – дигән иде ул бер килүемдә. Әйе, чыннан да, аның вакыты юк һәм ул аңа бик кадерле иде. Әллә инде тиздән үләсен сизгәнгәдерме, бик ашыкты, сөйләшкәндә дә ашыга иде Альберт абый. Эшенә фанатларча бирелеп, китап дигән серле дөньяда яшәде ул. Шул сәбәпле, үз-үзен тотышы белән тирә-юньдәгеләрдән һәм хезмәттәшләреннән бик нык аерылып торды: курыкмады, турысын да өзеп әйтте. Дөрес, үзен өнәмәүләре, яратып бетермәүләре турында да бик әйбәт белә иде Альберт абый...

Казиле чормасындагы табыш

Фәнни институтның тәҗрибә кырында эшләгәндә, колхоз безгә лаборатория һәм Арча районындагы Казиле авылындагы иске генә бер йортны бирде. Күптәннән кеше тормаган ул йортта. Өйне җыештырып, шунда лабораторияне урнаштырдык. Ятаклар куеп, йоклап та кала башладык. Беркөнне кояш баер алдыннан әлеге өй чормасында «тикшеренүләр» алып барырга булдым. Шулай итеп, кәрниз төбеннән гарәп язулы хәйран гына калын кульязма китап таптым. Каурый каләм белән бик пөхтә, тигез итеп язылган иде аңа. Араларында кызыл кара белән язылган юллары да, китап бите кырыена кыеклап язылган өстәмәләре дә бар. Китап нык таушалган: тышлыгы, баштагы һәм ахыргы битләре юк, күп кенә битләре аерылган, чәчелгән. Кульязманы җыеп куйдым. «Агрономның

кышын эшләре азрак, шул вакыт эчтәлеген ачыкларммын әле», – дип уйладым. Көзен тәҗрибә кырындагы эшләрне төгәлләп Казанга кайтканда, әлбәттә, серле табышны үземнән калдырмадым.

Бу – үзгәртеп кору еллары алды иде. Дөнья мәшәкатьләре белән китап турында бөтенләй оныта язганмын. Берничә елдан соң гына, фатир алып, тормыш мәшәкатьләреннән бераз арынгач һәм башка эшкә күчкәч, әлеге китапны яңадан искә төшердем. «Нәрсә турында икән бу? Бәлки, бик кирәкле, бик тә кыйммәтле китаптыр?!» – дигән уй күңелемә тынгы бирмәде.

Казан мулласы: «Искечә язылган, укып булмый...»

Әйткәнемчә, илдә зур үзгәрешләр башланган еллар, көз айлары. Ул вакытта да гарәп телен белүчеләр бик аз иде. Мин, китапны укыту өчен, укымышлы картлар, муллалар эзләп, Кабан арты мәчетенә киттем. Мәчет ишеге төбендә сакта утыручы бабай китапны укый алмады. Намаз беткәнен көтеп торырга, муллага күрсәтергә киңәш итте. Җомга намазы вакытына туры килгәнмен икән. Намаз бетте, түр бүлмәдән төркем-төркем олы яшьтәге абзый-аксакаллар чыга башлады. Мин, кульязманы тотып, аларның каршына йөгердем. Мәчет картлары, шул исәптән имам да әлеге кульязма китапны укый алмады. Әйләндереп-әйләндереп карадылар да: «Искечә язылган, укып булмый... Университет китапханәсенең иске китаплар бүлегендә Альберт Фәтхи дигән галим бар, укыса, бары тик ул гына укый ала», – диде имам.

Беренче күрешү. «Чәй кайнатканга да сүгәләр»

Салкыннар башлангач, бер иптәшем белән шул галимне эзләп киттем. Лобачевский китапханәсенә кереп, Альберт Фәтхине сорадык. Бер юан гына татар хатыны, баскычка чыгучы ишектән башын тыгып, югары каттагы ишеккә карап, бик дорфа итеп, исерек грузчикларга кычкырган кибетче сыман бугаз ярып: «Альберт, әнә, сиңа килгәннәр!» – диде. Без, югары катка менеп, тимер чылбырлар, аркылы тимерләр белән бикләнә торган, зур йозаклары асылынып торган серле ишекне ачып, эчкә уздык. Борынга тузанлы китап һәм «борынгылык исе» килеп бәрелде. Дулкынлану катыш курку хисе. Караңгы... Кайдандыр тонык кына сары яктылык шәйләнә. Килеп керешкә үк идәннән түшәмгә кадәр биеклектә рәт-рәт китап киштәләре башланды. Киштәләрдә

бик зур, берәр метрга якын киңлектәге бик калын китаплар ята. Алар укучыларын көтеп, моңаеп яталар кебек… Моңсу һәм шул ук вакытта серле, гаҗәеп бер дөньяга эләктек. Кайдандыр ерактан, киштәләр арасыннан тавыш килә – кемдер безне эзли: «Әйдәгез, егетләр, монда килегез!» – ди. Тавышы бар, ә кешесе юк. Без кабаланабыз, кая барырга белмибез, китап киштәләре арасында адашып тик йөрибез. Йөри торгач, рәтләр арасыннан каршыбызга саргайган йөзле (кояш яктысы күрмичә, озак еллар мәгарәдә яткан кеше дип уйларлык), озын, ак чәчле, уртачадан кыскарак буйлы, ябык-чандыр гәүдәле, әмма бик җитез хәрәкәтле бер карт килеп чыкты. Башында – хатын-кызныкына охшаган кызгылт беретка. Салкын булгангадыр инде, костюм якаларын, күтәреп, булавка белән каптырып куйган. Без шунда мәгарәдә Әбүгалисина белән очрашкан кебек булдык. Сискәнеп киттек һәм мин борынгы картларча: «Әссәламүгаләйкү-ү-үм!» – дип, инде ничә еллар мәгарәдән чыкмыйча, изге китаплар укып яткан аксакал белән күрешергә ике кулымны суздым. Безнең сәламгә ул бик гади генә, әллә кайчангы якын танышлар кебек: «Ә-ә-ә, саумысыз, егетләр, әйдә, узыгыз, кай яклардан буласыз, ни йомыш белән килдегез?» – дип, эшкә кereште. Без тагын аптыраашта калдык: карап торышка зур гыйлем туплаган, кимендә йөз яшьлек аксакал, ә үз-үзен тотышы белән яшьләрчә гади, шаян һәм бик җиңел сөйләшә.

Якыннан танышкач, аның алай ук олы түгеллеген, ә бәлки, 40-45 яшьләрдәге ир икәнлеген чамаладым. Арып-таушалган һәм саргайган йөз, озын, саргайган ак чәчләр, начар кием генә аны олы күрсәтә икән. Арча ягыннан икәнлегемне әйттем, кулъязманы бирдем. Галим китапны кулына алды да алдагы бер битен ачып укый башлады. Ниндидер Багдад хәлифәтләре турында иде бу китап. 1730-1770 нче елларда язылган диюе хәтеремдә калды. «Кирәк икән авторын да әйтеп бирергә була, тик бераз эзләнергә кирәк», – диде галим, кулъязманы миңа кире биреп. Кулъязма Альберт Фәтхине бик шатландырыр дип уйлаган идек. Әмма галимнең китапка артык исе китмәде: «Моны нишләтәсез? Биредә калдырасызмы, әллә алып китәсезме? Безгә «Букинист» кибете аша тапшырырга була, үзегезгә дә бераз акча булыр», – ди. Без, әлбәттә: «Китапны турыдан-туры бирәбез», – дидек. Ничек инде галимне артык кызыксындырмаган, димәк, безнең кара акылыбызча, әллә ни фәнни кыйммәте дә булмаган китап өчен акча аласың?!

«

Шунда ук китапханә хуҗалары һәм хезмәткәрләре белән көн саен диярлек була торган низаглары турында сөйли башлады. Әйтүенчә, үзегенә бик үтәләр икән алар.

А.Фәтхи китапның алдарак бер битен ачты, анда минем Казандагы адресымны, кайдан табылуын язып, кулъязманы киштәгә куйды. Сөйләшеп киттек: үзенең Актаныш якларыннан икәнлеген әйтте, эше турында сөйләде. Аның иске китаплар бүлеге мөдире булып эшләвен аңладым. Өстәвенә, татар халкы тарихын да өйрәнә икән галим. «XII гасырга төшеп җиттем инде», – ди. Шунда ук китапханә хуҗалары һәм хезмәткәрләре белән көн саен диярлек була торган низаглары турында сөйли башлады. Әйтүенчә, үзегенә бик үтәләр икән алар. Галим төннәрен калып эшли, шуңа ачуланалар. Эшкә соңрак калып килсә, тагын сүгәләр, чөнки йокысы туймаган. «Бүлмәдә суык, җылыныр өчен чәй кайнаткан өчен дә сүгәләр, чәйнекне тартып алалар», – ди. Дөрес, акча һәм торак шартлары турында зарланмады галим. Сорагач

кына: «Күптән түгел генә эш хакымны 110 сумга күтәрделәр, КХТИ артындагы бер бүлмәдә яшим», – диде. Иң борчылганы шул: аның тарихи тикшеренүләрен, гомумән, яратмыйлар, шуның өчен дә бәйләнәләр, комачаулыйлар, фәнни эш алып барырга рөхсәт итмиләр, мәкаләләрен матбугатта бастырмыйлар икән. Аеруча китапханә директоры (урыс исем-фамилиясен атады) аны еш эзәрлекли. Җәйге ялында, үз хисабына чит өлкәләрдәге татар авылларына чыгып, борынгы китаплар җыеп йөргән, бу гамәле өчен бернинди дә «командировочный»лар алмавын әйтеп узды. Бераздан: «Эшләрем күп, кайтыгыз!» – дип, безне озатып җибәрде.

Икенче күрешү. «Һәр минутым татар халкы өчен бик кыйммәтле»

Бу очрашу миңа аеруча нык тәэсир итте. Нинди бәхетле кеше Альберт Фәтхи: эшенә ничек бирелгән, сихри-серле дөньяда… Балачагымнан ук китап яратканга: «Их, миңа да шулай яшисе иде», – дип кызыктым мин аңа. Үз янына эшкә алмасмы икән, мин аны әлеге усал кешеләрдән саклар идем, аларга каршы бергәләп көрәшер идек, аның кебек, дөньямны онытып, тарих өйрәнер идем дигән уйлар башымнан чыкмады. Бераз вакыттан соң мин әлеге хыяллар белән яңадан мәшһүр тарихчыга – Альберт әфәнде янына юнәлдем.

Сөйләшү шул ук бүлмәдә, китап белән тулы эш өстәле янында булды. Ялгышмасам, китапханәнең иң түрендә, тәрәзә каршында иде ул. Ниндидер хәйләләр белән «Ялкын» журналында басылган бер язмасын күрсәтте. Хәйлә белән чыгарган бер-ике мәкаләсе турында әйтте. «Урыслар татарча белми, шуңа аңламадылар», – диде. Мин аңа: «Нинди бәхетле кеше Сез, яраткан эшегез бар!» – дидем. «Әйе, бер яктан караганда, мин бик бәхетле, яраткан эшем-шөгылем бар. Ә икенче яктан, мин өйләнмәдем, берүзем генә яшим», – диде. «Үзегез янына эшкә алмассызмы икән?» – дигән гозеремә каршы: «Башка килеп йөрмә, эшләргә комачаулама, минем вакытым бик кадерле. Чөнки минем фәндәге һәр минутым татар халкы өчен бик кыйммәтле. Син үз юлыңда бул… Дөньяда минем кебек кешеләр дә бар икәнен белеп яшәсәң, сиңа шул бик җиткән!» – диде ул.

Өченче күрешү. «Бүлмәмдә үземә дә урын калмады»

Альберт Фәтхинең фидакярлеге, аның тормыш авырлыклары минем баштан чыкмый гына бит. Яз көне тагын аның янына киттем. Бу юлы мин аннан: «Берәр ярдәм кирәк түгелме?» – дип сорадым. Исәбем җәйге ялымда машинам белән авыллар буенча йөртеп, аңа борынгы китаплар җыярга булышу иде. Сорауга каршы ул: «Ярдәм бик кирәк, чөнки мин ел саен җәйге ялымда татар авылларына чыгып, борынгы китаплар җыеп йөрим. Китаплар күп җыелды, бүлмәмдә үземә дә урын калмады, ә монда куярга рөхсәт итмиләр, шуларны сакларга берәр урын таба алмыйсыңмы?» – дип сорады. Мин, бер машина китаптыр инде бу, дип уйладым да: «Урын тапкач, хәбәр итәрмен», – дидем. Ләкин урын тапмадым, дөресрәге, бер-ике урынны белештем дә, башка эзләмәдем. Югыйсә өч бүлмәле фатирымда да урын табылган булыр иде инде, ник шул турыда башка килмәгән икән дип уйлыйм хәзер. Шул күрешүдән соң без башка очрашмадык.

* * *

Берничә елдан соң мин, газетадан укып, галимнең мәрхүм булганын белдем. Фаҗигале үлем... Эссе җәй көнне бүлмәсендә үлеп яткан, кайчан үлгәнен дә белмәгәннәр аның. Соңыннан, әлеге китапларның шактые юкка чыккан икән, дигән хәбәрне дә укыдым. Ә китаплар күп булган: бер-ике машина! Кайда икән әлеге борынгы китаплар? Кемнәр кулына эләкте алар? Әрәм хезмәткә яки юкка газап чигүләргә генә кайтып калмадымы икән ул фидакярлек, кадерсез гомер? Менә шундый сораулар борчый мине.

Альберт абыйның: *«Мин диссертацияләр язып вакытны әрәм итеп маташмадым»,* – дигән сүзләре миңа аеруча нык тәэсир итте. Үзем дә шулай эшләдем, кандидатлыктан ары диссертация язмадым – вакытымны юкка әрәм итмәдем. Ә бәлки, фән һәм халкым өчен файдалырак булган һәм шул ук вакытта үзем яраткан эш белән шөгыльләндем, китапларымны татар телендә* һәм соңрак рус телендә бастыруга ирештем. Акчам булмады, дан-шөһрәт казанмадым.

Еллар узган саен, Альберт абыйны ешрак искә алам. Тормышымда күп галимнәр белән эшләргә һәм аралашырга туры килде. Кызганыч, чын хөрмәткә ия булган галимнәр бик аз. Соңгы вакытта бу өлкәдәге эшләр аеруча тискәре якка үзгәрде. Дәрәҗә артыннан куучылар яки, халыкча әйткәндә, «конфет кәгазьләре җыючылар» фәнгә, үтеп кенә түгел, бәреп керде. Фән кандидатлары белән дөнья тулды, әлеге «поплавок»ның дәрәҗәсе калмады. Шунлыктан бар «голәмә» «зуррак поплавок» – докторлык диссертациясе артыннан куа башлады. Күбесен «галим» дип әйтергә тел дә әйләнми. Юкны бар итеп яки кеше көче белән диссертация яклаучылар да байтак. Мәсәлән, әтиләре булышлыгыннан башка укырга да керергә сәләтсезләрнең кайберләре «профессор» булды, ә элеккеге намуслы галимнәр фән кандидаты дәрәҗәсеннән ары уза алмады. Дан, акча өчен намусын, фәнен сатканнар бүген дә танк кебек алдагы киртәләрне таптапсытып алга бара: аспирантлар тәрбияли, фәнни кыйммәте булмаган (ә бәлки, зыянлыдыр да) диссертацияләр әзерли, яшь галимнәрне алдарга өйрәтә. Шуның нәтиҗәсендә, илдә фәннең һәм галимнәрнең дәрәҗәләре нык төште. Ә Альберт Фәтхи кебек тугры, намуслы җаннар фән дөньясында бик сирәк калды... ■

> **«Тормышымда күп галимнәр белән эшләргә һәм аралашырга туры килде. Кызганыч, чын хөрмәткә ия булган галимнәр бик аз.**

Закиров Фоат Дәүли улы – галим-агроном, агулы үсемлекләр, үсемлекләр физиологиясе буенча белгеч, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты. Хәзерге вакытта Арча районының Кәче авылында яши, төбәк тарихын өйрәнә.

---

* «Агулы үсемлекләр: Татарстанда үсә торган агулы үсемлекләр һәм агулануларны кисәтү чаралары (фитотоксикология нигезләре)».

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

БИККОЛОВ ИБРАҺИМ (1884-1938)

Мәгърифәтче, татар халкының хокукларын яклаган милли көрәшче. Сембер губернасының Яңа Тинчәле (хәзерге Буа районына керә) авылында туган.

Булмаган «Солтангалиевчелек» оешмасы эшендә катнашуда гаепләнеп, кулга алына, ГУЛагта атып үтерелә.

БОХАРОВ СӘЛИМ (1916-1944)

Хәрби комиссар. Чын исем-фамилиясе – Галләнур Бохараев. Башкортстанның Кыргыз-Миякә авылында туган.

Дошман камалышында калып, әсирлеккә эләгә. Татар әсирләренең яшерен оешмасы әгъзасы.

Өченче Рейхның Империя суды Сәлим Бохаровны үлем җәзасына хөкем итә.

БИСЕРОВ ӘХМӘТ (1906-1970)

ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары. Таҗикстанда Ходжент шәһәрендә туган.

Ул Икенче бөтендөнья сугышында әсирлеккә эләгә, 1944 елда азат ителә.

Советлар Союзына кайткач, зинданга ябыла. Ун ел төрмәдә иза чиккәннән соң, 1955 елда аклана.

БИЛЯЛОВ РАФАЭЛЬ (1940-1999)

Татар композиторы. Казанда зыялылар гаиләсендә туган.

1999 елның 25 декабрендә билгесез кешеләр аны, фатирына бәреп кереп, үтереп чыгалар. Җинаятьчеләрне таба алмыйлар.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

БУБИ ГАБДУЛЛА (1871-1922)

Мөгаллим, фәлсәфәче, мәгърифәтче. Вятка губернасының Сарапул өязендәге Иж-Буби авылында мулла гаиләсендә туган.

Мөселман югары уку йорты булган Иж-Буби мәдрәсәсен жандармнар тармар китергәннән соң, Кытайга Колҗа шәһәренә күчеп китә. Анда да мәдрәсә ачып, татар һәм уйгыр балаларын укыта. Октябрь түнтәрелешеннән соң, Ватанына кайта. Ләкин анда да, хакимият тарафыннан якты чырай күрмичә, 1922 елда вафат була.

БУЛАТОВ ФУАТ (1913-1944)

Төзүче, хәрби мөһәндис.

Башкортстандагы Мәләвез авылында татар гаиләсендә туган.

Фашистлар камалышында калып, әсирлеккә эләгә. «Идел-Урал» исемле яшерен оешма әгъзасы. Өченче Рейхның Империя суды тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителә. Кабере билгесез.

БУБИ МӨХЛИСӘ (1869-1937)

Дин галиме, мөгаллимә. Русия мөселманнарының хатын-кызлардан беренче һәм соңгы казые. 1901 елда Мөхлисә абыстай татар кызларын укытыр өчен алты еллык кызлар мәдрәсәсе ача һәм үзе дә шунда мөгәллимлек итә.

Гаепсезгә кулга алына һәм 68 яшендә төрмәдә атып үтерелә. Кабере билгесез.

БУРНАШ ФӘТХИ (1898-1946)

Татар драматургы. Буа өязенең Батыр төбәгендәге Бикшик авылы мулласы гаиләсендә туган.

Гаепсезгә кулга алынып, Советлар Берлеге зинданында атып үтерелә.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Истә, һаман да истә!

Язучы Адлер Тимергалинның туунына 90 ел

Язучы-фантаст, тел һәм мәдәният тарихы белгече, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1981), Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби премия иясе (2006), 1975 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Адлер Камил улы Тимергалин 1931 елның 1 гыйнварында Татарстанның Сарман районындагы Иске Минзәләбаш авылында укытучы гаиләсендә туган.

А.Тимергалинның кайбер китаплары: «Ике хикәя, бер хыял» (1965), «Ерак планетада» (1967), «Кохау ронго-ронго» (1972), «Кайтыр юллар» (1981), «Кабул булсын теләгең» (1990), «Җиде юл чатында» (2003).

Язучы 2013 елның 16 гыйнварында вафат булды.

Композитор Нәҗип Җиһановның тууына 110 ел

Күренекле композитор, педагог, СССРның халык артисты (1957), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Каһарманы (1981) Нәҗип Гаяз улы Җиһанов 1911 елның 2 гыйнварында Җаек (Уральск, Казакъстан) каласында туган. Нәҗип ятимлектә үсә: аңа бер яшь чакта – әтисе, биш яшь тулганда, әнисе вафат була.

1938 елда ул «Качкын» дип исемләнгән беренче операсын яза.

1939-1977 нче елларда – Татарстан Композиторлар берлеге рәисе, 1945-1988 нче елларда Казан консерваториясе ректоры булып эшли.

Н.Җиһанов 1988 елның 2 июнендә Уфада вафат булды һәм Казандагы Арча зиратында җирләнде.

Артистка Фирдәвес Хәйруллинаның тууына 70 ел

Татарстан Республикасының халык (1995), Россия Федерациясенең атказанган артисты (2002) Фирдәвес Хәбибулла кызы Хәйруллина 1951 елның 4 гыйнварында Лаеш районының Агайбаш авылында туган.

Ул 1970 елда Казан театр училищесын тәмамлый һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында артист булып эшли башлый.

Ф.Хәйруллина башкарган кайбер рольләр: Мөршидә – «Мәхәббәтең чын булса» (Х.Вахит), Дания – «Илгизәр + Вера» (Т.Миңнуллин), Эсмеральда – «Зифа» (Н.Исәнбәт), Кәләш – «Кияү белән кәләш» (М.Байҗиев), Маһинур – «Миңлекамал» (М.Әмир), Гөлемхан – «Ахырзаман» (Ч.Айтматов), Мәрфуга – «Кишер басуы» (З.Хәким), Зөләйха – «Зөләйха» (Г.Исхакый), Саимә – «Әни килде» (Ш.Хөсәенов).

Ф.Хәйруллина 2003 елның 15 июлендә вафат булды.

Артист Габделфәрт Шәрәфиевнең туына 70 ел



Татарстан Республикасының атказанган (1989) һәм халык артисты (2011) Габделфәрт Әхәт улы Шәрәфиев 1951 елның 6 гыйнварында Кукмара районының Янил авылында туган.

Ул 1973 елда Ленинград театр институтының татар студиясен тәмамлый һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли башлый.

Г.Шәрәфиев башкарган кайбер рольләр: Мансур – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин), Гамир – «Китәм инде» (Р.Хәмид), Миргаян – «Кичер мине, әнкәй» (Р.Батулла), Базарбай – «Ахырзаман» (Ч.Айтматов), Хәйруллин – «Кишер басуы» (З.Хәким), Нугай би – «Идегәй» (Ю.Сафиуллин), Платон – «Баскетболист» (М.Гыйләҗев).

Г.Шәрәфиев 2014 елның 27 декабрендә вафат булды.

Галим Равил Әмирхановның туына 75 ел

Тарихчы-галим, тарих фәннәре докторы Равил Госман улы Әмирханов 1946 елның 9 гыйнварында Ульяновск өлкәсендәге Иске Кулаткы районының Иске Кулаткы авылында укытучы гаиләсендә ун баланың дүртенчесе булып туган.

Ул 1968-1971 нче елларда Балтач һәм Питрәч районнарында рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

Галим 1986-1995 нче елларда «Фатих Әмирхан турында истәлекләр» (Ф.Ибраһимова белән берлектә), мәшһүр тарихчы-галимнәр Ә.Вәлидинең «Кыскача төрек-татар тарихы», Р.Фәхреддиннең «Алтын Урда ханнары», «Казан ханнары» кебек әһәмиятле хезмәтләрен төзеп бастырып чыгарды.

Р.Әмирханов 2006 елда вафат булды.

Шагыйрь Илдус Гыйләҗевнең туына 75 ел

Шагыйрь, Татарстан Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби премиясе иясе, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, 1990 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Илдус Сабир улы Гыйләҗев 1946 елның 15 гыйнварында Азнакай районының Урсай авылында туган.

Төп басма китаплары:

«Җир китабы» (Мөхәммәт Мәһдиевнең кереш сүзе белән, 1988), «Җилкенү» (1990), «Өмет ае» (1993), «Серле мәгарә» (1995), «Хак сүз» (Фәнзаман Батталның кереш сүзе белән, 2000), «Чатыртау тылсымы» (Нур Әхмәдиевнең кереш сүзе белән, 2001) «Яратканга күрә» (2006) һ.б.

И.Гыйләҗев 2018 елның 19 мартында вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Туйкә авылы (Азнакай) зиратында җирләнде. ■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Яһүдләрчә

Раил Садриев

Күптән түгел Камал театрында түгәрәк өстәл артында татар театрлары директорлары җыелды һәм алар, шактый гына бәхәскә кереп, зур-зур проблемаларны күтәрделәр. Һәрбер театрның бүгенге тормыш-көнкүрешкә, театрларның бүгенге юнәлешенә, яшәешенә үзенең карашы бар. Камал театры, академия театры буларак, үз күзлегеннән фикер йөртә, шәһәр театрлары үзләренчә әйтәләр. Безнең театр кебек район үзәгендә урнашкан театрлар үзләренең проблемаларын яңгыраттылар. Әлбәттә, төрле-төрле фикерләр булды. Шулар арасыннан иң мөһиме – телне, тамашачыны ничек саклап калырга? «Татар эстрадасы татар театрына көндәшме, дусмы?» – дигән фикер дә алга сөрелде. Язмамны да шуннан башлап җибәрәсем килә. Бу сүзләрне ишеткәч, бераз гына аянычрак булып китте, чөнки мин, эстрадада сәхнәгә чыккан кеше буларак, татар тамашачысын төрле катламнан тора дип саныйм. Кемдер классик музыка ярата, кемдер джаз, кемдер рок, кемдер Шаһиморатовага, кемдер Тямаевка мөкиббән китә. Бу фикерем эстраданы яклаудан гына түгел. Бүген татарның, милләтебезнең сагында аның мәнфәгатьләрен яклап яшәүче өч нәрсә бар, хәтта дүрт тә. Дүртенчесе турында соңрак аерым әйтәсе килә. Аның беренчесе – театр, икенчесе – эстрада, өченчесе – татар әдәбияты һәм дә инде дүртенчесе, мин соңрак әйтәм дигәне ул – гаилә. Гаиләдә инде күптән татарча сөйләшмиләр, чөнки бүген глобаль интернет, телевизор, «Маша и Медведь» кебек мультфильмнар, балалар бакчасы,

мәктәп аша безнең телгә янаган процесслар кереп бара. Хәзер Актаныштагы татар авылларында да, Буадагымы ул, Чүпрәледәгеме, Матактагымы – һәр кечкенә бала, хәтта балалар бакчасындагылары да – барысы да урысча сөйләшә, урысча фикер йөртә, урысча аңлый, урысча аралаша. Бу – телебезне, милләт дигән агачны төбеннән кисү процедураларының берсе. Без күпчелек халыкны, авылда эш бетү сәбәпле, соңгы утыз ел эчендә мегаполисларга күчердек, шулай ук аянычлы 90 нчы елларның шаукымы да гаиләдә татарча сөйләшүгә, татарча фикерләүгә аяк чалды.

Император Александр III: «Россиянең ике генә союзнигы бар: ул – армия һәм флот», – дип әйтеп калдырган. Кабатлап басым ясап әйтәм: бүген татар милләтенең дүрт кенә дусты бар. Аның берсе – театр, икенчесе – эстрада, өченчесе – әдәбият һәм инде дүртенчесе, иң көчлесе, иң кирәге, иң аянычлысы ул – гаилә. Менә бу өчесендә әле татар теле ничектер яши, аның кануннары саклана, ә гаиләдә беркем дә бернәрсә дә әйтеп киртәләр куя алмый, шуңа күрә бүген гаиләләр, үзләре дә моны аңламыйча, безне милләт буларак югалуга-юкка чыгаруга алып баралар. Моннан чыгып нәрсә әйтәсе килә: әлбәттә, без хәзер бу дүрт дустыбызны саклауга бөтен көчебезне куярга тиешбез. Аларны үстерү, саклау өстендә эшләр өчен нинди ресурслар, чыганаклар бар, шуларның барысын да табып, кирәкле юлга юнәлтергә тиеш булачакбыз.

Моңа таянып, шул әңгәмәдә булган тагын икенче бер мәсьәләгә күчәсем килә. Мине милләтче, шовинист, сионист, семит дип уйламагыз. Бу өстәл артында шундый тәкъдим керттем: әйдәгез, бүгенге аяныч заманда яһүдләр шикелле булыйк, алардан үрнәк алыйк.

Моңа мине нәрсә этәрде соң? Әле кайткач та берничә көн уйланып йөрдем, уйлануымны хәзер дә дәвам итәм. Моңа кадәр миңа Санкт-Петербургта «Радуга» халыкара театр фестивале кысаларында соңгы көндә оештырылган конференциядә катнашырга, спикер буларак чыгыш ясарга туры килде. Аның темасы: «Театр-2020: яшәү яки исән калумы?» («Театр-2020: жизнь или выживание?»). Ә без, татар театры директорлары, башка ваграк проблемаларны алга сөреп, төп сорауларга басым ясарга оныттык кебек.

Бүген глобаль үзгәрешләр вакытында безгә глобаль уйлый башларга өйрәнергә вакыт, җәмәгать! Әгәр дә без моны эшләмибез икән, киләчәгебез өметсез. Бу куркудан әйтү түгел, мин үземне иң оптимист кешеләрнең берсе дип саныйм. Шуңа да карамастан, икенче төрле әйткәндә, яһүдләр шикелле яшәргә өйрәнергә кирәк. Ничек соң ул яһүдләрчә яшәү? Ничә мең еллар буе кыйналып, куылып йөргән яһүдләр, Җир шары буенча таралып, бөтен илләрнең тарихларында урын алып, үзләрен милләт буларак саклап кала алдылар. Менә шундый заманда, үзебезне саклап калыр өчен, әлеге тәкъдимне керттем дә инде. Аларны, өйрәнү чыганагы буларак, үрнәк итеп кулланырга кирәк. Без, татарлар, театрны уйлап чыгарган халык түгел, тальян гармун да безнеке түгел, ул итальяннныкы, Италиядән килгән гармун.

Бу нисбәттән, беренче тетрәнүем Казанның меңьеллыгында Петербург урамы башына Лев Николаевич Гумилевка һәйкәл куелгач булды. Шатлыгымнан нишләргә белмәдем ул вакытта! Тарих факультетын бетергән, Мөсәгыйт абый Хәбибуллинның романнарын, китапларын укыган һәм Лев Гумилев турында аның сөйләүләрен тыңлаган кеше буларак, канында бөек татар халкының коды булган шушы бөек шәхескә һәйкәл күреп куандым. Хәтерлим әле: театр артистларын Камал театрына алып килгәч, аларны җәяү шушы һәйкәлгә җибәрдем. «Хәзер барыгыз да Казан уртасында, кендегендә кемгә һәйкәл куелганын карагыз һәм кире килгәндә Тукайга кадәр адымны санагыз», – дидем. Әйләнеп килгәч, болардан: «Кемгә һәйкәл?» – дип сорыйм. «Ниндидер Лев Николаевич Гумилевка», – диләр. Ниндидер Лев Николаевич Гумилев! «Кем соң ул Лев Николаевич Гумилев?» – дим. Белмиләр. «Ничек белмисез инде? Үзе Лев, үзе Николаевич, үзе Гуми-

лев». Аңламыйча, миңа карап торалар. «Лев булгач, яһүдтер инде ул, Николай булгач, урыстыр, – дим. – Гумилев булгач, аңлашылмый әле. Кем икәнен аңлап бетермибез. Ул – Анна Ахматованың улы». Татар фамилиясен, Анна Ахматова сүзен ишеткәч, безнең берике артистыбыз (укыган булганнар, күрәсең): «Ул шул шагыйрәнең улымы инде?» – ди. «Әйе. Ул – шагыйрәнең улы гына түгел, ә канында аз булса да татар элементлары булган язучы, галим дә. «Я всю жизнь защищаю татар от клеветы», – дип әйтелгән алтын сүзләре бар Гумилевның. Татарны шул пычраклыктан арындырып, аның тарихын саклап, барлап язып калдырган олпат кешеләрнең берсе. Ул – татарның адвокаты. Аның пассионарлык буенча һәрбер хезмәте безнең халыкның зурлыгын, бөеклеген күрсәтә. «Древняя Русь и Великая Степь» хезмәтенең нигезендә Киев Русеның чикләреннән алып Татар култыгына кадәр булган мәйданда Русия дәүләтен барлыкка китергән һәм аның төп халкына әверелгән безнең бабаларыбызның, безнең халыкның тарихы ята. Шуңа да без төрле. Наполеонның шундый сүзе бар: «Урысны кырсаң, татар чыга» (Поскребешь русского – найдешь татарина). Дөрес, бу сүзләрнең авторы төгәл билгеле түгел, аны Ленинга да, Пушкинга да сылтыйлар. Ничек кенә булмасын, бүген Россиядә яшәүче халыкта татар каны ага, чөнки ул шушы бөек далада яшәгән. Киевская Русь ул чын мәгънәсендә урыслар яши торган бер кечкенә генә учак булып калган. Һәм шул учак Украина, Белоруссия, өлешчә Россия дәүләтләрен барлыкка китергән. Менә шулай. Без кушылган халык, ул төрле: кайсыбызның күзе кысык, кайсыбыздыр җирән чәчле, сипкелле, кайсыбыздыр кара, кайсыбыздыр ак, сарырак. Әгәр дә безнең халыкны, фотога төшереп, аноним рәвештә: «Бу фотода нинди милләт халыклары җыелган?» – дигән сорау белән дөньякүләм танылган уку үзәкләренең (Сорбонна, Кембридж) антропология бүлекләренә җибәрсәләр, минемчә, без дөрес җавап ала алмаячакбыз. Шуңа да без җыелган һәм бөек халык! Менә Лев Николаевич Гумилев яһүд кешесе, ягъни татар канлы яһүд баласы, безнең тарихка кагылышлы шундый фикерләр әйтеп, безнең тарихыбызны барлап калдырганга, килеп чыгышыбызны, безнең пассионарлыгыбызны аңлатып бирә алганга, аның урыны да Казан түрендә. Ә Тукай читтәрәк тора. Шуннан соң артистлардан сорыйм: «Ә Тукай ник читтә?» «Кабан күле белән Болак тоташкан җирдә, матур урынга куярга теләгәннәрдер», – диючеләр булды. Ә бит Казанның менә шушы Гумилев һәйкәленә каршы яктагы үзәк урамы да яһүд кешесе Николай Эрнестович Бауман исемен йөртә. Миндә сорау туа: әлеге революционер Бауман татар тарихы, татарның, Татарстанның бөеклеге өчен нәрсә эшләгән? Ул нефть тапканмы, татарның тарихын язганмы, йә булмаса, Татарстан Республикасын төзүдә катнашканмы, яки, Гумилев шикелле, зур-зур трактатлар язганмы? Бу сорауга әле дә җавап юк. Моны шундый сиземләү белән әйтәм: киләчәктә бу урам татарны дәүләтле иткән һәм дөньяга таныткан, аның бүгенге яшәешенә зур импульс биргән шәхеснең исеме белән аталачак…

«Миндә сорау туа: әлеге революционер Бауман татар тарихы, татарның, Татарстанның бөеклеге өчен нәрсә эшләгән? Ул нефть тапканмы, татарның тарихын язганмы, йә булмаса, Татарстан Республикасын төзүдә катнашканмы, яки, Гумилев шикелле, зур-зур трактатлар язганмы? Бу сорауга әле дә җавап юк.

Һәм яңадан шул яһүдләргә әйләнеп кайтасым килә. Бүгенге театр сәнгате дә яһүдләр тудырган әйбер ул. Минем белән хәзер килешмәскә, ул башка җирдә килеп чыккан, Борынгы Грециядә, Римда, Англиядә булган дияргә тырышучылар, каршы төшүчеләр булыр, тик, күзәтүем буенча, бүгенге дөньяда барлык театрларны диярлек, андагы булган процессларны – фестивальләрне, лабораторияләрне күпчелек очракта яһүдләр җитәкли.

Минем күзлектән караганда, Питердагы конференция белән Казандагы түгәрәк өстәлдәге сорауларның әллә ни аермасы да юк кебек. Берсе – шушы авыр заман капкасы төбендә басып торганда, глобаль кризиска кереп барганда, әлеге шартларда театрларны сәнгать буларак ничек саклап калырга, булса, икенчесендә безнең өстәл артындагы әңгәмәләр нindiдер көндәлек вак-төяк проблемаларга гына кайтып калды. Ә бит безгә милли театрга, эстрадага, әдәбиятка кагылышлы проблемаларны зурдан күтәрергә, аны даими һәм җитәрлек рәвештә финанслауны булдырырга, шушы институцияләрне милләтне саклап кала торган иң төп чыганакларга әверелдерергә кирәк! Шуның өчен бездән яһүдләр кебек глобаль фикер йөртү сорала.

Әйе, бүген иң мөһим нәрсәләрнең берсе – татарча фикерләү, татарча уйлау, татарча җырлау, уйнау, татарча язу, татарча яшәү. Шул нисбәттән татар эстрадасы да татар театрына беркайчан да көндәш була алмый, ә киресенчә, алар бер-берсенә терәк кенә. Минтимер Шәрипович, аның исеменә «Барс-Рекордс» компаниясе өстеннән: «Алар биш йөзгә якын артистны сәхнәгә чыгардылар, җырлары да, киемнәре дә татарныкына охшамаган, безнең милләткә тап төшерәләр, зәвыгын бетерәләр», – кебегрәк эчтәлекле шикаять килгәч, болай җавап биргән дип сөйлиләр: «Аның бит иң мөһиме шул: алар татарча җырлыйлар». Чыннан да шулай бит, татар эстрадасы нигезендә татарча җырлау, татарча сөйләшү, татарча фикерләү, татарча уйнау, татар булу ята.

Татар эстрадасының бүгенге хәле бик аяныч. Без, дәүләт театрлары турында дәүләт ничек тә булса кайгырта әле, ә эстрададагылар бүген үз ипиләрен үзләре табып ашарга мәҗбүр. Әйе, соңгы елларда эстрада артистлары күбәеп киткән шикелле тоелса да, минемчә, яңа шартларда, кинәт кенә саегып, юкка чыгарга да мөмкин. Бары тик мегапопуляр артистлар гына үзләрен сәхнәдә саклап кала алачаклар. ***Без барыбыз да бүген бер дисбедә: әдәбият та, эстрада да, театр да.*** Барыбыз да, беренче чиратта, Татарстан хөкүмәте ярдәменә мохтаҗ, чөнки ***без, телнең, милләтнең, татарның төп сакчылары буларак, «яу» кырында алдынгы флангада.*** Нишлибез?! Безгә глобаль фикер йөртергә өйрәнә башларга, мондый югалту һәм югалу юлын үтеп, исән калган милләтләр (яһүдләр) тәҗрибәсен өйрәнергә, татарның чын терәге, дусты булган өч юнәлешне, бернәрсәгә дә карамыйча, даими финансларга, аларга ярдәм итәргә кирәк. Шушы юнәлешләрнең берсен генә югалтсак та, без инде тулы канлы милләт булып яшәүне дәвам итә алмаячакбыз. Шуның өчен, җәмәгать, кабатлап әйтәсем килә: ***безгә яһүдләрчә киң итеп, зурдан кубып, зирәк акыл белән уйларга һәм курыкмыйча фикер йөртергә өйрәнергә кирәк.*** Курыкмыйча!

Курку – тезген, аяктагы тышау,
Муендагы элмәк шикелле,
Әйтер сүзләреңне әйттерми ул,
Эшләттерми эшләр эшеңне.
Ахыр чиктә адәм балаларын
Колга әйләндерә куркаклык.
Шул коллыкка эләкмәскә, дисәң,
Курыкмаска кирәк бер тапкыр.

(Әнгам Атнабаев) ■

ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ. КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

*Татарстанның халык артисты **Фердинанд Сәлаховның** балачак, яшьлек, шәхес булып формалашу чорлары истәлекләрен тыңлау – детектив роман уку белән бер. Озак еллар белгән, 8 ел бергә эшләгән җырчының кайбер тарихларын әле яңа гына ишетеп, тел шартлатып тыңладым. Мәскәүгә метро төзелешенә киткән әти-әнисе кире авылларына кайтып урнашкач та, ул Мәскәүдә, әтисенең сеңлесендә калган, аны 7 яшендә генә авылларына кайтучы бер хатынга ияртеп кайтарып җибәргәннәр икән. Кайтканда бер авыз сүз татарча белмәгән, шуңа мәктәпкә дә кермәгән. 1 сыйныфка 9 яшендә – татарча өйрәнгәч кенә кергән ул. Кайчандыр тире эшкәртү белән шөгыльләнгән, шунлыктан, хәлләләр рәтендә булган бабаларының бөлү тарихын, әтисенең сәвитләргә каршы булуы сәбәпле, атна саен районга чакыртылып торуын һәм шул чорда күрше авылдагы җитәкче дустын сәбәпсез юк иткәч, алар золымыннан киткәнче, дип, үзенә кул салганлыгын тыңласаң, чәчләр үрә торырлык.*

Армия сафларына Казаннан, Медицина институтында укыган чагында алына ул. Дөресрәге, военкоматка барып, үзе: «Мине армиягә алыгыз», – дип сорый. Нәтиҗәдә, СССР эчке гаскәрләренең «Чиләбе-70» полигонына эләгә. Аны штабка билгелиләр. «Чибәркүл янында хезмәт иттем. Янына барырга рөхсәт ителсә дә, коенырга ярамый иде. И йөзә тегендә тәкә башы кадәр балыклар, тирәсендә алма зурлыгы җир җиләкләре. Ашарга ярамый. Бары да радиация белән «өлгергәннәр». 1975 ел, июль.

Фердинанд Сәлаховның «Язгы гөлләр сезгә» дип аталган беренче мөстәкыйль концерты 1986 елның 8 мартында Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында аншлаг белән уза. «Ул концерт өчен мин заманына күрә коточкыч зур акча – 250 сум алдым», – ди Фердинанд.

«Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исемне Ульяновск өлкәсендә узган Татарстан мәдәнияте көннәреннән соң бирделәр. Республикабызның сәнгать осталары катнашында узган концертта мин «Эскадрон» дигән башкорт халык җырын башкардым. Фотода – Минтимер Шәрипович Шәймиев кулыннан мактаулы исемнең документларын алган мизгел». 1993 ел.

«Гаиләм – хатыным Раилә, улларым Марат, Руслан һәм мин». 1995 ел.

P.S. Җырчы күңеле – авырлыкларын, кайгы-хәсрәтләрен, сынауларын моңга әверелдереп, кешеләр күңеленә дәва итеп таратучы кыл ул.

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

«Туган тел» җыры



«Кечкенәдән үк күңелемдә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю тугъды. Әгәр миңа җырулар ярдәм итмәсә, мин соң сарт «Бәдәвам»нәре, сарт «Кисекбаш»лары, кызылбаш «Тасриф»ләре, гарәп «Нәхү»ләре белән туган телемезне сөймәк кеби олуг бер нигъмәткә ия була алыр идеммени?..

...Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу – кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмур Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә һәртөрле бәлая вә казаядан, муллалар әйтмешли, мәсун вә мәхфүз уларак калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле.

Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска иҗтиһат итәргә кирәк.

Белергә кирәк ки, халык җырлары – халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер».

Габдулла Тукай

Туган тел

(Татар халык көе, Габдулла Тукай сүзләре)

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Мәгълүм шигырь
һәм җыр турында аз-маз тарих



١٣

طوغان تل

ای طوغان تل، ای ماطور تل، ئەتكەم ئەنكەمنڭ تلی!
دنیادە كوب نرسە بلدم، سین طوغان تل آرقلی.

ایڭ ئلك بو تل بلەن ئەنكەم بیشكدە كویلگان،
آننارى تونلر بويى ئەبكەم حكايت سويلگان.

ای طوغان تل! هر وقتدە یاردمڭ برلن سینڭ
كچكنەدن آڭلاشلغان، شادلغم، قایغم مینم.

ای طوغان تل! سیندە بولغان ایڭ ئلك قیلغان دعام:
«یارلقاغل دیب اوزم هم ئەتكەم، ئەنكەمنی خدام».

Тукайның «Туган тел» шигыре «Балалар күңеле»нең 1 нче (1909) һәм 2 нче (1911) басмаларында дөнья күргән. Икенче басмада алтынчы юлдагы «тышка чыккан» сүзләре «аңлашылган»га алмаштырылган.

«Балалар күңеле» исемле җыентыгына бирелгән бәяләмәсендә Кәбир Бәкер Тукайның әлеге шигыре турында: *«Туган тел» балалар рухына бик якын һәм бик муаффәкыятьле бер рәвештә язылган», – дип искәртә («Йолдыз». – 1910 ел. – 19 гыйнвар.).*

Фатих Сәйфи-Казанлы тарафыннан төзелгән өчтомлыкның 2 нче томында (1930) әлеге шигырьнең кульъязмасы турында мондый аңлатма бирелә: *«Татар мәдәният йорты янындагы китап палатасында Г.Тукайның ике кульъязмасы саклана. Бу кульъязмада Тукай үз шигырьләренең тарихын күрсәтеп барган. Киләчәк искәрмәләрдә «кульъязма» дип әйтелсә, шунда саклана торган кульъязма дип белергә кирәк».*

Хәзерге вакытта бу кульъязмаларның язмышы билгесез.

Инкыйлабка кадәрге чорда «Туган тел» җырын мәктәп-мәдрәсәләрдә уку елы башлану алдыннан, уку елы тәмамланган вакытта, шулай ук бәйрәм кичәләрендә балалар хор белән укый яки көйли-җырлый торган булганнар.

Тукайның совет заманында чыккан күп кенә җыентыкларында шигырьнең дини эчтәлектәге соңгы строфасы төшереп калдырылган.

Шагыйрь үзенең «Халык әдәбияты» дигән лекциясен (1910) әлеге шигыре белән тәмамлый.

(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан күзгә» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.) ■

Көлке куа килә...

Илдус Гыйләҗев (1946-2018)

Һәр халыкның үз холкы

Инглизләр – саран халык,
Төпле, төгәл – алманнар.
Испаннарның холкы кырыс,
Иң үҗәте – албаннар.
Французлар – гыйшык колы,
Гарәп ягы – диниләр.
Кытайлылар үрчи белә,
Япун ялкау, димиләр.
Африканнар кайнар, кыдрач,
Урыс бераз гадәтсез.
Ә татарлар артык тыйнак,
Шуңа илсез-дәүләтсез...

Илдус Гыйләҗев.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Туфан Миңнуллин.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Тоттылар...
(Хәрби хикәя)

– Шушында гына булырга тиеш, – диде армия генералы.

– Тегендә булуы да ихтимал, – диде генерал-полковник.

«Армияне әзерлектә тотарга!» – дигән приказ бирелде. Йөз мең офицер һәм солдат, бронетранспортерларга төялеп, һөҗүмгә күчте. Аларга самолетлар һәм вертолетлар кушылды. Туплар залпы яңгырады, миналар шартлады, ядрәләр чәчелде. Приказ арты приказ бирелде.

Операция уңышлы үтте. Ниһаять, тотыласы кешене тоттылар. Аның буе – 1 метр да 50 сантиметр, авырлыгы 48 кило ярым иде.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2021

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

«Бәтиев һәм...»

Авыл советы рәисе дигәч, күрше Балтач районында булган кечкенә вакыйга күңелгә килде.

Совет заманында Куныр авыл советы рәисе Гыйльмулла Дәүләтшинны Мәскәүгә – СССР күләмендәге бик тә җаваплы киңәшмәгә җибәрәләр. Зур горурлык хисләре белән кузгала ул олы юлга. Кайткач та, бик һавалы йөри. Сирәк-мирәк кенә, кәефе күтәренке вакытта, әлбәттә, истәлекләре белән уртаклаша. Ул мәңге онытылмас хатирәләрен, гадәттә, болайрак башлый:

– Шулай бер кичне мин, Бәтиев (сүз 1960-1983 нче елларда Татарстан АССР Югары Советы Президиумы рәисе булган Салих Гыйлемхан улы Батыев турында бара), калган берничә вак-төяк авыл советы рәисе ресторанда утырабыз шулай...

Илдар Юзеев (1933-2004)

Ике эпиграмма

Зөфәр Хәйретдиновка

Көен дә үзе чыгара,
Үзе җырлый – комбайн:
Үзе ура, үзе суга, –
Ул баемый кем баер?

Зәйнәп Фәрхетдиновага

«Әче-әче, диләр...»

Марҗа белән туйда
Күрешәсе килә,
«Әче! Әче!» – диеп,
Үбешәсе килә!

2002

Фаил Шәфигуллин (1939-1982)

Тәүбә

(Каләмдәш дусларыма ачык хат)

Хөрмәтле иптәшләр, кадерле каләмдәш туганнарым! Беләм, сезнең каршыгызда бик тә гаеплемен. Бары бернәрсә генә әйтә алам: мин бит аны зур акылым белән түгел, ә чын күңелемнән эшләгән идем.

Ничектер шулай туган якларга кайтып төштем. Яңа аерткан каймак эчкәннән соң, бер повесть язып ташладым. Укып чыкканнан соң, үзем дә шүрләп куйдым, коточкыч шәп чыккан бит бу! Журналда да башта икеләнеп калдылар, шулай да бастырып чыгардылар.

Менә шуннан соң башланды инде хәлләр! Укучылар яза, тәнкыйтьчеләр мактый, күршеләрем горурлана, ә язучылар... миннән бөтенләй йөз чөермәсенме!.. Мин башта үпкәләп тә куйдым, соңыннан гына барып житте – мин хаклы түгел! Уйлап кына кара, әле генә каләм очлаган кеше, нахалланып, исемле зур язучыларның иҗади биленнән түбән бәрсен әле!

(«Тынгысыз каләм», 1981) ■

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.*

ДЕКАБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында



● Декабрь башында Туфан Миңнуллинның (1935-2012) робагыйлардан гына торган тупланмасы рус телендә (тәрҗемәче – Рауза Хуҗахмәтова) китап булып дөнья күрде. Китапның рәссамы – Рената Галиуллина.

● 9 декабрьдә ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984), ТАССРның халык артисты (1991), җырчы Рафаэль Ильясов (1939 елның 28 апрелендә туган) сиксән бер яшендә вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Казанның Мөселман зиратында җирләнде.

● Декабрь аенда Кыргызстанда дөньякүләм танылган язучы Чыңгыз Айтматовның (1928-2008) тууына 92 ел тулуга багышланган чаралар узды. Әдипнең якын дуслары, туганнары һәм иҗатын хөрмәт итүчеләр язучының «Аталар кабере» мемориаль комплексындагы каберенә чәчәкләр салды. Шулай ук Чыңгыз Айтматов исемендәге кино йортында «Айтматов дөньясы» дигән документаль фильм күрсәтелде.

● Декабрьдә төрек халык мәзәкләре тупланган китап (төзүче-автор – Фирдүс Дәүбаш) басылып чыкты.

● 13 декабрьдә Татарстанның халык һәм (2001) Россиянең атказанган артисты (2014) Айдар Садри улы Хафизов (1943 елның 20 маенда туган) вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде туган ягында – Питрәч районының Күн авылында җирләнде.

● 14 декабрьдә Татарстан мөселманнары диния нәзарәтендә Казыйлар шурасының чираттагы утырышында Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев кеше исеме гарәпчә, татарча, фарсыча, төрекчә уңай мәгънәгә ия булырга тиешлеген искәртеп үтте һәм көн тәртибендәге мөһим мәсьәләләрнең берсенә – яңартылган татар исемнәре китабын әзерләп бастыруның мөһимлегенә аеруча басым ясады.

● 17 декабрьдә ТР Дәүләт Советы Рәисенең урынбасары Марат Әхмәтов Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, «Казан утлары» журналы мөхәррире, язучы Камил Әдһәм улы Кәримовка

Татарстан Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хатын тапшырды. Әдипне шулай ук Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров исеменнән Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фондының башкарма директоры Нурия Һашимова да котлады.

● 18 декабрьдә Татарстан мөселманнары диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесенең урынбасары Михаил Мишин белән очрашты. Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган әлеге чарада ТР Президентының Эчке сәясәт буенча департаментының милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы Данил Мостафин, ТР Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаментының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Альберт Дирзизов, ТР МДН аппараты җитәкчесе Ирек Арсланов, «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин катнашты.

● 18 декабрьдә Казан Кремлендә узган киңәшмәдә Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев: «ТАССРның 100 еллыгын билгеләп үтү елында бик күп эш башкарылды», – дип бәя бирде. Ул шулай ук Болгар һәм Зөяне торгызу буенча саллы эш башкарылганын да искәртте: «Соңгы дистә елда нинди бөек эшләр эшләгәнебезне әле аңлап та бетерә алмыйбыз: халкыбызның мәдәни мирасын торгыза алдык. Бу күптәнге хыял иде...» Дәүләт Киңәшчесе Казан Кремле, Болгар һәм Зөя ЮНЕСКО тарафыннан танылып, Бөтендөнья мирасы һәйкәлләре исемлегенә кертелүен зур казаныш дип атады.

● 18 декабрьдә «Безнең мирас»журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, басмага яңа материаллар туплау нияте белән Әтнә районында булып, хакимият башлыгы Габделәхәт Хәкимов белән очрашты. Ул шулай ук Әтнә дәүләт драма театры (директоры – Ленур Зәйнуллин, баш режиссеры – Рамил Фазлыев) коллективы һәм «Сәхнәдәш» балалар театрының (җитәкчесе – Финә Сафиуллина) яшь талантлары белән дә очрашулар уздырды. Кичен исә баш мөхәррир шагыйрә Гөлүсә Батталова пьесасы буенча куелган «Җомга базары» спектаклен карады.

● 18 декабрьдә Татарстанның халык артисты (1985), С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры артисткасы (1959 елдан) Илүсә Әхмәт кызы Бәдриева (1940 елның 19 декабрендә туган) вафат булды.

● 21 декабрьдә башкалабыз Казанның Ш.Мәрҗани мәчетендә бер төркем зыялыларыбыз шул айда вафат булган күренекле артист Айдар Садри улы Хафизовны искә алды.

● Декабрьдә Чуашстан татар милли-мәдәни мохтариятен вафатына тикле җитәкләгән, татар җыры һәм фольклоры фестивальләренә, төбәктәге фольклор ансамбленә нигез салган, Чуашстанның һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фәрит Гыйбатдинов (1959-2020) турында китап (төзүче-автор – журналист Рафис Җәмдихан) дөнья күрде. ■

МИРАСВОРД

Язучы Мин ...

Язучы Госман ..., композитор Әнвәр ...

... Сиражи (башкорт шагыйре)

Намазда: башны җиргә ору хәрәкәте

Дан, дәрәҗә (иск.)

Борынгы Грециядә һәм Римда: киләчәк турында хәбәр итүче жрец

Кимлек, җитешмәүчәнлек (иск.)

... Бәдигый

Алман микробиологы

Алтын Урда каласы

Зур, киң, тупас, калын киндер яки брезент җәймә (диал.)

Балтач районындагы авыл

Борынгы грекларда: халык җыелышы

Пар двигателе уйлап тапкан инглиз инженеры

Тель-...

Артист ... Нуруллин, шахматчы ... Камский

Борынгы грекларда исәпләү тактасы

Язучы ... Галәү, шагыйрь ... Хөсәен

Пәйгамбәр

Борынгы әйберләр саклана торган бина

1917 елда Казанда Шәһит Әхмәдиев чыгарган газета

«Диване лөгатет-төрк» әсәре авторы

Немец ханымы

Зур хәрби флот

Композитор ... Мөлеков

... Нәҗми

Көн акча янчыгы (иск.)

Элек авылда тимерченең эш урыны

Киемнең эчке ягына тегелгән тукыма

Җәлилче Гайнан ...

Ашарга яраклы үлән

... Байҗиев (кыргыз әдибе)

Аркылы сырлары булган ефәк яки йон тукыма

Иртышның сул кушылдыгы

Композитор ... Гатауллин

Ярдәмче фигыль

«... дисбесенең сере» (Нурихан Фәттах)

Америка язучысы, «Эстер», «Демократия» романнары авторы

Мифик зат, гном

Рәис Габдулла төзеде.

12 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: сыбай, ур, ләим, галл, Сәйф, тияк, Каюм, «Илдар», Арпаяз, Нәби, коба, Нерон, Шәвәли, Ван, хәя, өяз, Сунчәләй, лорд, Әзәл, сәрви, «Ника», алка, юха.
Өстән аска: Ка, төмән, Саркел, зир, Әюп, Үзбәк, Сөләйманов, лар, Наис, бриг, иза, аума, Ян, кәпәч, «Саз», Солтанов, хәләл, ирәбә, Лорка, «Бала», әрвах, кси, Әйди.

«Безнең мирас»

елъязмасы / гыйнвар

Казандагы Борнай мәчете. Иске татар бистәсендәге әлеге мәчет 1872 елда сәүдәгәр М.К.Борнаев акчасына салына. Проект авторы – П.И.Романов.

195 ел элек (1826)

20 гыйнварда комач фабрикасы, тире һәм сабын заводлары хуҗасы, Казан Шәһәр Думасы гласные (1871-1898) Мөхәммәтсадыйк Корбангали улы Борнаев (1826-1898) туган.

150 ел элек (1871)

6 гыйнварда Каюм Насыйри төзегән еллык календарьның беренче саны басылып чыга.

135 ел элек (1886)

Татар әдәбияты классигы – прозаик, драматург, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан (Мөхәммәтфатих Зариф улы Әмирханов (1886-1926) туган.

125 ел элек (1896)

Казанда «Камско-Волжский край» («Кама-Идел төбәге») газетасының беренче саны чыга. Беренче нашире һәм мөхәррире – Н.А.Фирсов.

115 ел элек (1906)

15 гыйнварда Казанда шәһәр китапханәсенең мөселман филиалы – беренче җәмәгать китапханәсе «Китапханәи Исламия» (1906-1929) ачыла. Ул бертуган Мөхәммәтҗан, Шәрифҗан һәм Хәсән Кәримовлар йортында урнаша.

100 ел элек (1921)

25 гыйнварда Беренче Бөтентатар халык хуҗалыгы хезмәткәрләре съездында Татарстанны электрофикацияләү планын әзерләү турында резолюция кабул ителә.

95 ел элек (1926)

Рәсми статистика мәгълүматларына караганда, шул елның 1 гыйнварына Татарстанда 2 942 875 кеше яши.

70 ел элек (1951)

4 гыйнварда рәссам, сәнгать остасы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Шамил Габдрахман улы Нигъмәтуллин (1951-2004) туган. ■

Журналга ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.*

Содержание. Январь 2021

И останется в мире слово моё...: Гумер Баширов.

Историческое наследие: «Половцы»; «Созвездие Шамсуар». Ф.Байрамова; «Издательства, выпускающие татарские книги за пределами Казани». Р.Марданов, И.Хадиев; «Страшный голод». Р.Шарафиева и Л.Губайдуллин; «Надгробный камень Махмуда Марджани». А.Гайнутдинов.

Татарский мир: «Целеустремленный сын Уразметьева». М.Амирханов.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Ориентация на вечность». И.Тагиров; «Правда об исламе». А.Али; «Стихи Азиза Али».

Литературное наследие: «Аксакал из Нарыша». С.Салимшина-Шагимарданова; «Религиозные праздники и памятные даты в 2021 году»; «Продвигающий татарскую культуру в Суоми». Х.Миннегулов; «Такташ и Сирин». А.Шарипов; «Фатхи Бурнаш и дивная Казань». Н.Каштан.

И вырвалось из мирской суеты: «Смерть Ильдара Юзеева (1933-2004)». Л.Лерон.

В глубинах памяти: «Фотонаследие Г.Баширова». З.Баширов; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Океан воззрений: «По-еврейски». Р.Садриев.

Художественное наследие: «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Шәмсебанат һәм Фатих Садыйковлар

- **Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт көндәлеге.** Руи Гонсалес де Клавихо
- **Хәзәрләр сабагы.** Фарук Нәфиев
- **Безнең өчен мәңге изге йорт.** Гүзәл Төхвәтова, Ләйсән Медведева
- **Хәсән Туфан ядкяре.** Әхәт Гаффар
- **Рәшит Ваһапов белән очрашулар.** Нәсимә Камалиева
- **Мөгаллим язмалары.** Фатих Садыйков

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Әдип авылы — фотоларда

Яңасала чишмәсе янында. Уңнан беренче – Г.Бәшировның туганы Хәерниса. 30 июнь, 1968 ел

Язучы Гомәр Бәшировның туган авылы – Арча районының Яңасала фотолары «Казан арты» тарих-этнография музееннан һәм язучының улы Зөфәр Бәширов архивыннан алынды.

Профессор Фәйзелхак Ислаев (сулда) язучы Вакыйф Нуриев һәм ТРның атказанган укытучысы Шәфигулла Гарипов «Җидегән чишмә» янында. 2016 ел

Г.Бәширов туганнары белән китапханә ачылган вакытта. Яңасала. 1983 ел

Г.Бәширов Яңасала мәктәбе ачылышында

ГОМӘР БӘШИРОВ ТУГАН НИГЕЗ

Гомәр Бәширов, туган нигезенә кайткач, китапханә бинасы янында.
16 июнь, 1982 ел. *Зәфәр Бәширов фотосы*

Гомәр Бәширов туган нигездә парк ачылган вакыт. Бер төркем каләм әһелләре һәм район хакимияте вәкилләре.
16 гыйнвар, 2020 ел. *Ленар Гобәйдуллин фотосы*

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.